
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ОКТЯБРЬ № 10

Сөембикә

СОҢГЫ ТУКТАЛЫШ

язмышлар бер-берсенә охшамый

«МИН СИҢЕ ШУНДЫЙ САГЫНДЫМ»

кеше китә, җыры кала

РЕЗЕДА ШӘРӘФИЕВА СЫЙЛЫЙ:

лазанья пешерәбез

Сөембикә ҖИҺАНШИНА:

«МИЛЛИ КИТАПХАНӘДӘ ЭШЛӘВЕМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ!»



PRESSA.RU



70

1945–2015

Сугыш язган хатлар

Һади Хәмитов 1908 елда хәзерге Әтнә районы Күлле Киме авылында туган. Тормыш иптәше Ркия белән алар 15 ел бергә яшәп калалар. Олы уллары Марсель әтиләрен сугышка озаткан көнне хәтерли әле: «Сугыш безне балачактан аерды, яшьли нужа йөге тарттырды. Безне әтисез калдырды, әнине тол итте... Тормышның бөтен авырлыгы әни өстенә төште. Әтидән без өч бала калдык: иң кечкенәбезгә - Лидиягә 3 кенә яшь иде. Кесәсенә бер уч ашлык салып кайткан өчен әбине дә төрмәгә утырттылар, озакламый аның үлгән хәбәре килде».

Һади Хәлиулла улы сугышта өлкән сержант, орудие командиры була. 1945 елның 29 гыйнварында Польшада барган каты сугышлар вакытында һәлак була ул. Познань-Милостово шәһәрендәге совет хәрби зиратында күмелгән.

«**24.11.43.** Сөекле семьям, сезләргә тагын хат язарга тотынам. Үзем хәзерге көндә таза-сау. Каты сугышлар. Бер үлемнән тагын исән калдым. Бер авылда бер йортта кунарга туры килде. Бер кич кундык, икенче көн иртән ашап бетереп, огневойга киттек атарга. Без чыгып ун минут узмады, йортка бомба килеп тиде, стена, идән, түшәмне, мичне җимереп ташлады. 2 иптәш үлде, берсе – хатын-кыз. Санинструктор иде. Ярый, башка сүзләр язып ятмыйм, хәзерге көндә исәнлек турында гына язам.»

«**5.12.44.** Минем иптәшем Ркия! Сезләргә миннән үтә сагынулы сәлам. Балаларым Марсель, Ленар, Лидиягә аталар сәламе. Ркия, сезнең 15.11дә язган хатыгызны алдым, хәлегезне белдем. Симез сарык итен ашадым, ну хатыгызның уртасында көлеп җибәрдем. Тылда яшәүчеләр нәрсә уйлыйлар! Сез язгансыз «үзегезгә тапкансыздыр» дип. Ягъни мин иптәш тапкан булам, сезне ташлап өйгә кайтмый йөрим. Ркия, нәрсәләр уйлыйсың? Мин монда сәгать саен үлем көтеп, ут эчендә сугыш алып барам. Минем вакытым юк өйләнеп, икенчеләр белән шаярып йөрергә. Сугышның алгы краенда хәзерләп куйганнар миңа хатын-кыз. Уйлама юкны. Һади.»





24.12.44. Гомерлек иптәшемә үтә сагынулы кайнар сәламнәремне кабул ит. Ркия! Үзем таза һәм исән. Сезләрдән якын арада хат алганым юк. Балалар шаулап школага йөриләрдер. Их, аларның укыганнарын күрсәң иде. Их, аларның зур үскәннәрен күрсәң иде, сөйләшүләрен ишетсәң иде. Мин сезләрдән бик ерак торам шул – Польша җирендә. Исән калсам, моңарчы йөргән кадәр йөрмәм, последний удар, җиңү удары булыр. Берлингача кызыл флаг элеп, җиңү ясап, өйгә борылырбыз. Ркия! Сугыш, белеп булмый, минут эчендә зур үзгәрешләр була. Мин андыймондый булсам, сез яшь, сезгә иптәш белән яшәргә кирәк, билгеле. Если мин ватан, Сталин өчен гомеремне бирәм икән, сезгә миннән рәхмәт һәм якты киләчәк телим. Ә балаларны ташламассыз, аларның киләчәктә тормыш чәчәкләре булып үсүләренә мөмкинлек бирерсез. Сез бу сүзләрне укып борчылмагыз. Бәлки, мин исән калырмын. 4 ел инде исән йөрим, күп үлемнәрдән калдым. Мин сезгә, бәлкем, үлеп калсам шулай итегез дип телим. Ярый, Ркия, хуш җаным. Ышан, Һади үлмәс ул, яшәр, һәм сезгә тагын якты-яхшы тормыш корыр өчен сезнең янга кайтыр. Көт мине, сөеклем Ркия! Хуш, хуш. Хат яз, барлык хәлләрне әйтеп. Сезнең Һади.»

(Һади ХӘМИТОВның фронттан язган хатлары Әтнә районы Бәрәскә авылында яшәүче кызы Лидия апа КАДЫЙРОВАда саклана. Хатлар үзгәртелмичә, әмма кыскартылып бирелә.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015



1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Сөембикә Җиһаншина
Фото: Гөлнара Сагиева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 5.10.2015 ел.
Заказ О-2839.
Тираж 7936.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

Илсөяр ИКСАНОВА

Октябрь

Сары яфрак булып
тәрәзәдән керде – Көз.
Куксел томан булып
күтәрелеп китте – Җәй.
Аксыл офыкларда – Кыш шәүләсе.
Һаваларда тибрәп торган
Татлы җәй,
Дымлы көз
исенә
Кушыла килә
сыкы –
кыш исе.





Наис ГАМБӘР

Көз – моңлы күз

Көзнең күзендә үк уйчан моң бар,
Яшерен сабырлык бар җанында;
Күпреп, кайнап торган хисләр түгел,
Айнылган бал инде җамында.

Кошлар булып кошлар сүлпәнрәк,
Сулар агышы да тынырак;
Көзнең дәрте тирәндәрәк ята,
Хәтер кайтавазы – тын, ерак!..


Күк сүрүе тоныграк хәтта, –
Челтер-челтер тутлар ябына;
– Тор-рыйк!..
Тор-рыйк!..
Ялгыз торна сөрән салып үтте
Баш өстемнән Казан ягына.

«Торыгыз, тор!..» – дияр идем,
Юк шул! –
Торна бик еракта.
Ничек ишетелсен?!
(Ялгыз кибән тора кыр түрендә,
Күктән төшкән торна шикелле.)

Көзнең йөзендә үк бер сагыш бар,
Кая күз текәмә – сарылык;
Пәрәвезләр ага су өстеннән,
Таллар муенына сарылып.



«Фәрештә йорты». Виктория Егорова эше.



PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



ЖАННЫҢ ГҮЗӘЛ ХАЛӘТЕ
Э. Закирова
16

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8
АВЫРЛЫКЛАР ВАКЫТЛЫЧА ГЫНА...
М. Авзалова



22
СОҢГЫ ТУКТАЛЫШ
А. Галиева



БУЯУ КАТЫШ КӘГАЗЬ ИСЕ...
Ф. Мостафина
12

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ




26
КЫР ҮРДӘКЛӘРЕ КАЯ ТӨШӘ?
Н. Гыйматдинова



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



38

КҮҢЕЛЕМ КОЯШЫ
Г. Закирова

ЯШӘЕШ 



46

ҖЫР БУЛЫП КИЛЕП КЕРДЕ...
Р. Камалетдинова

52



КЫЯЛАРНЫҢ ҮЗ СҮЗЕ
Г. Сафиуллина

ШУЛАЙ УК: 

42


КҮҢЕЛЛӘРНЕҢ СӘЛАМЕ
А. Юнысова

48

ЭНӘ КҮЗДӘН СЫНАР
Г. Хәсәншина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

СНУД



59

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КАРЫНЫМДА... ЧИТ БАЛА

САНДЫК. Хикәя.

«КӨЗГЕ РОМАНС». Бер җыр тарихы.

ДӨНЬЯЛЫКТА БЕРГӘ БУЛА АЛМАДЫК. Язмыш.

БҮЛӘККӘ – «КОРЫ ХУШБУЙ». Мастер-класс.



PRESSA.RU



Халык мәхәббәтен яулаган җырчы Илһам Шакиров турында гел язып торалар. Быел аның хакында язмалар аеруча күп чыкты. Минә әле үзем дә аның белән бәйле бер вакыйганы язмакчы булам. Ул үзе аны хәтерләмидер дә, ләкин минем күңелдә якты хатирә булып саклана ул.

1966 елда Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. Юбилейның тантаналы өлеше, әлбәттә, Яңа Кырлайда үтте. Бик күп шагыйрьләр, артистлар килде анда. Мактанып булса да әйтим әле, ул шигырь бәйрәмендә мин дә катнашып, Сибгат Хәкимнең «Бер горурлык хисе» шигырен укыдым. Сибгат ага рәхмәт тә әйткән иде әле. Ә бәйрәмнең икенче өлеше – кунакларны хөрмәтләү, сыйлау өлеше туган авылым Чиканас янындагы урман аланында үтте. Дөрес, анда инде безне кертмәделәр, аланны милиция урап алган иде. Мондый зур тантана Илһам Шакировсыз гына уза диме, аны да чакырганнар. Ул елларда әле авылда телевизор сирәк кешедә генә иде. Яраткан җырчыларыбызның үзләрен күргән юк, радиодан тыңлап кына беләбез. Минем әти Илһам абыйның җырлавын бик ярата һәм аның үзен күрү теләге белән янып яши иде. Әти ике сугышта катнашкан. Фин һәм Герман сугышы ветераны, Ленинград блокадасыннан бер аяксыз кайткан кеше. Протез аяклы килеш шушы аланга якын умарталыкта озак еллар умартачы булып эшләде. Кунаклар арасында яраткан җырчысының да булуын белгәч, күз кырые белән генә булса да күреп калып булмасмы дип, ул да шушы тирәгәрәк килгән. Таякка таянып килгән сугыш инвалидын милиция хезмәткәрләре аланга уздырмады, билгеле. Без дә шул тирәдәрәк идек, аларның тарткалашуын ишетеп тордык. «Энем, – диде әти. – Мин ашарга-эчәргә килмәдем, гомер буе хәмер эчмәдем. Мин бары тик Илһам Шакировны гына күрергә телим. Шуны гына күрәм дә, эшемә китәм». Юк, милиция хезмәткәренең керфеге дә селкенми. Якындагы ызан буйлап бер кеше йөренгәләп тора иде, бу сөйләшүне ишетеп, ул да килде. «Абый, – диде ул әтигә, – син ул Илһамны таныйсыңмы соң?» «Юк шул, күргәнем юк. Җырларын гына ишетеп беләм. Менә үзен бик күрәсем килгән иде дә, үткәрмиләр бит», – диде әти. Әлеге кеше әтине култыклап алды да аланга таба атлады. «Илһам Гыйльметдинович, безгә андый рөхсәт юк бит», – дип, милиция вәкиле каршы килмәкче иде, Илһам дигән исемен ишетү белән, әти таягын ташлады да: «И энем, синмени инде ул Илһам Шакиров! Менә бит Алланың рәхмәте, сине күрү бәхетенә дә ирештем», – дип, теге кешене кочаклап та алды. Без бу күренешкә шаккатып торганда Илһам абый әтине үзе белән эчкә алып кереп китте. Нәрсә булыр икән дип, без агачлар арасыннан кача-поса күзәтә башладык. Илһам абый әтине өстәл янына утыртты, официант чакырып, ашарга-эчәргә китертте. Нәрсә сөйләшкәннәрдер, анысын инде без ишетмәдек. Бераздан бар аланга Илһам Шакировның «Яшь имәннәр» җыры яңгырады. Ахырдан белдек: Илһам абый әтидән нинди җыр тыңлыйсы килүен сораган. «Яшь имәннәр»не аның соравы буенча җырлаган икән.

Бу вакыйганы әти гомере буе горурланып искә алды. Үлгәндә дә: «Туганнар белән җыелышып, мине искә алганда шушы җырны җырлагыз. Бу җыр сезгә минем төсем булсын», – дип, «Яшь имәннәр» җырын безгә васыять итеп калдырды. Шул көннән ул җыр гаиләбезнең ядкаренә әверелде. Без, әтинең җиде баласы (инде өчебез исән түгел), һәр мәҗлестә «Яшь имәннәр»не җырламый калмыйбыз.

Фәрхәт ЗЫЯТОВ.
Арча.

Минем дәү әнинең бабаи урлап каита. 1956 елда була бу хәл. Яраткан егете армиядә кала. Дәү әни ул вакытта Кайбыч районы Шүшермә авылында почтада эшли.

Беркөнне аны авылдаш егетен армиягә озату кичәсенә чакыралар. Шунда дәү әни бабайны – ул чакта әле яшь-яшь Рәхимулланы күрә. Бабам элегрәк тә танышырга омтылып карый. «Егетемне көтәм», – дип, дәү әни аны читкә тибәрә.

«Салкын кыш көне иде, – дип сөйли дәү әни. – Мин эштә идем. Өне-тыны бетеп, Рәхимулла йөгереп керде. «Сәкинә, бер генә минутка тышка чыгып кер әле», – ди. Киенеп, аның артыннан чыктым. Урамда бизәлгән бик матур ат тора. Мин шул атка карап сокланып торганда, кемдер күтәреп чанага утыртмасын-

мы! Безнең якта кыз урлау гадәтенең бик таралган чоры иде. Күз ачып йомганчы бер йортка алып кайтып, мулла каршына китереп тә утырттылар. Үзем елыйм, үзем эчемнән генә: «Өйләнешү шулай яратусыз гына була аламы?» – дип уйлыйм.

Көннәр үтә торды, язмышыма буйсынып яши бирдем. Рәхимнәрнең гаиләсе начар түгел иде. 1957 елда беренче балабыз Фидаил туды. Балам туганга кадәр бабагызны яратам дип әйтә алмый идем. Фидаил тугач, хисләрем уянды. Бераздан игезәкләр Рафаэль белән Равилне алып кайттык. Игезәкләремә алты айлап булгандыр, аларны кайнанама калдырып, әнкәемнең хәлен белергә киттем. Бик сагынган идем. Өй тутырып күрше хатыннары кергән, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыралар. Никтер күңелем тынгысызлана, балаларны имезәсем бар дип, тизрәк кайтып киттем. Мин кайтып кергәндә игезәкләрем икесе дә әллә нишләгәннәр иде. Ашамыйлар да, еламыйлар да, рәтләп башларын да тотмыйлар. Берсен алдыма алып күкрәгемне бирдем – алмый. Кулымда җан бирде балам. Сабыемның бәләкәй тәне суынганчы кочаклап еладым. Кайнатам авыл советына үлем турындагы кәгазь алырга китте. Ул кайтып кергәнче игезәкләремнең икенчесе дә җан бирде. Шул көннән яшәвемнең яме калмады. Тормышка Фидаилемнең: «Нәнәм, син хәзер гел шундый буласыңмы инде?» – дигән сүзе кайтарды. 1961 елда Фаилебез туды. Ул вакытта декрет яллары юк. Чөгендер кисәргә кырга чакырдылар. Фаилне дә үзем белән алам. Игезәкләрем үлгәч, баланы үземнән калдырырга курка идем».

Аннан соң тагын дүрт балалары туа. 1962 елда кайнатасын җирлиләр. Кайнанасы 1997 елда – 97 яшендә вафат булды. Без аны карт әби дип йөртә идек. Соңгы елларда урын өстендә булды. Әле дә исемдә: бүлмәсендә гел ашарга сорап утыра иде ул. Ә өстәлендә нинди генә ризык юк. «Сугыш чорындагы ачлыкны уйлап саташа», – ди иде бабам.

«Бабагызның күп вакыт юл куюы, аңлап, терәк булып яши белүе аркасында шулай озак бергә гомер иттек тә инде», – ди дәү әни. Чыннан да, Рәхим бабай сабыр холкы, акыллылыгы, тырышлыгы белән бөтен районга билгеле кеше. Юкка гына 1971 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнмәгәндер инде ул. Мактаганны бер дә яратмый үзе тагын. Пенсиягә чыккач та тик утыра белми ул, каралты-кураларны яңарта, уллары-кызларына йорт төзергә булыша. Дөнья куып яшәп ятканда аларга язмыш тагын бер авыр сынау әзерләп куйган икән: олы уллары Фидаил абый авырып үлеп китте. Бу кайгы барысыннан да ачырак, авыррак булды алар өчен. 2007 елның 21 маеннан башлап дәү әнием көн саен: «Улым үлгәнгә бүген фәлән көн», – дип санап бара.

Дәү әни белән бабайның әле дә бер-берсен яратуларын күрү безгә шундый күңелле. Әле менә 2016 ел башында зәбәрҗәт туйларын үткәрергә җыеналар. Бергә яшәүләренә – 60 ел! Быелның 8 июлендә – Гаилә көнендә аларны «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык» медале белән бүләкләделәр. Мин алар өчен чын күңелемнән куанам. Ходаем үзенең чиксез рәхмәтен кызганмасын иде.

Айсылу СӘЛАХОВА.
Кайбыч районы, Борындык авылы.

Казанга 1983 елдан бирле килгәнем юк иде. Быел улым белән киленем аның матурлыгына исләре китеп кайтты. «Сине дә алып барырбыз әле, үзең дә күрерсең», – дигәч, күңел җилкенде бит.

Юлга чыгасы көнне төш күрдем. Имеш, мин Казанда, «Сөембикә» журналы редакциясендә утырам. Шуңа да Казандагы сәяхәтебезне «Сөембикә»дән башларга булдык.

Мин 1985 елдан бирле Мәчетле районы Әләгәз рус мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытам. Шактый катлаулы эш бу, чөнки балаларның татар телен белү дәрәҗәсе төрле гаиләдә төрлечә. Үзара күбрәк рус телендә сөйләшәләр. Ярый, хәзер хәл бераз үзгәрде – телгә караш яхшырды. Укучылар да үзара татарча сөйләшергә тартынмый.

Рус мәктәпләрендә ана телен укытуның үзенчәлекле яклары бар. Укытучы туган тел методикасы белән беррәттән, чит телләрне өйрәнү методикасын да яхшы белергә тиеш. Рус телле балаларга тел өйрәткәндә төп игътибар иң элек сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә. Бәйләнешле сөйләм, иҗади сәләт үстерү грамоталы язарга өйрәтүгә караганда күпкә авыррак. Моңа традицион методлар белән генә ирешеп булмый, белем бирү методикасының яңа алымнарына мөрәҗәгать итәргә туры килә. Мин үзем В. Э. Штейнбергның белем бирү системаларын проектлау технологиясен үз итәм. Аның буенча яңа мәгълүмат бирү логик-мәгънәви модельгә нигезләнеп ясала. Яңа теманы аңлатканда да, кабатлау-гомумиләштерү дәресендә дә бу технологияне куллану җайлы.

Татар теле дәресләре татар милләтеннән булган балаларга гына тәгаенләнсә дә, башка милләт балаларының да татар теле белән кызыксынып киткән очраклары байтак. Бер дә онытасым юк, берсендә дәресемә украин милләтеннән булган бер малай кереп утырды. Ул безнең мәктәпкә яңа гына килгән иде әле. «Бу бала татар теле дәресенә ялгыш кереп утырды инде», – дим. «Сиңа рус теленә керергә кирәк. Монда – татарлар гына», – дигәнемә: «Минем дә татарча өйрәнәсем килә», – ди бу. Әйбәт кенә укып китте, татарча җырлар, шигырьләр өйрәнде. Мәктәпкә килгәндә бер авыз татарча белмәгән балалар да татар теле буенча узган республика олимпиадаларында катнашып, урыннар ала. Укучыларымның уңышлары күңелемә шул кадәр рәхәтлек бирә. Димәк, хезмәтем әрәм түгел. Көченең бушка китмәвен тоеп яшәү дә кирәк кешегә.

Минзилә НӘФЫЙКОВА.
Башкортстан.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

АВЫРЛЫКЛАР ВАКЫТЛЫЧА ГЫНА...



Мәдинә АВЗАЛОВА

ЫШАНЫЙК ӘЛЕ ШУҢА: КРИЗИСНЫҢ ТИЗ АРАДА БЕТҮЕНӘ, МАТДИ ХӘЛЕБЕЗНЕҢ ЯХШЫРУЫНА, ФӘКЫЙРЬЛӘРНЕҢ, ХӘЕРЧЕЛӘРНЕҢ КИМҮЕНӘ, ХӨКҮМӘТЕБЕЗНЕҢ ТОРМЫШ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУГА ЮНӘЛТЕЛГӘН ИГЕЛЕКЛЕ КАРАРЛАР КАБУЛ ИТҮЕНӘ ЫШАНЫЙК... һӘМ ӨМЕТЛӘНИК.

Моннан берничә ай элек Татарстан Дәүләт Советы уздырган матбугат конференциясендәге сөйләшүне искә төшереп утырам. Анда республиканың 2011–2015 елларга социаль үсеш программасын гамәлгә ашыру барышы турында фикер алышып арыгач, сүз үзеннән-үзе урта хәлләләргә барып ялганды. Кем ул, нинди ул безнең бай да түгел, фәкыйрь дә түгел урта сыйныфыбыз?! Бу хакта төрле фикерләр, бәхәсләр бар. Кем ничек күрә бит урта хәлле кешенең хәлен. Мәсәлән, Татарстан Дәүләт Советының икътисад, инвестиция һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Марат Галиев әйтүенчә, бу төркемгә кергән кешенең уртача айлык кереме алты яшәү минимумына тиң, ягъни

35 мең сум. Өстәвенә, ул белемле дә, аның автомобиле дә, чит илдә ял итәрлек мөмкинлеге дә бар! Республикада мондый рәхәтлеккә тиешкән кешеләрнең саны бүген 13 проценттан артып китә. Урта хәллеләргә айлык кереме 25 мең сум тирәсе булучылар да якыная бара икән. Андыйлар 20 процент тәшкил итә. Депутат белми әйтмидер. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге Республика мәгълүмати-методик үзәге җитәкчесе, философия фәннәре кандидаты Нина Исланова: «Урта хәллеләрнең социаль һәм икътисадый ихтыяҗы һәрвакытта да туры килеп бетми», – дип тә өсти. Бу ни дигәнне аңлата?! Әйтик, ялга чит илгә барасы килә. Ә акча юк. Теләк бар, мөмкинлек юк...

Шулай итеп, урта сыйныфка кемне кертәбез булып чыга инде? Ул белемле, аның әйбәт кенә эше, үз фикере бар. Ул күп укый, театрга йөри һәм башкалар. Мин кайсы төркемгә-сыйныфка керәм икән? Белемем бар, үз фикерем бар, китапны укыйбыз анысы. Ара-тирә, сирәк кенә булса да, театрга да баргалыйм. Ашыйсы килгәнне, киясе килгәнне алырга тырышам. Чит илгә... чит илгә дә барам. Әлеге дә баягы, теләк бар, акча юк булса да... Әмма теләк көчлерәк, диңгез тарта... Юкны бар итеп, кешедән акча алып торып булса да барам. Алып торырга курыкмыйм. Димәк, кире кайтарыр мөмкинлегем бар. Алайса, тарта-суза гына булса да, мин үземне урта хәллеләр исәбенә кертә алам. Менә хәзер, бүген әле ул шулай. Киләчәктә ничек булыр, безне алга таба ни көтә?

Илдә кризис баруын онытмыйк. Безне әлегәчә: «Ул озак бармас», – дип ышандырып килделәр. Тик Социаль анализ һәм прогноз институты белгечләренең хәбәр итүенә караганда, инде көзләргә үк социаль сферада хәлнең кискенләшүе ихтимал. Безне: «Илгә фәкыйрьлек килә», – дип кисәтәләр. Ил буенча алганда, халыкның кереме 5 процентка һәм хезмәт хакы 10 процентка кимү нәтиҗәсендә, фәкыйрьлек чигендә торучыларның күләме якынча 9-11 процентка җитте. Әгәр дә кризис дәвам итсә, ул 15 процентка җитәргә мөмкин. Татарстанда, әйткәнемчә, бу сан күпкә кимрәк. Ләкин безгә дә тынычланырга ярамый. Эшсез калсаң, Аллам сакласын, урта хәлдән түбәнгә тәгәрәвең – фәкыйрьлеккә чыгуың да бик тиз бит. Ил җитәкчеләре, бу авырлыклар вакытлыча гына, дип тынычландырмакчы. Белмим шул, алай булыр микән?! 90 нчы еллардагы кризисны гына хәтерегезгә төшерегез. Ул вакытта да аны үтә дә китә, дип әйттеләр. Ә ул озакка сузылды. Тиешле икътисадый шартларың булмагач, аннан тиз генә котылам димә... Ил күкрәгенә баскан яңадан-яңа санкцияләр, нефтькә бәяләрнең түбән тәгәрәве дөньякүләм дәрәҗәдә генә хәл ителә торган проблема ич. Бер бездән генә тормый. Болар барысы да социаль күрсәткечләргә тәэсир итә. Һәм ничек кенә әле?!

Россиядә 22 миллион кеше фәкыйрьлек чигендә. Бу хәлне яшәү минимумы буенча бәяләп буламы? Аның күләме бүген 5554 сум тәшкил итә. Башкача әйтсәк, кибеткә – азык-төлеккә ике мәртәбә чыгарлык акча бу. Ә бит әле фатирга, балалар бакчасына, мәктәп кирәк-яракларына, даими килеп торган салымнар өчен дә түлисе бар. Инде киеме, тагын очсыз-кырыйсыз вак-төяге турында әйтмим дә. Ул тиеннәргә ничек яшәргә? Кемдер, күбрәк өлкән яшьтәгеләрнең кайберләре, азык-төлек кибетләре янында, җир асты юлларында хәер сораша, кемдер юклыктан эчүгә сабыша...

«Сөткә-ипигә җитми...»

Очратканым бар минем андыйларны да. Башта мин ул әбине үзебезнең кибет янында очраткалый идем. Яулыгын маңгаена кадәр төшереп бәйләгән дә ишек төбенә куелган тартмаларның берсенә чүккән. Ара-тирә, таныш-белеш күрмәсен дигәндәй, як-ягына карангалап куя. Күреп торам: уңайсызлана. Хәер сорашуымы, әллә инде болай гына – хәл алырга гына утыруымы? Көн дә күрә башлагач

«ЮГАРЫ ЭШ ХАКЫ КИРӘК»

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге Республика мәгълүмати-методик үзәге җитәкчесе Нина ИСЛАНОВА:

– Үзәккә төрле кеше килә. Ике югары белемле белгечләр дә, кайсыдыр бер заводта эшләп, кыскартуларга эләккән гади эшчеләр дә, фирмасы бөлгенлеккә төшеп, урамда калган хезмәткәрләр дә... Кем генә килмәсен, моңарчы кайда гына эшләмәсен, биргән беренче соравы: «Эш хакы күпме?» Аларны нинди коллективта эшләячәкләре дә, эшләү шартларының нинди булуы да, социаль гарантияләр дә, килешүдә ниләр каралуы да кызыксындырмый. Иң мөһиме – акча!

Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең 99 проценты алга таба ничек яшәрен күзаллый алмый. Кайда, кем булып эшләр иде, кайсы һөнәрне яңадан үзләштерер иде... белмиләр! Кинәт кенә эшсез калган кеше моңа психологик яктан әзер булмый. Ул югалып кала. Аңа кайда эшләсә дә барыбер сыман. Мондый очракта мин аларга эшне дәүләт учреждениеләреннән тәкъдим итәм: «Акчасы әз димәгез, аның каруы, квалификациягезне үстерү мөмкинлеге бар», – дим. Күбесе, бигрәк тә хатын-кызлар, эшне өйләре яныннан эзлиләр. Имеш, йөрергә ерак булмасын. Теләсә нинди эшкә бармыйлар: урам себерүчеләр, җыештыручылар кирәк. Ә аларга чиста эш булсын. Гаепләп әйтүем түгел. Эшсез утырганда, анысы да кайчак ярап куя бит. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар: әйтик, эшеңне яратмасаң, хезмәтеңә нинди зур акчалар түләмәсеннәр, син үзеңнән беркайчан да канәгать була алмаячаксың. Бу хакта да онытырга ярамый.

Безнең үзебездә дә ике оешманы берләштерделәр дә, югары квалификацияле, пенсия яшенә җитеп килүче 20 эшчебез эштән китте. «Калыгыз, эшләгез», – дидек. Ә алар: «Юк, оныкларыбыз белән утырабыз». Шулай диделәр диюен. Ә күбесенең балалары эшсез утыра. Менә бит проблема кайда! Дөресен әйткәндә, өлкән яшьтәгеләр белән эшләве җиңелрәк. Алар больничныйга бөтенләй диярлек чыкмый. Аларны укытырга кирәкми. Эшне болай да бик шәп беләләр. Аннары... барына канәгать! Ни гаҗәп, яшьләр арасында компьютерны белмәүчеләр бар. Киләләр, компьютер белән бәйле эш тәкъдим итәбез. Булдыра алмыйлар. Димәк, өйрәтергә кирәк. Хезмәт базарына кирәкле һөнәр ияләре сирәк очрый. Шуңа да эшсез йөриләр яшьләр. Эш урыннары җитәрлек. Шул һөнәрне үзләштер дә, эшлә генә...

PRESSA.RU

кына аңладым: әби янәшәдә генә кайнаган тормыштан, кешеләрдән нидер өмет итә. Учындагы тиеннәрен тырыша-тырыша санаган әби янына киләм дә акча сузам. Ул сискәнеп китә: «Мин хәерче түгел, миңа хәер бирмә», – ди, мине аптырашта калдырып. «Хәерне хәерчегә генә бирмиләр аны, әби. Дога кылырсың», – дим. Ул шундук минем белән килешә. Артымнан рәхмәтләр әйтә-әйтә кала.

Икенче көнне мин аның янында озаккарак тоткарланам. Сөйләштерә башлыйм. Ул инде миннән тартынмый, якын туганыдай күреп, бөтен эч серләрен түгә. Әбинең пенсиясе минималь, әлеге дә баягы 6-7 мең сум тирәсе. Ул чутлап китә: «Фатирыма түлим, кирәкле даруларымны алам, шунсыз булмый – аяк-кулларым бик сызлый, кан басымым югары, ай буена ашаргаэчәргә өч мең сум акчам кала. Бер шешә сөткә дә тилмерәм, – ди ул, авыр сулап. – Зарланырга куркам. Аллаһы Тәгалә ипи-сөтеннән аермасын», – дип тә куя.

Яшьләр теләсә нинди эшкә бармый: урам себерү дә, йөк бушату да оят алар өчен. Ә типсә тимер өзәрдәй ир-егеткә хәер сорашу оят түгелме?!

Эшсезлек – зур бәла ул

Авырлыкларга түзем-сабыр без. Мондый чакта иң куркынычы – эшсез калу. Акча табуның бердәнбер юлы бит ул безнең өчен. Эш таба алмый айлар буе бер оешмадан икенчесенә чапкан көннәрне искә төшерсә, аның тәненә янә кайнар су сипкәндәй була. «Теләгән кешегә эш табыла ул», дигән сүзләргә ышанмый икән ул. Ул теләмәдеме, ул эзләмәдеме эш?! Шәхси фирмада озак еллар юрист булып эшләгән кеше, фирма ябылу сәбәпле, урамда калды. Ике югары белемле ир уртасы берәүгә дә кирәк булып чыкмады. «Үзең беләсең, кризис, бездә кыскартулар...» – дигәнне күп ишетте ул. Яраткан эше турында хыялланасы да юк хәзер аңа. «Йөк машинасына утырырга да риза мин», – дигән иде ул әнисенә. Эшсезлек сукмагында йөри торгач, ул бер нәрсәне аңлады: «Бүген эш базарына менеджерлар белән сатучылар, кунакханә ишеге төбен саклаучы сакчылар кирәк. Хәтта заводка да, һөнәрең булмагач, алмыйлар. Эш белән тәэмин итү үзәгенә дә бармады түгел, барды. «Бездә фәлән кадәрле эш урыны бар», – дип сөйләсәләр дә, тик ул алардан да тәгаен тәкъдим ишетмәде. «Башыңа төшкәч кенә беләсең икән ул. Эшсезлек – зур бәла. «Тапты инде, урнашты улым, – диде бер очрашканда егетнең әнисе. – Югыйсә эш харап иде».

Эшсезлек фәкыйрьлеккә генә китереп калмый. Аның нәтиҗәсе бик яман. Әнә шулай эшкә урнаша алмый йөрүче яшьләрнең күбесе тора-бара җинаять юлына баса. Хокук саклау органнары хезмәткәрләренең «криминоген вазгыять» дигәннәре шул инде. Моңа социаль киеренкелекне, физик һәм психик авыруларның кинәт артуын, еллар буе туплаган эш тәҗрибәңне югалтуны, тормыш дәрәҗәсенең түбәнәюен, ә иң аянычы, үз-үзеңә ышанычны югалтуны да өстәсәк, эшсезлекнең җәмгыятьне чиргә сабыштыручы чын бәла, фаҗига икәнлеген аңлый башлыйсың.

Нинди ярдәм көтәргә?

Эшсезлек базар икътисадының аерылгысыз юлдашына әверелде, дисәк, ялгышмабыз. Дөрес, ул гел бертөрле генә, бер дәрәҗәдә генә тормый: әле күтәрелә, әле төшә. Ничек кенә булмасын, беркайчан да: «Бездә эшсезлек юк», – дип әйтә алмабыз. Чөнки бу – икътисадый вазгыять. Күп илләрдә моңа хәзер табигый күренеш дип карыйлар. Бер яктан караганда, урамда йөрүче эшче куллар яңа эш урыннары булдыруга, икътисадны тагын да үстерүгә этәрә.

Эшмәкәрлекне үстерүнең эшсезлеккә каршы иң үтемле чара булуын исбатлау мәгънәсез тоелыр. Тормыш моны күптән раслап күрсәтте инде. Яңадан-яңа эш урыннары булдырып, бөтен районны үзләренә каратып тоткан фермерлар турында әйтүем. Гомумән, Көнчыгыш Европа илләрендә мәшгульлек хезмәтләре каршында эшмәкәрлек һәм эшсезләрне эшкә урнаштыру коммерция үзәкләре оештырылган. Бу үзәкләр эш башлап җибәрергә теләк белдергән кеше һәм Башкарма хакимият арасында арадашчы сыйфатын үтиләр. Әлеге тәҗрибәне нигә безгә дә кулланып карамаска?!

Бүгенге көндә безнең мәшгульлек үзәкләрендә 16,2 мең эшсез исәптә тора икән. Ел дәвамында күрсәтелгән дәүләт ярдәме түбәндәгедән гыйбарәт: беренче өч айда аларга элеккеге эшендә алган хезмәт хакының 75 проценты, икенче дүрт айда – 60 проценты, калганында 40 проценты түләнә. Ел дәвамында эш таба алмыйсың икән, үзеңә үпкәлисең. Тик шунысы бар: үпкәләп кенә бу хәлдән – фәкыйрьлек тозагыннан ычкына алсаң, ярый да ул. Әмма, кызганычка каршы, тормышта алай булмый. Әтисе эшләмәгән күп балалы гаиләне күз алдына китерегез. Баланы уку елы алдыннан башыннан аягына кадәрле киендерергә, уку әсбаплары, бөтен кирәкярагын алырга кирәк. Бер баланы мәктәпкә әзерләп җибәрү өчен, иң кимендә, ун мең акча кирәк. Кабатлап әйтәм, бик тыйнак кылганда... Өендә берәү генә түгел, өч-дүрт мәктәп баласы булса?! Кайчак әле ул бишәү дә була. Әти-әнигә нишләргә? Дөрес, Мөслим районында яшәүче сигез бала әнисе әйтмешли, берсенекен берсе кия алар. Тик бу гына мәсьәләне хәл итә аламы? Аннан, шунысы да сер түгел, мохтаҗлыкта үскән балаларга алга таба белем алу мөмкинлеге юк диярлек. Алар эшкә дә кайда кабул итәләр шунда урнаша. Сайланып торырлык мөмкинлекләре юк чөнки. Ә кайчак бөтенләй дә эшсез калалар. Авырып китсәләр, яшерен-батырын түгел, сыйфатлы медицинага янә өмет итә алмый-

лар. Үзегез беләсез, бүгенге «бушлай» медицина янына, кесәң тулы акчаң булмаса, якын да киләсе түгел. Җыеп әйткәндә, тормыш байлар өчен көйләнгән. Акчасыз уңга да, сулга да карый алмыйсың. Ә баланы укырга кертү өчен күпме акча кирәген беләсезме?! Әлбәттә, беләсез... Ник дигәндә, бүген бу өлкә дә чамасын югалта башлады. Ишеткәнебез дә, хәер, күргәнебез дә бар. Кая барабыз диген... Кайчак үзәк телевидениедән миллион долларларга төшереп алынган катлы-катлы йортлар турында, йомышыңны йомышлый торганына кадәрле алтыннан дип мактанып сөйләүләрен ишетәсең дә ипи-сөткә тилмергән әбиләр өчен үкереп елыйсы килә башлый. Нигә бу дөнья шулкадәр дә гаделсез икән, ә? Бюджет кытлыгын хәерчеябагай, аз мөлкәтлеләр, ягъни социаль өлкә исәбенә киметү, хәл итү турында баш ваткан дәүләт эшем ияләренә ни диясең менә...

Әйе, республикада эшсезлеккә каршы да, фәкыйрьлек чигендә утырган гаиләләргә азмы-күпме ярдәм итү өчен дә кулдан килгәнчә эш алып барыла. Хөкүмәтебезнең социаль программалары бүген дә нәтиҗәле эшләвен дәвам итә: күп балалы гаиләләргә, инвалидларга субсидия, ташламалар, яшь гаиләләргә социаль ипотекалар, үз эшләрен башлап җибәрүчеләргә эшмәкәрлекне үстерү программалары, төрле лизинглар, талантлы яшьләрне чит илдә укытулар... Боларның барысы да, әлеге дә баягы кризистан – авырлыктан чыгу юлларын эзләү, яңа эш урыннары булдырып, кешене азмы-күпме акчалы итү өчен эшләнә бит. «Мәктәпкә әзерләнәбез!» акцияләре, хәйрия белән шөгыльләнүче игелекле-ярдәмчел оешмалар да үзләрен күрсәтеп өлгерде инде. Ләкин барыбер социаль яклауга мохтаҗ катлау (ә ул аз да түгел, ким дә түгел, халыкның өчтән бер өлешен тәшкил итә) дәүләт тарафыннан һәрьяклап яклауга алынган булырга тиеш. Бары шул чагында гына киләчәгебез өчен тыныч була алабыз.

«ТАТАРСТАНДА ТОТРЫКЛЫЛЫК САКЛАНА»

? Хөкүмәтнең адреслы социаль ярдәмгә кучүе фәкыйрьлекне бераз киметә алырмы?

– Әгәр дә кеше тормыш өчен кирәкле булган иң кечкенә ихтыяҗын да канәгатьләндерә алмый икән, адреслы социаль ярдәм бу хәлне азмы-күпме җиңеләйтә ала. Чөнки бу очракта матди хәле авыр булган кешегә фәкыйрьлек бусагасын үтеп чыгу мөмкинлеге тудырыла. Без аны «ихтыяҗ корзинасы» дип атыйбыз.

Дөрес, хәзергә чараларның нибары 13,5 проценты гына адреслы. Шуның белән бергә, мәгълүматларга караганда, 2014 елда кереме яшәү минимумы күләменнән дә түбәнрәк булган халык саны, гомумхалык исәбеннән алганда, 7,1 процент тәшкил итте. Ә адреслы социаль ярдәм алучылар – 41,9 процент. Шулай итеп, дәүләтебез фәкыйрьлек чигендәгеләргә генә түгел, урта хәллеләргә якын катлауга да ярдәм күрсәтә булып чыга.

? Социаль ярдәм матди булырга тиешме, әллә инде ул ниндидер бер социаль хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт булса яхшыракмы?

– Матди ярдәм дигәч тә, ул акчалата түләүләр (айлык социаль ярдәм, бер мәртәбә түләнә торган түләүләр) һәм ягулык, азык-төлек, кием-салым, дарулар белән тәэмин итүгә генә кайтып калмый. Кайбер төркемгә дәүләт ярдәме социаль контракт шартларында гамәлдәге социаль адаптация программасы буенча бирелә. Мәгълүм программага социаль адаптация буенча түбәндәге чаралар керергә мөмкин: гаиләдәгеләрнең эш эзләве; һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем алу; эшмәкәрлекне башлап җибәрү; шәхси хуҗалык алып баруы; балаларны мәктәпкә һәм башка гомумбелем бирү оешмаларына йөртүне тәэмин итүе; үз теләге белән алкоголизмнан, наркоманиядән дәвалануы; торакка ремонт ясавы һәм көзге-кышкы чорга әзерләнүе һәм башкалар...

? Илдә кризис бара. Бездә эшсезләр артамы, кимиме? Эшсезләрне эшле итү өчен нинди чаралар кулланыла?

– Хәзерге вакытта хезмәт базарындагы вазгыятьне чагыштырмача тотрыклы дип әйтә алабыз. Быелның июнь-август айларында эш белән тәэмин ителгән халыкның саны 2073,2 мең тирәсе булган. Шуның 1993,4 меңе икътисад өлкәсендә эшле. Һәм 79,8 мең кеше яки 3,9 проценты шөгыльсез. Ләкин алар бик тырышып эш эзли.

Россия Федерациясе һәм Идел буе федераль округы буенча эшсезлек дәрәҗәсе безнеке белән чагыштырганда югарырак. Май-июль айларында ул ил буенча 5,4, ә Татарстанда 4,6 процент тәшкил итте. Тик мәшгульлек үзәкләренә килеп ирешкән мәгълүматларга караганда, сентябрь-декабрь айларында эшсез калачак кешеләрнең саны 1682 гә җитәчәк. Ел башыннан 6146 кеше эштән азат ителгән иде инде. Шунысын да әйтим, гыйнвар белән август арасында 58,5 мең эшсез теркәлгән һәм шуның 37,4 меңе эшкә урнаштырылган. Бүген исә мәшгульлек үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 16,2 мең кеше исәптә тора.

Шулай да 1 сентябрьгә мөрәҗәгать итүчеләрнең саны, былтырның шушы чоры белән чагыштырганда, 14,1 процентка күбрәк. Эшкә урнашучылар саны да күбрәк. Вакансияләрнең 4,8 процентка артуын да билгеләп үтик. Бусы да бик мөһим. Мисалга, быелның 16 сентябренә тәкъдим ителгән эш урыннарының саны 36,9 мең берәмлек булган. Эшсезләр арасында күбесе (61 процент) хатын-кыз, аннары яшьләр (22,7 процент), үз теләкләре белән эштән китүчеләр (62,5 процент) дә бар.

? Бу уңайдан хөкүмәтебезнең нинди чаралары гамәлдә инде?

– Россия хөкүмәте кабул иткән махсус чаралар ярдәмендә республикада халыкның тормыш-көнкүрешен шул бер дәрәҗәдә саклап кала алдык. Халыкны бу авыр заманда эшсез калдырмау өчен Татарстан Министрлар Кабинеты кабул иткән күп кенә дәүләт программалары эшли. Эшсезләргә вакытлыча эшләп тору, һөнәри белемнәрен үстерү мөмкинлеге бирелә. Инвалидларга яраклы шөгыль табу да мәшгульлек үзәкләренә йөкләнгән. Без хәтта Татарстаннан күчеп киткән кешеләрнең язмышы белән дә кызыксынып торабыз, эшкә урнашырга ярдәм итәбез. Вакансия ярминкәләре, яңа һөнәргә өйрәтә торган эш урыннары турында әйтмим дә инде. Бу чаралар даими уздырыла. Теләге булган кеше эшсез калмаячак. Тик теләге нинди бит... Һәркайда эшсезлек хөкем сөргәндә, вакансияләр турында сөйләү үзе бер өмет тудыра торган күңелле күренеш бит әле ул.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге

PRESSA.RU



БУЯУ КАТЫШ КӘГАЗЬ ИСЕ...



Фәнзилә МОСТАФИНА

МИН БАШТА АҢА КЫЗЫКТЫМ. МӨШКӘТ ЧИКЛӘВЕГЕ, ЯҢА ПЕШЕРЕЛГӘН КАҺВӘ, ДИҢГЕЗ, КӨЗГЕ УРМАН ҺӘМ БАШНЫ ӘЙЛӘНДЕРЕРЛЕК БАШКА ИСЛӘР КИЛЕП ТОРГАН БАСМАЛАРНЫ ИҢ БЕРЕНЧЕ БУЛЫП КУЛЫНА УЛ АЛА БИТ.

Яңа китап-журналларның исен-тәмен тоя алган кешегә генә таныш бу хис. Тик аның эшенең колачын-авырлыгын үзем чамалагач, 350 гә якын кешенең эшен оештыруда җаваплы икәнлеген белгәч, кызыгуымны башка хис алыштырды. Соклану иде ул!

Стажер булып КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшриятында эшли генә башлаган чоры. 1983 елның ноябре. Яңа басылган китапта текстның бер өлеше төшеп калган. Хата өчен Себер китә торган заманнар узган булса да, болай калдырырга ярамый. Бөтен сменалары, эштән соң калып, тиражны яңадан бастыра. Уен эшмени – ул вакытта тиражлар меңәрләгән саннар белән исәпләнгән бит!

«Брак»ның үз сменасында килеп чыкмаганлыгын Люция Мөгамбәр кызы соңрак кына аңлый. Шулай да ул вакыйгадан алган сабак гомер буена җитә. «Ленинград» сүзендә бер хәрефнең төшеп калуы, БАМ төзелешен тасвирлаганда хата китүе полиграфия хезмәткәрләре язмышында нинди яңгыраш табуын ишетеп үсә шул алар буыны...

Мөгаллимә булып эшләгән әнисе өйдә, үз балалары янында, гадәттәгедән озаграк булсын иде дип теләүләр... Аннары, укытучы һөнәренең кайчан үз эченә бөтереп

алуын да сизмәстән, әнисе юлын дәвам итәм дип йөрүләр... 10 нчы сыйныфта укыганда үз гомерендә беренче типографияне – район газетасы басыла торган кечкенә генә бүлмәне барып күрү... Ә 17 яше тулгач, романтика эзләп, Мәскәү полиграфия институтына укырга чыгып китү... Кичә генә булган кебек югыйсә. Юк икән, бик күп сулар аккан икән инде аннан соң. Урыссу урамнарының тараеп калганына, ә анда бергәләп туп типкән авыл малайларының ир уртасы булганына да, үзенең кызы белән улы үсеп буй җиткәненә дә шаккатый. Институтны тәмамлагач, Казанга эшкә юллама алганына да 32 ел икән.

Сайлаган һөнәрендә беренче чирканчыкны Мәскәүдәге «Красный пролетарий» нәшриятында ала Люция. Чын эшкә керешкәнче «йомышчы малай» вазыйфасын үтәргә туры килә әле. Анысы да бәхет – ул үзе теләгән дөньяга, Сүзнең «таш»ка басыла, Галиҗәнап Китап туа торган җиргә килеп эләкте ич.

Көндез – институт, кичен – нәшриятта. «Красный пролетарий»дан соң, «Правда», «Первая образцовая типография» мәктәпләрен дә үтә ул. 1980 елда Олимпия уеннары вакытында «101 нче километр»га озатылган хезмәткәрләрне алыштырып, иптәшләре белән бергә машина артына баса.

Институтны тәмамлагач, Үзбәкстанга китәм, анда торак бирәләр, дип йөргән Люциягә декан чат ябыша – Гавриловка да кеше кирәк, Казанга эшкә кайт, дип үгетли. Фатир да бирәбез дип торганда, туган ягын Үзбәкстанга алыштырамы соң?!

1983 ел. Беренче эш көне. Аны нәшриятның директоры Владимир Гаврилов белән җитештерү бүлеген җитәкләүче Дилбәр Хәйруллина каршы алалар. Аларга ияреп, типография буйлап үткәндә, булачак кайнатасы Җангәрәйнең дә заманында шушында эшләгәнен белми әле ул. Һәм киләчәктә улының да хезмәт юлын монда башлаячагын, тормыш иптәше Наилнең дә монда эшләячәген күз алдына да китерми. Әле аның үзенең дә буяу катыш кәгазь исе килеп торган дөньяга ныклап аяк баскан тәүге көне генә бит.

Эш урыны – офсет цехы. Бу ысул белән басуның, калган төрләрне икенче планга күчереп, алгы рәткә чыга барган вакытлары. Китаплар офсет ысулы белән басыла, газеталар да әкренләп шуңа күчә бара. Күчеш чорында эше дә күп, яңалыгы да. Сайлаулар, съездлар вакытында көн белән төн төшенчәләре юкка чыга — тәүлек дәвамында эш кайный. Яңа заман якынлаша. Алгарыш заманы. Совет полиграфиясенең, зур сикереш ясап, чит илләр белән тигезләшкән, Китапның яңа киңлеккә чыккан чоры. Линотипны – фото ысулы белән җыю, анысын компьютер алыштыра, җиһазлар яңартыла. Китапны бастыруга әзерләгәндә текстны пленкага яздырулар, сурәтне кургаш клишега төшерүләр артта кала, агулы эремәләр урынына зарарсызлары кулланылышка керә. Аңарчы да алга киткән технологияләр заманында яшибез дип уйлаучылар тагын да яхшырак була алуын күрә.

...Цех буйлап атлыйбыз. Люция Мөгамбәр кызы өч дистә ел элек аяк баскан цехлар түгел инде бу. Иseme дә,



җиһазлары да башка. Рухы гына һаман элеккечә. 1997 елда газеталар тулысынча офсет ысулы белән басуга күчеп бетә. Шул ук елда китапларны каты тышлык белән тышлау машиналары кайтартыла. Ә бүген инде интеграль ысул белән тышлауга күчеп баралар – тышлык үзе каты, шул ук вакытта җиңел дә.

Беренче көнне үк аңлый ул: гомерен шушы хезмәткә багышлаячак.

Китап камилләшә. Башка – күңелсез процесс та бара. Тиражлар кими. Шуңа күңеле әрни Люция ханымның. Миллионлаган тиражлар белән эш иткән кешегә 2-3 мең данә нәрсә инде ул?! Элек китапның эчтәлеге мөһимрәк булса, хәзер – тышлыгы. Конфет кәгазе кебек укучыны әллә кайдан ук үзенә җәлеп итеп торырга тиеш ул. Анысын булдыралар – нинди генә төрдә эшләмиләр бүген тышлыкны!

Китап әле сатуга да чыкмаган, ә ул инде алар кулында. Итәк астына яшереп алып чыгу очракларын кисәтү өчен, хезмәткәрләргә заманында бу дефицит товарны юнь бәядән генә сатып бирә башлыйлар. Арткы битенә мөһер сугылган ул китаплар бүген дә Люция ханымның өендә саклана әле. Әнисе мөгаллимә булган, китап тәрбиясендә үскән, соңрак үзе үк миллионлаган басманы якты дөньяга чыгарган кешенең аларны макулатурага тапшырырга кулы бармый. Хәзер инде балалары аның кебек үк китап җыя. Кызы Алия – матур әдәбият, улы Марат – спорт китаплары.

Люция Мөгамбәр кызы яңа гына басылган бер китапны кулына ала. Шулай үз куллары белән тотып карау, исен тою кирәк аңа. Бер сурәт тоныграк чыккан икән. Цех җитәкчесе Сәлим Салихҗановка шундук күрсәтмә дә бирә – кабат бастырырга! Бу эшнең икеләтә чыгымлы икәнен, күпме көч һәм сабырлык таләп итүен нәшрият-

PRESSA.RU





Фото: Гөлнара Сагиева

ның җитештерү бүлеген җитәкләүчедән дә яхшырак белүче юк. Тик аның өчен заказның тиешле дәрәҗәдә үтәлүе, заказ бирүченең хөрмәтен яулау – беренче урында. Шул принцип буенча эш итмәсәләр, танылган нәшриятлар белән хезмәттәшлек итә алырлар идеме икән? Ә «Идел-Пресс»ка заказ белән килүчеләр Казанныкылар гына түгел. Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Екатеринбург, Түбән Новгород, Уфа кебек шәһәрләрдән дә эре нәшриятлар бар аларга заказ бирүчеләре арасында. «Просвещение» басмаханәсе белән хезмәттәшлек итә башлаганда алар исемлегендә безнең нәшрият унтугызынчы урында идек. Бу баскычта югарырак күтәрелү өчен директорыбыз Әнәс Тәлгатович Әскәров та, без дә бик тырыштык, эшчеләребез дә көнне төнгә ялгап эшләде. Хәзер «Просвещение» безне беренче урынга чыгарган», – ди Люция ханым.

Нәшриятта эшләүчеләр – иң укымышлы халык.

Хата дигәннән, Люция Курамшина хезмәт юлындагы тагын бер ялгышны хәтерли әле. Михаил Горбачев Илбашы итеп билгеләнгәч, газеталарда яңа генераль секретарьның сурәтен биргәндә форма монтажлаучылар Михаил Сергеевичның башындагы миңен, тап дип уйлап, чистарталар. Төзәттек, дип, үзләре үк хата ясап куялар.

...Стажер булып башлаган хезмәт юлында җитештерү бүлегенең җитәкчесе вазыйфасына кадәр үсә ул. Тонналап кәгазьгә заказ бирү; китап, газета-журнал, брошюра, плакат ише заказлар кабул итү һәм аларның вакытында үтәлүен тәэмин итү; хилафлыклар була калса, аларны вакытында төзәтү... Шулар өстенә хезмәткәрләрнең эшен оештыру, эш сәгатьләрен көйләү, хезмәт хакларын контрольдә тоту... Әнисеннән алган сабырлыгы һәм җаваплылыгы булмаса, бу эшләрнең барысын да ерып чыгарга көче җитәр идеме икән?! Әле шуның өстенә гаиләне дә карарга кирәк бит. Хезмәт тырышлыгын бәяләп, 2011 елда Люция Курамшинага «Атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелә.

...Унбиш минуттан Люция Мөгамбәр кызының җитәкчелек белән җыелышка чыгып китәсе бар, ә без һаман аның тормыш йомгагын сүтәбез. Барасы җиренә җитәчәген белә ул, чөнки аның вакыты минутлап бүленгән, эчке сәгате соңга калырга ирек бирмәс. Ә хәзергә ашыкмыйча, балачак елларга кайтып, хатирәләрен яңарта. «Мин икенче сыйныфларда булганмындыр – әни авырып китте. Чире бик җитди, өметле түгел, диләр. Әнинең биш туганы килде. Балаларны бер елга булса да үзебезгә алып торыйк, диләр. Шул вакыт әтинең: «Минем кешегә өләшә торган балаларым юк!» – дигәне хәтердә. Бирмәде безне. Без, биш бертуган, бер-беребезне карашып үстек. Ходайның рәхмәте – әни терелде. Әти генә бик иртә китеп барды». Йодрык бүген дә бербөтен – биш бертуган, төрлесе-төрле җирдә яшәсәләр дә, бер-берсенең хәл-әхвәлен белешеп, ярдәмләшеп яшиләр. Очрашу урыны үзгәрми – туган нигез. Анда аларны сагынып көтүче әниләре Мөсәвәрә апа, шөкер, исән-сау. «85 кә җитсә дә, «Сөембикә»не һаман кулыннан төшерми, башыннан ахырынача укып чыга», – ди аның турында Люция ханым.

«Китап кибетенә еш керәм мин. Иң беренче, әлбәттә, үзебездә басылган китапларны карыйм. Аннары башкаларныкына күз салам, чагыштырам. Үзем дә китап укырга яратам. Биш-ун елдан басма матбугат бетәчәк, диләр. Ышанмыйм! Безнең һөнәрне сызып ташлау булыр иде бит бу...» Оптимист та әле Люция ханым. Кайчандыр үзе романтика эзләп килгән полиграфия-нәшрият тармагының киләчәге тагын да яктырак булачагына ышана ул.

ҖӘМГЫЯТЬ

■ Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстан Дәүләт Советы депутатларына юллама белән чыкты. Анда кеше капиталы үсешенә, милләтара мөнәсәбәтләргә, гаилә кыйммәтләренә аеруча зур игътибар бирелә.



■ Кырым делегациясе Татарстанга килде. Аның киңкырлы эш планында газета-журнал продукциясе белән танышу да каралган иде. Идел буендагы иң эре медиахолдинг «ТАТМЕДИА»га килеп, кунаклар Татарстан башкаласыннан алган тәэсирләре белән уртаклашты. «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтов массакүләм мәгълүмат чаралары үсеше планы белән таныштырды. Республикада этник басмаларны үстерү һәм аларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү турында сүз булды. Кырым делегациясенең Татарстанга эш сәфәре вакытында Кырым һәм Татарстан арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-тикшеренү, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында Килешүгә кул куелды.

■ Корбан бәйрәме алдыннан Мәскәүдә яңартып төзелгән Җәмигъ мәчете ачылды. Тантанада Россия, Төркия, Казакъстан, Татарстан Президентлары катнашты, күп санда мәртәбәле кунаклар килде. Мәчет — Европадагы иң зур гыйбадәтханәләрнең берсе. Анда берьюлы 10 мең мөселман намаз укый ала. Россия мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин: «Җәмигъ мәчете — иманыбыз һәм берлегебез символы», — дип белдерде.

СПОРТ



■ Казан Теннис академиясе базасында Россия чемпионаты кысаларында беренче тапкыр Теннис фестивале узды. Атаклы спортчылар Анастасия Мыскина, Евгений Кафельников, алыштыргысыз тренер Шамил Тарпищев фестиваль кунаклары иде. Игорь Куницын мастер-класс үткәрде.

Татарстан җыелма командасыннан Ксения Лыкина парлы разрядта чыгыш ясап, Россия чемпионы исемен яулады.

МӘДӘНИЯТ

■ Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 110 нчы юбилей сезонында 7 премьера куелачак. 110 нчы сезон драматург Туфан Миңнуллин исеме белән дә бәйле булачак. Аның иҗатына багышланган ункөнлек уздырыла. Яңа сезонда театр Илгиз Зәйниевнең «Әниләр һәм бәбиләр» пьесасына нигезләнеп иҗат ителгән «Әлли-бәлли-бәү» спектаклен тәкъдим итәчәк.

■ К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында һәр якшәмбедә «Гаилә спектакльләре» проекты эшли башлады. Тамашачылар театрның иң яхшы спектакльләрен күрә һәм театрның үткәне, хәзергесенә багышланган күргәзмәләр белән таныша алачак.

■ Чаллы курчак театры Казакъстанның Актүбә шәһәрендә узган IV Халыкара курчак театрлары фестиваленнән җиңү белән кайтты: «Иң яхшы режиссерлык эше» номинациясендә алар диплом белән бүләкләнделәр. Артистлар театр белгечләре игътибарына «Дюймовочка» спектаклен тәкъдим иттеләр.

■ Казанда II Халыкара реставраторлар съезды булып узды. Мәдәни мирасны саклау өлкәсендә норматив-хокукый һәм техник көйләү, реставрация тармагында кадрлар әзерләү, мәдәни мирас объектларын саклау буенча халыкара оешмаларда Россиянең роле һәм башка мәсьәләләр буенча фикер алыштылар. Корылтайда РФ Мәдәният министры В. Мединский да катнашты. «Моннан 30-40 ел элек кенә Казан провинциаль калаларның берсе иде, бүген исә шәһәр – Россиянең эшлекле, инфраструктуралы туристик энҗесе», – дип бәяләде министр.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры режиссеры Резеда Гарипова 2015 ел нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе хөкүмәтенең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә талантлы яшьләргә бирелә торган стипендиягә лаек булды. Җиде спектакль сәхнәләштерергә өлгергән Резеда хәзерге вакытта Рөстәм Мингалимнең «Өченче бүлмәдә эт яши» пьесасы буенча спектакль куярга җыена.



МӘГАРИФ

■ Казанда «Россия ел укытучысы-2015» Бөтенроссия конкурсы чаралары узды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, РФ мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов катнашты. Мондый чара, традиция буенча, узган елгы конкурста җиңүченең ватанында үткәрелә.

Татарстан укытучысы, «Россия ел укытучысы-2014» конкурсының абсолют җиңүчесе Алла Головенькина Мәскәүдә «Укытучы көне» уңаеннан уздырылган бәйрәм тантанасын алып барды.

■ «WorldSkills Russia-2018» Бөтенроссия һөнәри осталык чемпионаты Казанда узачак. Бу хакта Сочида Халыкара инвестицион форум кысаларында билгеле булды. «2018 елда безнең Дөнья чемпионатын кабул итәргә әзерлекне тикшерү буенча генераль репетиция узачак», – дип билгеләп үтте ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

PRESSA.RU

«Каендагы яра... Күрегез сез, автор аны өнсез кычкырудан ачылып калган авызга охшата. Һәм бөтенесе күз алдына килеп баса...» Әңгәмәдәшемнең сүзләрен гаҗәпләнеп һәм сокланып тыңлап утырам. Китапның төмен белеп, һәр детальне, һәр күренешне күңеленә сеңдереп укып барган кеше генә югары зәвыклы укучы буладыр.

Эльмира ЗАКИРОВА

ҖАННЫҢ ГҮЗӘЛ ХӘЛӘТЕ

Кремль урамында ак мәрмәр колонналы университет каршында урнашкан бу затлы бина әллә каян балкып, ымсындырып, үзенә дәшеп тора. Студентларның яраткан «сковородка»сы, Лобачевский бакчасы, университетның яңа биек корпуслары янәшәсендә ул тагын да матуррак, серлерәк күренә. Кичләрен фонарьлар яктысында сихри бер халәттә каласың: модерн стилендә салынган әлеге йортның зур тәрәзәләреннән, челтәрләп каймаланган балконнарыннан чын-чынлап тылсымлы әкият дөньясы балкый. Арыслан тоткалы авыр ишекне ачып, тизрәк эчкә үтәсе, борынгы баскычлардан күтәреләсе килә... Тикмәгә генә аны Казанның йөзек кашы димиләрдер инде! Экскурсоводлар, иң элек XIX гасыр башына – тарих төпкеленә төшереп, йортның архитекторы Карл Мюфке исемен телгә алырлар, затлы бинаны «Ушкова йорты» дип тә, «Второвлар китапханәсе» дип тә таныштырырлар... Фабрикант Ушков аны хатыны Зинаида Ушковага туй бүләге итеп махсус салдырган бит! Ишек өстенә куелган «ЗУ» вензеле үзе үк шул хакта сөйли. Соңыннан ул китап йортына әверелә. Анысының да кызыклы тарихы бар. Заманының зыялы кешесе Иван Алексеевич Второв гомере буе китаплар җыйган (алар 1908 томга җитә!). Аның шәхси китапханәсе турында ул чорда белмәгән кеше сирәк булгандыр. Бу байлык улы Николай Иванович Второвка мирас булып калган. Петербургка күчеп киткәндә исә Николай Иванович әтисенең китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк иткән. Шулай итеп, 1865 елда Казанда җәмәгать китапханәсе ачылган. Ә безнең өчен ул күптән инде шәһәребез, республикабыз, халкыбыз горурлыгы булган Китап сарае, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе. Бу серле бинага барып кергәч, бөтенләй әкият дөньясына килеп эләккәндәй буласың. Таң калып, тирә-ягыңа күз саласың. Диварларга, тәрәзәләргә витражларга кошлар, җәнлекләр, аждаһа сурәтләре төшерелгән. Идән-түшәмнәр чәчәк, яфрак рәсемнәре белән бизәлгән. Ма-ту-ур! Японкытай стилендә эшләнгән вестибюль. Тарихи көзгеләр... Уңда да, сулда да, каршыда да ишекләр, каталоглар, картотекалар, киштәләр... Ишекләрнең берсе – борынгы кулъязмалар, икенчесе – сирәк китаплар бүлегенә алып керәчәк... Мин һәрвакыттагыча яраткан урыныма – сталактитлы мәгарәгә ашыгам. Түшәмнәрдән, диварлардан таш сөңгеләр асылынып тора. Кабырчыклы стеналар арасыннан үрмә гөлләр шытып чыккан... Без студент чакта биредә имтиханнарга әзерләнеп утырырга ярата идек... Кунаклар кабул итә торган ал, яшел бүлмәләр, каминнар, зур аквариум, борынгы канделябрлар, шәмдәлләр көзгә чалынып кала. Урта гасырларның алман замоклары стиле, мавритан стиле... Балконга чыгу юлындагы түгәрәк бүлмә исә мәчет манарасын хәтерләтә, анда тавыш та шәп яңгырый. Юк, биредә ашыкмыйча, иркенләп йөрергә кирәк. Никадәр серләр яшерелгән монда! Никадәр хәзинә!

Быел, Россиядә Әдәбият елын билгеләп үткән бер вакытта, китапханәдә дә зур вакыйга – ул 150 еллык юбилеен бәйрәм итәргә әзерләнә. Китапханә, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында күңелдә дистәләгән сораулар туа. Һәм мин, әлбәттә инде, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директоры Сөембикә Разил кызы Җиһаншина янына ашыгам. Карап торуга йомшак-тыныч күренсә дә, гаҗәп күп эшләр башкарырга, кызыклы башлангычлар белән чыгарга, янарга һәм яндырырга маһир, гел яңалыкка омтылучы, киләчәккә карап яши торган җитәкче диләр аны! Үзе ипле-җайлы да. Кыз йолдызлыгы аны гадел һәм тырыш, төгәл һәм максатчан иткән. Ханбикә исемен йөртүче Сөембикә ханым үзе дә кызыклы шәхес. Халкыбызның рухи хәзинәләрен туплау, өйрәнү һәм халыкка җиткерү вазыйфасы аңа югарыдан иңгән, исеме белән бергә үк, язмышына язылган, күрәсең. Исеме чынлап та җисеменә туры килеп тора! Озын чәчләре, асылмалы көмеш алкалары, зифа буй-сыны, килешле киемнәре аңа ниндидер үзгә бер сылулык өсти. Аңардан затлылык, зыялылык, ятылык бөркелә. Китапханә, яраткан китаплар, туган тел язмышы, китапханәчеләр хезмәте турындагы сөйләшү балачак хыяллары, ерак илләр, матур хатын-кыз булу серләренә барып тоташа.

● КИТАХАНӘЧЕ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНМАСАМ ДА, ЯЗМЫШЫМДА ШУЛАЙ ЯЗЫЛГАН БУЛГАН, КҮРӘСЕҢ. Минем эш урыным бер генә. Китапханәдә инде 22 елдан артык эшлим. Күптән түгел кәгазьләремне актарып утырганда 12 яшемдә «Артек» пионер лагеренда алып барган көндәлегем килеп чыкты. Язылганнарны көләкөлә укыдым: «Бүген отряд советын сайладылар. Мине китапханәче итеп куйдылар! Көн саен газеталарны бер төпләмгә теркәп барам...» Ни гаҗәп, институтның беренче курсыннан соң практикамны да Казандагы китапханәләрнең берсендә үттем, шунда беренче хезмәт хакымны алдым. Ул чакта әле киләчәктә кайда эшлисемне төгәл генә күз алдыма да китерә алмый идем. Ләкин алдагы язмышым Республика Милли китапханәсе белән бәйле булып чыкты. Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында «Тарих, җәмгыять белеме һәм инглиз теле укытучысы» белгечлеге алып, 1992 елда Милли китапханәгә – документларны фәнни эшкәртү бүлегенә эшкә урнаштым, бераздан халыкара китап алмашу бүлегендә эшли башладым.

Бер җирдән дә табалмаган китапны шушында гына эзлисең.

● ИНГЛИЗ ТЕЛЕН БЕЛҮЕМ БИК БУЛЫШТЫ. Интернетта игълан ителгән конкурста катнашып, грант оттым! Ул вакытта әле грант программалары турында юньләп белми дә идем, анкета тутырдым да җибәрдем. Ярымфиналга үтүемне хәбәр иттеләр, Мәскәүгә имтиханнар тапшырырга, әңгәмә үтәргә чакырдылар. Җиңеп, финалга чыктым. 9 ай Американың Урбана-Шампейн шәһәрендәге Иллинойс штаты университетында китапханә һәм мәгълүмати фәннәр буенча магистратурада уку, 3 ай дөньяның атаклы Нью-Йорк җәмәгать китапханәсендә практика үтүләр... Зур мәктәп булды ул! Интернет бездә әле кереп кенә килгән бер чорда, анда компьютерда эшләргә, электрон почтадан файда-

PRESSA.RU







ланырга, веб-сайтлар төзергә өйрәттеләр. Бер төймәгә генә басып дөнья кадәр мәгълүматны саклап булу һич башыма сыймый иде әле ул чакта. Хәзер генә көлке тоелгач та... Котым очып: «Сез ялгышмыйсызмы, бернәрсә дә югалмаячакмы?» – дип кат-кат сорап тинтерәтә идем үзләрен. Күп китапханәләр эше белән таныштым, Америка китапханәләр ассоциациясендә булдым, китапханә конференцияләре ничек үтүен күрдем. Кайткач, чит илләр әдәбияты бүлеген җитәкләдем. Ул елларда халыкара эшчәнлек белән актив шөгыльләндек, балалар, студентлар, укытучылар, табиблар белән эшләдек. Россиядә эшләүче АКШ илчеләре безнең китапханәнең «Америка үзәге»нә килде.

Чит илләргә барсам, китапханәләрен күрми кайтмыйм.

АКШТА ҖӘМӘГАТЬ КИТАПХАНӘЛӘРЕ МАКДОНАЛДСЛАРДАН КҮБРӘК ХӘТТА! Франция, Япония, Корея, АКШ, Швейцария, Таиландның заманча китапханәләрендә стажировкада булып, күп нәрсәгә өйрәндем. Анда китапханәләр бик популяр. Мәсәлән, Франциянең Лион шәһәре китапханәсе бик зур булса да, анда һәрчак чират. Ул гади китапханә генә түгел, очрашу урыны да. Халык бер-берсе белән аралашырга, музыка тыңларга, видео карарга дип тә килә. Күп гаиләләр ял көннәрен шунда үткәрә. Миңа калса, бездә дә оештырып була моны. Иран Милли китапханәсе исә зурлыгы һәм масштаблары белән генә түгел, китапка аерым сакчыл мөнәсәбәте белән дә таң калдырды. Китапны шулай зурлау һәм кадерләү төп китабыбыз Коръәнгә булган хөрмәттән үк киләдер, минемчә. Бездә дә китапны, тарихи-мәдәни һәйкәлләрне, кульязмаларны әнә шулай күз карасыдай сакласыннар иде. Миңа Вашингтондагы Конгресс китапханәсе, Нью-Йоркның җәмәгать китапханәсе бик ошый! Нью-Йоркныкы да, безнеке дә шәһәрнең нәкъ үзәгендә! Аларныкы да, безнеке дә искиткеч матур тарихи бинада! Нью-Йорк китапханәсендә дә, Милли китапханәдә дә бай коллекцияләр саклана!

КИТАПХАНӘНЕ КУЛЪЯЗМАЛАР ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ ФОНДЫ КҮПЛӘРНЕ ТАҢ КАЛДЫРА! Сирәк һәм аеруча кыйммәтле документлар тупланган анда: археографик экспедицияләр вакытында Түбән Новгород, Оренбург, Пенза, Самара, Пермь, Башкортстан якларыннан табып алып кайтылган искетатар язулы, гарәп шрифтлы китаплар, уникаль коллекцияләр, XIX йөз ахыры – XX йөз башында нәшер ителгән вакытлы матбугат дисеңме... Гомумән, безнең китапханәдә 3 миллион 300 мең документ саклана: китаплар, электрон басмалар, ноталы басмалар, дисклар, патентлар... Татарстан һәм татар халкы турында татар телендә китаплар җыю һәм саклау белән шөгыльләнүче дөньяда бердәнбер китапханә ул. Елына безгә 35 мең укучы килә, 1 миллион 450 мең китап бирелә. XIV йөз кульязмаларын, Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ын, Толстой, Пушкин, Тукайның үзләре исән чакта басылган китапларын күрергә була анда.

ИРТҮК ИҢ БЕРЕНЧЕ БУЛЫП КИЛЕРГӘ ЯРАТА ТОРГАН УКУЧЫБЫЗ ДА БАР! Беренче номерлы контроль карточка һәрчак аңа эләгә. Бер-бер сәбәп белән аз гына соңарса да, кәефе төшә. Шуңа беренче номерны аңа саклап калдырабыз. Китаптан башка яши алмый торган, көн саен килә, китапханә ачылганчы ук ишек шакый торган укучыларыбыз бар.

БЕЗДӘ БЕРКАЙЧАН ДА «КИТАП ЮК» ДИГӘН СҮЗНЕ ӘЙТМӘЯЧӘКЛӘР. Төрле китапханәләр белән бәйләнешкә керә торган абонемент укучыга теләсә кайсы китапны табып бирергә булыша. Үзендә юк икән, компьютер төймәләренә басып, шәһәрдәге башка китапханәләрдән,



Фото: Гөлнара Сагиева

университет китапханәсеннән, бөтен Татарстаннан эзлиләр. Алай да барып чыкмаса, Мәскәү, Санкт-Петербург китапханәләренә мөрәҗәгать итәләр.

ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕМӘ СОКЛАНАМ. ҖАВАПЛЫ, НАМУСЛЫ, ТЫРЫШ, ТЫНГЫСЫЗ АЛАР, КҮП УКЫЙЛАР, КҮП БЕЛӘЛӘР. Бүген китапханәбездәге 238 кеше 20 дән артык бүлектә эшли. Берчак чит илгә китапханәчеләр төркеме җитәкчесе булып чыгарга туры килгән иде. Эшмәкәрләр – үзләре бер төркем, икътисадчылар – үзләре... Оештыручылар һәр көнгә йомгак ясаганда ахырдан гел безне мактадылар. Иң оешкан, иң төгәл, иң тәртипле, күп укыган, экскурсияләр вакытында гидны да алыштыра алырлык китапханәчеләребез өчен сөендем. Җанның үзгә бер халәтенә ия кешеләр генә эшли ала китапханәдә! Хатын-кызлар гына эше димәкче була кайберәүләр... Крылов, Одоевский, Гете, Кант, бертуган Гриммнар, үзебезнең Һади Максуди, Закир Сәет-задә, Мирхәйдәр Фәйзиләрнең китапханәче булуын исегезгә төшерегез. Галим кеше генә китапханә белән җитәкчелек итә алган. Атаклы галим Николай Лобачевский үзен иң элек китапханәче, аннары гына, өтер аша, ректор дип яза торган булган. Ә сез беләсезме, Америкада китапханәче сүзе баш хәрефтән языла! Конгресс китапханәсе директоры рәсми рәвештә АКШ Конгрессы Баш Китапханәчесе дип йөртелә!

ӘДӘБИ КАФЕБЫЗГА КУНАККА ЧАКЫРАМ! Анда «Әдәби кунакханә» эшли. Язучылар, шагыйрьләр белән очрашулар үтә. Китап кибетендә китаплар сатып алырга, чәй йә кофе эчәргә, дуслар белән аралашып утырырга, Wi-Fiдан бушлай файдаланырга мөмкин. Китап тарату һәм җәмгыятьчелек белән элемтәләр өчен җаваплы бүлек китапханә буйлап экскурсияләр дә үткәрә. Экскурсиягә килергә теләүчеләр бик күп, кайберәүләр, хәтта алдан ук чиратка язылып куялар. «Театраль кунакханә», «Музыкаль кунакханә» проектлары да популяр. «Паркта китапханә» проектын Милли китапханәнең 150 еллыгына, Әдәбият елы кысаларында узучы Бөтенроссия китапханәчеләр кәнәшенә һәм Татарстанда игълан ителгән «Парклар һәм скверлар елы»на багышладык. Паркка китаплар, газета-журналлар алып чыгабыз, «ачык микрофон» эшли, балалар шигырьләр укый... Шунда ук китап шүрлеге дә бар: бушлай китаплар алырга мөмкин. «Укы. Уйла. Сөйлә!» шигаре белән ел саен уздырыла торган китап бәйрәменә халык яратып йөри.

ЕШ КЫНА ЯРАТКАН КИТАБЫМ ТУРЫНДА СОРЫЙЛАР. Бу сорауга кистереп кенә җавап бирү кыен. Кайбер әсәрләр балачакта бик яратып укылса да, вакытлар узу белән аның тәэсире үзгәрә. Төрле яшьтә төрлечә кабул итәсең. Кәефтән дә күп нәрсә тора. Кайчак дөньяларыңны онытып эшкә кагылышлы китапларга кереп чумасың. Хисләргә бирелеп, үзеңне хатын-кыз итеп тоеп, мәхәббәт романнары да укыйсы килә. Үсмер чакта Маргарет Митчеллның «Унесенные ветром», Лев Толстойның «Анна Каренина»сын бик яратып укыган идем, хәзер дә алар – яраткан әсәрләрем арасында. Соңгы укыган китабым – Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы. Халыкның зирәк акылы сокландыра. Була шундый китаплар, әсәрдәге аерым өзекләре, тирән фикерләре белән күңелгә кереп кала. Антуан де Сент-Экзюпериның «Нәни принц»ы, мәсәлән. Мин китап укыганда очраган кызыклы фикерләрне күчереп алам. Никадәр акыллы сүзләр, мәгънәле гыйбарәләр очрый! Милли китапханәнең 150 еллыгына өч телдә китап-альбом әзерләдек, анда китап, китапханәләргә караган канатлы сүзләрне дә файдаландык. Френсис Бэкон әйткәннәрне ошатып, блокнотыма да язып куйдым: «Китаплар – вакыт дулкыннары буйлап сәяхәт итүче һәм үзләрендәге кыйммәтле йөкне буыннардан-буыннарга илтүче фикер кораблары».

Чыңгыз Айтматов, Фәнис Яруллин әсәрләрен кайта-кайта укыйм.

ЯҢА БАСЫЛГАН КИТАП ИСЕ АҢКЫП ТОРГАН ХУШБУЙЛАР ДА БУЛА. Мәсәлән, «Paper Passion» хушбуе флаконы калын китапны хәтерләтә икән. Кайберәүләр, электрон китапларга өстенлек биреп, басма китаплар озакламый юкка чыгачак, дип йөри башлаган иде. Хәзер инде яңадан кәгазьдә басылган китапларга ихтыяҗ арта. Бармак очларына урнашкан тоемлау нокталары да шул китап битләрен ачу, актаруга җайлашкан лабаса! Өр-яңа китапны кулга алу, битләрен актару – үзе бер рәхәт мизгелләрдер... Кая барсам да, китап җыярга, китап бүләк итәргә яратам. Без эштә дә туган көннәргә китап бүләк итүне матур бер гадәткә керттек. Без китапсыз яши алмыйбыз бугай... Бер кызык мисал. Борынгы фарсы вәзире Абдул Касыйм Исмаил ерак сәфәргә чыкканда китапханәсен дә үзе белән ала торган булган. Алфавит тәртибендә тезелгән 117 мең китапны 400 дөя ташып йөргән.

ТЕЛНЕҢ ТӘМЕН БЕЛЕП ЧЫН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШУЛӘР КҮҢЕЛНЕҢ БИК ТИРӘН БЕР ТӨПКЕЛЕНӘ КЕРЕП, ОНЫТЫЛМАСЛЫК БУЛЫП УРНАШЫП КАЛГАН. Бала чакта әтинең туган авылы Ташлыкка озын җәйләр буена торырга кайта идем. Көтү куулар, сыер көтүләр, сепаратта сөт аертулар, сөт өстен туглап май язулар, каз

PRESSA.RU

бәбкәләрен су буена төшерүләр, көянтә белән суга барулар, елгада кер чайкаулар... Мин андагы сөйләшүләрне, тавышларны хәзер дә ишетәм кебек.

Уку – олы хезмәт ул, эшкә өйрәткән кебек, китап укырга да баланы кечкенәдән өйрәтергә кирәк. Аннары ул гадәткә кереп китәчәк.

Күп язучылар, сәнгать кешеләре белән аралашып, әдәби мохиттә үстем. Кайсылары өебезгә кунакка килә, кайберләре белән иҗат йортында бергә ял итәбез. Туфан Миңнуллин, Миркасыйм Госманов, Равил Бохараев, Лев Ошанин, Юлиан Семеновлар...

ИСЕМЕМ – СӨЕМБИКӘ! Мин Мәскәүдә туганмын. Ул чакта Әдәбият институтында укучы әтием белән медицина институтында укучы әнием миңа Сөембикә дигән борынгы затлы исемне кушкан. Мин беркайчан да исемемне кыскартырга рөхсәт итмим. Дөрес әйтүләрен телим. «Ой, исемегез нинди матур, ул ничек тәрҗемә ителә?» – дип сорыйлар. «Яраткан хатынкыз!» – дим, горурланып. Кайберәүләр авырлык белән әйтә. Телефоннан сөйләшкәндә кайтарып сорыйлар. Мин хәрефләп кабатлыйм. Белгән кеше исемемнең мәгънәсен аңлый. Күп нәрсә кешенең эрудициясеннән, белеменнән тора бит...

КЫЗЛАРЫМ АКЫЛЛЫ. Олысы – Камилә, кечесе – Җәмилә. Мин аларны мөстәкыйль булырга өйрәтәм. Кайчан үз фикерләрен әйтерләр икән дип көтә идем. Уңышларыннан канәгать мин. Хәтта әниемә дә әйтәм: «Кара, Камилә белән Җәмилә тормыш сорауларына нинди дөрес чишелеш табалар», – дим. Камилә университетны «биш»кә генә тәмамлады, кияүгә чыкты, бала тәрбияли. Җәмилә КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына быел укырга керде. Аралашкан дуслары да тәрбияле, аларның эчке дөньялары бай. Минем инде хәзер Әмир исемле кечкенә оныгым да бар. Һәм ул... китаплар ярата! Мөгаен, гаиләдә китапка булган мәхәббәттән киләдер бу. Укырга керәген кечкенәдән аңлап үскәннәндер.

МАТУР БУЛУНЫҢ СЕРЕМЕ? ҮЗЕҢӘ ОШАРГА, ҮЗЕҢНЕ ЯРАТЫРГА КИРӘК БАШТА! Зарланмаска, вакланмаска, вакыйгаларны куертмаска, беркайчан да җебеп төшмәскә, максатлы булырга, сәламәтлегеңне кайгыртырга, заман белән бергә атларга... Үзеңне ничек күрсәтәсең, сине шулай кабул итәләр!

КАЗАН ИСКИТКЕЧ МАТУР! Европа шәһәрләреннән һич калышмый! Юллар, парклар, спорт корылмалары, тарихи-архитектура һәйкәлләре... Мондый шәһәргә, әлбәттә инде, Милли китапханәнең яңа бинасы да кирәк! Һәм ул шәһәрнең үзәгендә булырга тиеш! Ә бу затлы бинабыз да тарихи китапханә булып калсын. Ул бик тә уңайлы урында, матур бинада урнашкан. Борынгы кульязмалар, сирәк китаплар сакланса, уку заллары эшләсә, экскурсияләр үткәрелсә, чит ил туристлары бирегә борынгы китап үзәгенә килгән кебек килеп, аның гүзәллегенә сокланырлар. Китаплар байлыгы да, интерьер затлылыгы да әсир итәр аларны.

«МИН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ ЭШЛИМ!» Кая гына барсак та, бу сүзләрне аерым бер горурлык белән әйтәбез. Кайдан икәнебезне белгәч, безгә бөтенләй башкача карыйлар! Зурлап, аерым хөрмәт күрсәтәләр! Милли китапханә статусы шулкадәр мәртәбәле төшенчә икән. Аның дәрәҗәсе үзебезне дә күтәрә, исеменә һәм җисеменә лаеклы булып яшисе килә.

КИҢӘШ



- Балагыз кечкенә чакта ук аңа кычкырып китаплар укыгыз. Алар кызыклы, тылсымлы, маҗаралы булсын.
- Китапны сез ничек яратып укыганны алар да күреп үссен: аерым өзекләрне ятлагыз, әсәрнең эчтәлеген сөйләгез.
- Баланы китапханәгә ешрак алып барыгыз.
- Китапка аерым кадер-хөрмәт күрсәтегез: китаплар сатып алыгыз, аларны бүләк итегез.
- Китап, журналларны бала үзе сайлап алып укысын, өйгә аның исеменә килерлек итеп балалар журналларын яздыртыгыз.
- Укуны һәрьяклап хуплагыз: бүләккә яңа китаплар сатып алыгыз, театр, музейларга алып барыгыз, йокламыйча, озаграк китап укып ятса да, сүз әйтмәгез.
- Машинада йөргәндә әдәби әсәрләрне тыңлатыгыз – МР3-плеер алыгыз.
- Өйдә балалар китапханәсе булдырыгыз. Укып утырыр өчен бер уңайлы почмак та көйләгез.
- Фильмны караганнан соң, бала шул фильм нигезенә салынган әсәрне дә укып чыксын.
- Балагыз мавыккан дөнья (космос, маҗаралар, динозаврлар) турында китап, журналлар җыеп барыгыз.
- Кычкырып укуны хуплагыз, ул үз-үзеңә ышанычны да арттыра.
- Балага зур әсәрләр укыганчы, кечкенә хикәяләр уку яхшырак, аның төгәлләнгән ахыры була, ул канәгатьлек тудыра.

Күпләр өчен уку – тормышның алыштыргысыз бер өлеше. Кул астында китап булмаса, яллары да ял түгел. Андыйларга китап – кәеф чыганагы!

Кайберәүләр кул астына нәрсә эләгә, шуны укый: газета-журналлар, яңалыклар, хатлар... Күп вакыт ашык-пошык, аяк өсли генә. Укымаслар иде – эш өчен кирәк!

Халыкның бер өлеше укуны, гомумән, әһәмиятсез шөгыльгә саный. Әмма аларга да кайчакларда укырга туры килә. Зарурлык дигән нәрсә дә бар бит!



УКЫЙБЫЗМЫ? УКЫЙБЫЗ!

Без нәрсәгә кулыбызга китап алабыз? Укымыйча тора алмаганга, гадәтләнгәнгә, кирәк булганга... Күп укыган кешегә үз фикерләрен белдерү җиңелрәк, аның теле баерак – шуңа күрә ул башкалар өчен кызыклы әңгәмәдәш. Уку ул – уйлау дигән сүз: авторның фикерләрен үзеңә «йоктыру» яки аларга каршы чыгу. Укыган кеше һәртөрле яңа мәгълүматны тизрәк кабул итә, яңалыкка омтыла.


Барысы да чагыштырганда күренә: укуга мөнәсәбәт безнең илдә нинди үзгәрешләр кичергән? Ә дөньяда? Ир-атлар белән хатын-кыз икесе бер дәрәҗәдә укыйлармы? →

Даими укучы һәм сирәк укучыларның төрле илләрдәге өлеше (%, 2014)







Укырга яратучы ир-атлар һәм хатын-кызларның төрле илләрдәге өлеше (%, 2014)









Патша Россиясен белемле ил дип бик әйтеп булмый. Ул вакытта дворяннар, морзалар, буржуазия вәкилләре генә укыган.




Галимнәр, инженерларга ничек дан җырламыйсың: галәм киңлекләренә кеше юл алуында аларның өлеше бәяләп бетергесез.



Нефтькә бәя күтәрелә, Мәскәүдә зур вакыйга – Олимпиада... Нәрсәгә эшләп торырга – сузылып ятасың да рәхәтләнеп укыйсың гына!



Бандитлар хуҗа булган чор... Укуны иң мөһим нәрсәгә санийсың икән, димәк, син яши белмисең, булдыксыз...



Нибары инде... Аның каруы, бөтенләй укымаучылар саны азайды: күпләрне интернет ничектер үзенә җәлеп итә, кызыктыра алды.

PRESSA.RU









Фотолар интернеттан алынды

СОҢГЫ ТУКТАЛЫШ



Айсылу
ГАЛИЕВА

«ТУКСАН ЯШЬЛЕК ӘНИНЕ КЕМ БЕЛӘН КАЛДЫРЫРГА?» ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ ӘЛЛӘ НИЧӘ ЕЛГА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ЯЛГА БАРЫРГА ҖЫЕНГАН ИДЕ.

Әбигә күз-колак булырлык күршесе дә, туган-тумачасы да юк аның. Бертуганы башка шәһәрдә яши. «Үз өеңдә чит кеше калдырып китү дә кыен, әни кабул итәме әле аны, юкмы», – дип, тәмам аптырады ул. Ахырда, китәр алдыннан гына, олылар өчен пансионат табып, килешү төзеп, әнисен шунда урнаштырды.

Яулдан кайткач та, көн аралаш, эшкә кадәр кереп, әнисенең хәлен белеп чыкты. Өйдә чакта, бишенче каттан урамга тәрәзәдән генә карап яткан, дару эчәргә, хәтта ашарга кирәклеген дә онытa торган әби күзгә күренеп хәлләнгән, үзе кебекләр белән җырлашып, ишегалларын әйләнеп керә башлаган. Көне буе берүзе, сүз әйтергә дә тилмереп утырган карчыкка сөйләшергә «дус кызлар» да табылган...

Барып алыр алдыннан: «Их, тагын беразга калдырыр идем әнине, акча ягы чамалы, инде үзе тотып ашый да, дарусыз торырга да өйрәнеп килә иде, хәзер барысы да яңадан башланачак», – дип уфтанды хезмәттәшебез. Пансионатта тоту бәясе – кешенең хәленә, сәламәтлегенә карап, тәүлегенә мең сумнан артыграк икән. Әмма әнисен тизрәк өйгә алып кайтуының тагын бер сәбәбе – кеше ни әйтер, күрше-күлән ни сөйләр дип курку да бар иде. «Син бит аны ташламадың, ул да вакытлыча ял итә, үзең дә», – дип тынычландырдык без аны.

– Картлар йортында кемнәр тора дип уйлыйсың син, сеңлем? – дип каршы алды мине Арча картлар йорты директоры Мулланур Гыйләҗиев. – Кереп таныша башлаганчы, шул сорауга җавап бир әле. Биш ел элек, монда килеп эшли башлаганда, мин дә шулай уйлый идем. Ак яулыклы әбиләрдер дип... Юк, андыйлар бирегә килми, сеңлем. Әнә кергәндә ике кулсыз абзыйны очраттың. Бик кызгандың син аны, аңлыйм. Бернинди сугышта да катнашмаган ул. Исереп йоклап кулын өшеткән. Менә шундыйлар биредә...

Сүзсез калуымны сизеп, Мулланур Габделнурович сүзне икенчегә борды:

– Әйдә, сеңлем, бүлмәләргә кергәнче, мин сиңа башта ишегалдыбызны күрсәтим әле.

Бизәкләп эшләнгән капкалы, фонтанлы, шау чәчәккә батып утырган йорт ишегалдына килеп кергәндә: «Әллә адресны бутадыммы?» – дип уйлаган идем. Юк, ялгышмаган булып чыктым. Мулланур әфәнде беседкаларын да, теплицаларын да, хәтта тәмәке тартучылар өчен махсус ясалган болдырларын да күрсәтте.

Арча картлар йортында 50 кеше яши. Шуның 21 е – хатын-кыз, 29 ы – ир-ат. Урын өстендә ятучылар ундүртәү икән. Бюджет оешмаларын автономияле оешмага әйләндерү җилләре картлар йортларын да читләтеп үтмәде. Аларга да бүген акча эзләргә өйрәнергә кирәк. Ләкин ничек итеп? Көнкүреш, медицина хезмәтләрен ничек түләүлегә әйләндереп була соң картлар йортында? Күз алдына китерү кыен... Мулланур Габделнурович белән шул хакта сөйләшәбез. «Юньле табибым булса, стоматология кабинеты ачып, халыкка түләүле хезмәт күрсәтер идем, ләкин юньле табиб монда килмәячәк, – ди директор. – Кер юу өчен шартларым бар, тик аның белән дә өстәмә табышка өметләнеп булмый – хәзер бөтен кешедә дә автомат кер юу машинасы». Теплицалары бар икән. Әмма анда да нидер үстерү өчен биредәге карт-карчыкларны тәрбияләүче хезмәткәрләр көч түгәргә тиеш. Кергәндә миңа очраган кулсыз бабай да, ике аягын өздергән 43 яшьлек ир-ат та, башкалар да казынмый ул теплицада. «Безне дәүләт карарга тиеш», – дип, монда кергән абзый-апалар да, кулларыннан килсә дә, бер-ике тапкырдан артык чыгып аяк басмаган анда. «50 кешенең бары берсе генә тик тормый, төп ярдәмчем ул», – дип, ихатада йөргән И.га күрсәтә директор.

Акча эшләүнең тагын бер юлы – түләүле палаталар тоту. Түләп яшәүчеләр монда дүртәү. Кайсыныңдыр үз пенсиясе җитеп бара икән, кайсын, өендә урыны, карау өчен шартлары булмауны сәбәп итеп, баласы китергән. Шундыйларның берсе – Фәридә әби. Ленинград блокадасыннан исән чыккан, Советлар Союзының төрле шәһәрләрендә яшәгән карчыкның яшәү урыны әлегә монда. Ни өчен әлегә? Әби бер ел элек егылып аягын сындырган, кызы эшли, оныгының яңа туган яшь балаларын да карарга кирәк. Шуңа күрә Фәридә әбине, аягына басканчы дип, бирегә китергәннәр. «Түләүле бүлектә торучыларны онытмыйлар, балалары шалтырата да, килә дә, безнең эшне дә карап-күзәтеп торалар», – ди монда эшләүче апалар. Эшләренә тел-теш тидереп була торган түгел: һәр җирдә чисталык, ятып авыручылар бүлмәсендә була торган авыр ис тә артык сизелми. Картлар йортында инде 13 ел эшләүче Мөршидә апа: «Җиңел түгел: яшь баланы ничек карыйсың, шулай тәрбиялибез аларны да. Памперсларын да алыштырабыз, тырнакларын да кисәбез. Атнага бер тапкыр мунча да кертәбез», – дип сөйли. Сокланырлык та, гаҗәпләнерлек тә. Бер авыру турында гына сүз бармый бит, урын өстендәгеләр 14 кеше монда! Картаеп, бәвелен тота алмаучылар да бар, белепме, белмичәме, син җыештырып чыкканны пычратып куючылар да, идәнгә түкереп ятучылар да...

Һәр бүлмәдә бер-берсенә охшамаган икешәр, өчәр язмыш...

Директор белән бүлмәләр буйлап йөрибез. Синең кергәнне шатланып каршы алып, тыңлаучы булганда күбрәк сөйләп калырга теләүчеләр дә, акылы китеп, сабый өммәтендә калганнар, сиңа игътибар итми үз эше белән мәшгульләр дә, һәм киресенчә, таный күрмәсеннәр дип, фотога төшерүдән куркып, йөзен яшереп утыручылар да бар монда... Гаилә корудан сугыш мәхрүм иткән, гомер буе эш дип яшәгән, картлыгында беркемгә кирәге калмаган 90 яшьлек әбиләр дә, аларның оныгы яшендәге, аракы белән дуслашып, йортҗирсез калып, инвалидка әйләнгән ирләр дә очрады...

БЕЛЕШМӘ.

■ Татарстанда 28 картлар һәм инвалидлар йорты бар, аларда бүгенге көндә 1801 кеше гомер кичерә. Картлар йортларының икесе кайчандыр җәмгыятьчелек өчен куркыныч булган – төрмәдән чыкканнарны кабул итә.

■ Бөгелмәдә, Чаллыда, Казанда торыр урыны булмаган, авыр хәлдә калган кешеләрне кабул итү үзәкләре эшли.

PRESSA.RU

Әбиләр гомер буе илгә бик бөккән, ярый инде, кулларыннан эш киткәч, дәүләт ташламаган үзләрен. Ә бит җәмгыятькә бер файда да китермичә, үз язмышын үзе җимергәннәргә дә урын шушында. Һәркайсының соңгы тукталыр урыны – картлар йорты... Һәр икесенә дә тәүлегенә якынча 480 сум акча бирә дәүләт. Дөресме соң бу? Ахыр чиктә дәүләт сине барыбер ташламаса...

Бүген Арча картлар йортына 7 кеше чират көтә икән. Бу сүз нәрсәне аңлата соң? Рәхимсез тоелыр, әлбәттә, ләкин... картлар йортыннан беркемне дә өйләренә алып китмиләр – балалар йорты түгел бу. Бирсдән соңгы юл бары тик зиратка гына илтә. Димәк, чираттагылар биредәгеләрнең вафатын, урын бушатуын көтә...

Кемдер әтисен яки әнисен үзе ялга киткәндә кыска вакытка гына калдыра, кемдер урын өстендә яткан туганнарын озаккарак китерә.

Бик авыр хисләр белән киттем Арчадан... Әйе, шартлар әйбәт, картлар йорты хуҗалыгы көлеп тора. Тик тормыш сынаулары шушы йортка китергән әбиләрдән бигрәк, үз язмышын үзе җимергән гарипләр әрнетте мине. Советлар заманындагы кебек әрәмтамаклык өчен җавапка тарту бүген дә дәвам итсә, бәлки, хәлләр башкачарак булыр иде? Думада артык мал асрау, балык тоту яки башка акылга сыймаслык нәрсәләр турында законнар кабул итеп утырганчы, депутатларыбызга, бәлки, менә шушындый социаль проблемалар турында уйларга кирәктер. Мәктәп, уку йортын тәмамлагансың икән – рәхим ит, эшкә урнаш. Өйдә әти-әни тапканны ашап, вакытны кая куярга белми, эчеп-тәртипсезләнеп йөрмә. Югыйсә ахыры билгеле инде – йә төрмә (анда да дәүләт җилкәсендә яшисең), йә шушы Алексей кебек, 42 яшьтән инвалид калып картлар йортына эләгәсең...

Хезмәттәшем сайлаган пансион картлар йортыннан нәрсә белән аерыла икән дип кызыксынып, әлеге пансионны эзләп киттем. Резиденциянең хуҗалары бертуган Сергей белән Андрей Ощепковлар иң элек офисларына дәштеләр.

– «Картлар йорты» дигән стереотип бездә тискәре мәгънәгә ия. Мин ул сүзне яратмыйм, – дип башлады сүзен Андрей. – Бездә балалары ташлаган әтиләр дә, әниләр дә юк. Әйе, моңарчы дәүләт кенә шөгыльләнгән эшкә алындык – анысы бар. Ләкин безгә кадәр дә ябык типтагы андый пансион Казанда бар иде – гадәттә, алар аерым фатирлар арендалап торалар, вакыт-вакыт күчеп тә йөриләр. Ятып авыручыларны, үз-үзләрен карый алмаучыларны караучылар (сиделкалар) хезмәте дә бар. Безнең өстенлек – шәһәр читендә, саф һавада үз йортыбыз бар, картлар һәрдаим күзәтү астында. Үз ишләре белән аралашалар, ишегалдына чыгып һава сулыйлар, туганнары белән күрешеп торалар. Ничек бу эшкә алынырга уйладыкмы? Әбиебез Амалия без белә-белгәннән бирле ялгыз яшәүче бер ахирәтен карады. Башта аңа өй эшләрендә булыша иде, аннары, ул аягын сындырып, урын өстенә калгач, гел янында булды.

Германиягә баргач, без андагы шушындый йортлар белән кызыксындык, Питердагы, Мәскәүдәге хосусый пансионатлар эшен өйрәндек. Ачылганыбызга елдан артык. Ихтыяҗ бар, урыннарыбыз тулы. Бер йортыбызда – 26, икенчесендә 22 кеше яши. Картлар, гадәттә, уңайсыз егылып, бот сөяген сындыра бит. Альцгеймер белән авыручылар, картаеп, акылы җиңеләйгәннәр шактый бездә. Алар үзләре өчен дә, тирә-күрше өчен дә куркыныч тудыра – ялгыз булмасыннар дип, балалары, оныклары аларны монда китерә. Уллары яки кызлары чит илдә яшәгән әти-әниләр дә бар бездә.

Йөз кат ишеткәнче, бер күрүең хәерле. Шәһәрдән 20 чакрымдагы бистәне дә, нарат урманы кочагына кереп утырган әлеге йортны да җиңел таптым. Капкадан керүемә каршыма бер әби йөгереп чыкты: «Тукта, япмагыз, оныгым килә, каршыларга чыгам!» Сергей: «Апа, оныгың килгәч, үзе шалтыратыр, сабыр ит», – дип, аны җитәкләп, кире борды. «Җитен комбинаты монда гына, өемә кайтам», – дип, һаман үзенекен сөйләгән әби Казанның бөтенләй икенче почмагында икәнлеген әллә оныткан, әллә белмәгән дә...

Пансионатның беренче катындагы ике бүлмәдә аягында йөри алмаучылар ята. Яннарында туганнары утыручылар да бар. Икенче катта – дүрт бүлмә. Каяндыр җыр яңгырый: «Надежда, мой компас земной...» Әбиләрнең яшь вакытындагы көйләр! Сергей, баскычтан менгәндә үк мине кисәтеп куя: «Алар барысы да диярлек Альцгеймер белән авыручылар, гаҗәпләнмәгез».

Каршыга йөгереп диярлек бер әби килде: «Ой, сез безнең янгамы, әйдәгез, рәхим итегез!» Нина түтәй шунда ук үзләренә узарга чакырды. Бүлмә саен бишәр карават. Картлар йортыннан бигрәк, пионер лагерена охшаган. Сергей аркаларыннан сөеп, һәрберсенең хәлен белешә, әби-бабайлар шат, йөзләрендә елмаю, бакча балаларын хәтерләтәләр: «Ай, шундый матур кыз!», «Безгә эшкә киләсезме?» Сергей холлдан икенче бүлмәгә әйдәкли. «Безнең менә шушы бабай гына аек акыллы монда», – дип таныштыра. Лазарь бабай – Бөек Ватан сугышы ветераны. Аның кызы чит илдә, әтисен үз янына алдырырга документлар да әзерләгән, тик бабайның туган-үскән җиреннән китәсе килми. «Мин монда ялгыз түгел, бик канәгать», – ди ул.

«Мин сөйлим япон белән кытайны, син сөйлисең Хәмдениса түтәйне», дигән гыйбарә мондагы әби-бабайларга бик тә туры килә. «Тыңлап торсаң, күп вакыт икесе ике нәрсә турында сөйли аларның, берсен-берсе аңламыйлар да, әмма аралашуга, тыңлаучы булганга ике як та шат», – ди Сергей. Үземне бер мәлгә киногa эләккән кебек хис иттем. Матур декорацияләр, катнашучы геройлар – көнбатыш пансионнары турында күптән түгел караган «Яшьлегем көндәлеге» фильмын хәтерләтте. Анда да Альцгеймер авырулы, хәтерен югалткан апа-абзыйлар балачакларының иң җете мизгелләрен искә төшерә... Беренче каттагы кунак бүлмәсендә (үз аякла-

рында йөрүчеләр өчен ашханә дә шунда ук) агылучы моңсу көй дә әлеге хисне көчәйтә. Каршыга тагын Хәят апа очрый. «Ачыгыз капканы, өемә кайтам, монда – җитен комбинаты янында гына торам», – дип инәлә ул.

– Курыкмагыз, монда башкаларга зыян сала торган агрессив картлар юк. Кабул иткәндә, без аларны махсус тестлар ярдәмендә тикшерәбез, кискен психик тайпылышлары булганнарны алмыйбыз, – ди Сергей. (Читкә китеп булса да әйтим, андыйларны Казандагы бер клиниканың геронтология бүлеге кабул итә, бәясе – тәүлегенә якынча 2500 сум.)

Кухняга юнәләбез. Шунысы бар: биредә ашарга үзләре әзерләмиләр. Килешү буенча, ризыкны бер фирма әзерләп китерә. Көненә биш тапкыр ашату каралган. Теләгән кешегә чәй кайнатып бирү, коктейльләр ясау мөмкинлеге бар. «Олылар, балалар шикелле, татлыны ярата», – дип көлә Андрей. Ул үзе генә түгел – ниһаять, Хәят апаның өзелеп көткән оныгы килгән. Әле оныгына, әле аның юлдашына нәрсәдер сөйләгән әбигә карау кызык та, кызганыч та... Онык кай ара бер-ике сүз белән нәрсәдер әйтеп куя, ә юлдашы, Хәят апа аңа борылып нидер әйткән саен: «Я вас не понимаю, не знаю ведь по-татарски», – дип елмая. И Ходаем, мондый картлыкны насыйп итмә, балаларымны, оныкларымны телебездән аерма...

Коммерцияле оешманың – үз борчулары. Ашыгыч ярдәм чакырган вакытларда, картларны алып китәселәре килми, юлда ул-бу булса, дип куркалар, диләр. «Хәле авырлашкан бер бабайны хастаханәгә җибәрү өчен җан талаштык», – дип искә төшерә Андрей. «Без медицина оешмасы түгел. Табиб ярдәменә мохтаҗларны, психик тайпылышлары булганнарны алмыйбыз. Дөрес, атнага бер-ике тапкыр табиб килә безгә, карый, киңәшләрен бирә. Хәлләре начарланса, туганнарына шалтыратып, хастаханәгә салырга кирәклеген әйтәбез. Исәбебез – түләүле ашыгыч ярдәм хезмәте белән килешү төзү. Аннан әби-бабайларның хәлен карап-күзәтеп торырга психолог-аниматор эзлибез».

Күзәтү дигәннән, ул монда адым саен. Һәр бүлмәдә, һәр борылышта «балык күзе» дигән видеокамера тора. «Язмаларны үзебез дә күзәтәбез, сорасалар, клиентларыбызга да карарга бирәбез», – ди Сергей.

Кешенең үз якыннарына, һәрдаим аларның игътибарына мохтаҗ булуына инандым.

Әйе, хезмәт күрсәтү кайда да бер чама: картлар йортында да, түләүле пансионатта да барлык социаль-көнкүреш хезмәте, гигиеник процедуралар үткәрелә. Тегендә дә, монда да урын-җир чиста, бүлмәләрдә тәртип, хезмәткәрләр игътибарлы. Картлар йорты дәүләт күзәтүе, кайгыртуы астында, ә пансионат клиентлар саны өчен үзе көрәшә – тискәре имидж бу очракта файдасыз. Барып күргәнче, пансионаттагы картлар бәхетлерәк кебек тоелган иде. (Туганнары, балалары хәлләрен белеп, яннарына килеп тора бит!) Әмма өемә кайтам дип өзгәләнгән, оныгы белән күрешүгә балаларча куанган Хәят апаны, мин пансионатта уздырган берничә сәгать эчендә урыннан купмыйча, инвалид коляскасында китап укыган булып уйланып утырган Зәлифә апаны күргәннән соң, фикерем үзгәрде.

Әтиемнең әнисе, инде күптән мәрхүмә әбекәемнең ерактан кайткан бер туганыбызга сөйләгән сүзләренең мәгънәсенә яңа төшендем. «Әбекәй, мин киттем, дип чыгып китәләр, хәлең ничек, дип кайтып керәләр. Тагын ни кирәк?» – дип сөйләгән иде ул. Шушы гади генә, гел әйтелә торган ике җөмләгә әбекәй нинди зур мәгънә салган булган икән!

P. S. Әби-бабайларның исемнәре үзгәртелде.

СҮЗ УҢАЕННАН.



■ Яшьләр дөнья куа – аларның иркенләп сөйләшеп утырырга беркайчан да вакытлары юк. Ә өлкәннәр исә һәрвакыт аралашуга мохтаҗ... Петрозаводск шәһәрендә башланып киткән гадәти булмаган геронтоволонтерлык хәрәкәте шушы бушлыкны тутыру өчен уйлап чыгарылган да. Өлкән яшьтәге карт-карчыклар бер-берсенә ярдәм итә анда. Картлык һәркемгә дә бертөсле килми: гомер исәбе күп булса да, һаман да актив тормыш рәвеше алып баручы әби-бабайлар да бар бит ул. Юк, алар чордашларының өен җыештырмый, дару алып кайтмый, кибеткә йөрми. Боларын – социаль хезмәткәрләр башкара. Ялгыз яшьтәшләре янына алар исә сөйләшеп утырырга, хатирәләр яңартырга, гаилә альбомындагы фотосурәтләрне бергәләп карарга, ил-көндәге соңгы яңалыкларны уртаклашырга килә.

■ «Бәбиләргә – әбиләр» проектының да төп максаты – пенсия яшендәге өлкән хатын-кызларга аларның җәмгыятькә һаман да кирәклеген искәртү. Дәү әни-дәү әтиләре үзләреннән ерак та яшәгән яшь әти-әниләр каядыр барып киләсе булганда, кечкенә балаларын рәхәтләнеп шушы әбиләр янында калдырып тора ала. Проектта катнашучыларның күбесе – элеккеге укытучылар, табиблар, социаль хезмәткәрләр. Үз оныклары булмаган яки алар белән әвәрә килүдән мәхрүм хатын-кызлар өчен дә, әби назы күрмичә үсүче оныклар өчен дә мондый аралашу бик кирәк дип саный белгечләр.

PRESSA.RU









Туфан МИҢНУЛЛИН

ТАТАР КЫЗЫ

Танылган җәмәгать эшлеклесе, журналист, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитулловага багышлыйм.

АВТОР.

Бу язмамны ике бала анасы, ир хатынына багышласам да, мин аны «Татар кызы» дип атадым. Чөнки татар кызы дигән сүз минем өчен, җыелма образ буларак, тирән мәгънәгә ия. Татар кызы, дигәндә мин һәрвакыт инсафлы, чибәр, акыллы, пөхтә, чая, сабыр, өзелеп ярата һәм яраттыра белгән асыл затларны күз алдыма китерәм. Мин аларның ничә яшьтә икәнлекләрен санамыйм. Дөньяга күзен тутырып сокланып һәм исе китеп карар яшькә җиткән япь-яшь гүзәлләр дә, тормыш арбасына җигелеп җир шары өстеннән горур атлаучы затлы ханымнар да, заманның хәсрәт-кайгыларын, куаныч-шатлыкларын күңелләренә сыйдырып олыгайган мөлаем апалар да – барысы да минем өчен татар кызы.

Татар кызы! Тарих сәхифәләрен кат-кат актарып, Синең язмышың турында уйлаганда, Сиңа сокланып туя алмыйм. Әнә Син ат өстенә менеп алгансың да, ирекле кош булып, иксез-чиксез далалар буйлап җилдерәсең, әнә иң текә тауның иң биек түбәсенә баскансың да, илеңнең иминлеге сагында торасың. Синең ирең, Ил башы тәхетендә утырып, ил агалары белән, чит мәмләкәттән килгән илчеләр белән дөнья хәлләре турында сөйләшкәндә, бәхәсләшкәндә, Син аның янәшәсендә утыргансың да акыллы киңәшләреңне биргәнсең. Син ханбикә булып Ил белән үзең идарә иткәнсең.

Татар хатыны изелгән, мәсхәрәләнгән, иренең телсез колы булган, дип сөйлиләр икән, ул – дошманнар гайбәте. Сине һәм Синең йөзеңдә милләтне түбәнсетү өчен уйлап чыгарылган яла.

Син һәр чорда татар гаиләсендә әхлак нигезләрен саклаучы хуҗа булдың. Ирне ир итә белү серләрен Син тумыштан ук белә идең. Шуңа күрә башка милләтнең бик күп зыялы ирләре Синең кулыңны сорап еш килделәр. Син аларга даһилар үстереп бирдең. Кызганыч, әмма Синең бу бөеклегеңне кайбер милләтләр оныталар. Югыйсә алар Сиңа һәйкәл куярга тиешләр иде.

Син. Татар кызы, беркайчан да надан, томана булмадың. Үзең укымышлы булдың, балаларыңны укымышлы иттең. Нарасыйның бишеге янында: «Үсеп буйга җитәр бу, мәдрәсәгә китәр бу», – дип бишек җыры көйләдең. Балаңны укытып кына кеше итү турында уйладың. Татар кызлары яшьтән үк укытучы булырга хыялланып үстеләр. Кайларда гына, кемнәрне генә укытмадылар татар мөгаллимнәре!

Татар кызы! Син ифрат сәләтле зат. Син – шагыйрь, Син – галим. Кулыңа каләм алсаң, ак кәгазьдә искиткеч шигырь юллары сузылып кала. Хикәя, повесть, романнар, публицистик уйланулар, фәнни хезмәтләр дөньяга пәйда була. Аларның барысы да ихлас күңел, чиста кул белән иҗат ителгәннәр. Син хәрәмләшә белмисең.

Татар кызы! Син төрле дәрәҗәдәге мөнбәрләргә менеп, үз сүзеңне өзеп әйтә беләсең. Әйтер сүзең бар, Синең дөньяга үткен, зирәк фикерең бар.

Бигрәкләр дә чибәр инде Син, Татар кызы! Зинһар өчен үз кадереңне үзең белә күр. Синең тирәңдә бик күп аучылар сагалап тора. Ә аучылар бары тик затлы кошларны гына аулыйлар.

Татар кызы! Мин Синең сәхнә уртасына басып җырлаганыңны тыңларга яратам. Кайвакыт син, бүтәннәргә охшарга тырышып, кыланып та куясың. Ләкин барыбер итагатьле Син. Бөтерелеп алуларыңда да Сиңа гына хас нәфислек, горурлык бар. Күңелең тулы моң Синең. Хәтта кайбер ирләр язган моңсыз, мәгънәсез такмакларны да «адәм рәтле» итеп җырлыйсың.

Татар кызы! Синең колагыңа гына әйтерлек әрнүле сүзләрем дә бар минем. Ләкин мин аларны әйтеп, күңелеңне яралыйсым килми. Минем өчен аларны сиңа әдәпле, аңлаешлы, акыллы, үтемле әйтә белүче затлы кызларыбыз бар. Шуларның берсенә багышладым мин бу язмамны. Иң изге теләкләремне телим мин аңа!

«Ватаным Татарстан», 14 октябрь, 1995 ел.

КЫР ҮРДӘКЛӘРЕ КАЯ ТӨШӘ?

НӘҖИП ДУМАВИ, ХӘСӘН ТУФАН, ГАЗИЗ КАШАПОВ, ӘНВӘР ХӘЙРИ КЕБЕК ОЛПАТ ӘДИПЛӘР ТУДЫРГАН АКСУБАЙ ТӨБӘГЕ КЫЗЫНЫҢ ЯЗУ КУӘТЕН УЛ ЧАКТА УК ЧАМАЛАРГА МӨМКИН ИДЕ ИНДЕ.



Нәбирә
ГЫЙМАТДИНОВА

Ә Роза ханымның холкы бүтәнрәк шул: кайберәүләр үзенә йөкләнгән бурыч-вазыйфасын өстән-өстән генә, йөрәгенә кагылдырмыйча гына башкарганда, ул камиллекнең иң соңгы ноктасына омтылгандай, тулысы белән эшкә батты.

Ак ана

Чәчәккә төренгән бакчаның уртасында ташлар белән каймаланган нәни генә сулыкка, кара көзләр җитте исә, кыр үрдәкләре очып төшә. Ерак сәфәргә кузгалганда кошлар монда туктап канат ялы ала, күрәсең. Мөгаен, Казан читендәге бистәнең бу аймагында борын-борын заманнарда астан чишмә типкән күл булгандыр да, вакытлар үтү белән ул кибеп-корып беткәндер. Ә хәтер дигәнең онык-үрдәкләргә бабаларыннан күчкәндер, бу ике канатлы туганнарыбыз адәмнәр кебек хәтерсезлектән интекми. Ничек хыялның чабуыннан тартасың, ди, көннәрдән бер көнне җир куенына поскан су могҗизасы, йорт хуҗаларын шаккаттырып өскә ургылыр кебек. Нигә мин язмам башында ук тора салып чишмә турында сөйлим, ди, әле? Моның серен сез соңрак аңларсыз. Табигатьтәге кебек үк кеше күңелендә дә чишмәләр бар: шуларның берсе – иҗат чишмәсе. Кемнеңдер ул челтер-челтер ага, ә кемнеңдер, юл сапкач кына, кинәт билгесезлектә югала. Якташым Роза Туфитуллова белән дә тәүге мизгелләрдә шулай булды дип беләм. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлап журналистика өлкәсен сайлаган һәм Галиҗәнап каләм белән матур-матур язмалар әзерләгән, алай гынамы, сугыш елларында татар авылы сыендырган ятимнәр – 40 латыш баласы турында «Олы Мәңгәр – гомер бишегем» исемле китап бастырып өлгергән талант иясе капылт кына язу-сызу эшен читкә этәреп, муеннан җәмәгать эшләренә күмелә башлагач, бәлкем, көнчеләр сөенгәндер (конкурент бит!), бәлкем, дуслары көенгәндер. «Яшь ленинчы» газетасына баш мөхәррир итеп билгеләнгәч тә, каләм йөгертер өчен әз генә вакытны «чеметсә», аны берәү дә гаепләмәс иде. Ләкин кеше язмышлары җанын әрнеткәндә ничек түзеп утырасың, ди. Студент сабакташы, шагыйрь Зөлфәт, әнә, эшсез каңгырап йөри. Журнал таләп итеп театр бинасыннан листовкалар ташлаганнан бирле аңа органнар кырын карый. «Безгә кил», – дип Зөлфәтне чакырып китереп, эшкә урнаштырган көнне үк погонлы адәм редакциягә килеп баш мөхәрриргә җикеренә. «Приказны ертып ташла! Маликов матбугат тирәсендә чуалмаска тиеш!» Әмма Рәхмәтулла кызы коелып төшми, шагыйрьне яклап, югары ишекләрне шакый. «Иң бәхетле елларым «Яшь ленинчы» белән бәйләнгән», – ди Роза ханым, һәм мин эчтән генә елмаям. Һе, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Нияз Акмал, Ркаил Зәйдулла кебек әдәбият арысланнары белән көн саен аралаш әле син! Аларның һәркайсы бөеклек каланчасына кунаклаган. Төрле чак булгандыр анысы, әмма егетләр беренче чиратта Роза ханымда нәзакәтле хатын-кыз күргәндер, аны апасы, сеңлесе яисә әнисе белән чагыштырып хөрмәт иткәндер. Университет елларында ук Мөдәрриснең рухи тоткасы, илһам учагына ут өстәүче Роза ханым иде, диләр! Бу хакта соңрак мин шагыйрьнең үз авызыннан да ишеттем. Тулай торак. Төн. Студентлар йоклый. Шаку-нитү юк, бүлмә ишеген аяк белән генә этеп ачалар: «Роза, тиз, яме!» Кыз, халатын бөркәнеп, коридорга чыкса, кулындагы дәфтәр битен «җилләтеп» Мөдәррис басып тора.

Ике арбаның берсенә чеметем генә, икенчесенә өеп-өеп йөк тутырсаң, ул һичшиксез авыррагын тартыр иде.

– Әле генә яздым. Карасы да кипмәде. Тыңла, өр-яңа шигырь!

– Ул мине сердәше ясады, – ди Роза ханым. – Әнисе үлгәч, аны бертуган апасы тәрбия кылган, шигырьләрен укып үсендергән, мине Мөдәррис шул апасының дәвамы итеп санады. Мин «булган бу, Мөдәррис!» – дип канатландыра идем. Тәнкыйтьләргә ярамый, чөнки ул гений!

Соңгы сүз ихлас ярату белән әйтелә.

PRESSA.RU

Роза Туфитуллованы «Ялкын», аннары «Азат хатын» журналына «баш» итеп куйгач, каләм, әлбәттә, тагын елап калгандыр. Яңа хыяллар, яңа мәшәкатьләр... Исеме җисеменә туры килсен дип, хатын-кызларның бердәнбер газиз басмасын ханбикәбез Сөембикә исеменә алмаштырулар, милләт дип, татар хатын-кызлары дип янган тынгысыз җанына өстәмә мәшәкатьләр алып, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар ассоциациясен оештырулар... Куелган максатка ирешә президент Туфитуллова: меңәрләгән-меңәрләгән хатын-кызларыбызны берләштергән чисталык, сафлык символы «Ак калфак» дөнья күләмендә танылып, абруй казана.

Урыны, дәрәҗәсе белән беркайчан да масаймады ул.

Хатларга күз салыйк әле:

«Кадерлебез Роза ханым! Казаннарда сагынырлык кешеләребезнең берсе булуыгызны беләсездер дип уйлыйм. «Ак калфагыгыз»ның шаукымы Уфаларга да килеп җитте. Мин моңа шәхсән бик сөенәм. Дөньяларны аклыкка күмик әле бергәләп. Ник сагынучы Фәридә апагыз Кудашева.

15.10.1995 ел.»

«Мөхтәрәм Флора ханым! «Гыйффәт туташ» тамашасын карагач, «Ак калфак»ның нинди юнәлештә эш алып баруын аңладым. Сезнең җитәкчегез Роза ханым ак әбиләр токымыннан булса кирәк. Хатын-кызның җанын үтә дә нечкә тоя белү, аңа терәк булырга омтылу, изге эшләргә рухландыру аның бөтен күңелен биләгән. «Ак калфак»ка ак юллар телим. Әмирхан Еники.

28.11.1992 ел.»

«Кичә радиодан чыгышыгызны тыңлап хәйран калдым. Күңелегезнең кайсы төпкелендә саклана ул затлылык? Борынгылыкны тою, шуны йөрәк белән ярату? Сез чын мәгънәсендә заманыбызның «ак анасы!» Хәйдәр Бигичев.

3.03.1990 ел.»

«Чуманны онытып калдыра күрмә...»

Ак ана... Нинди төгәл билгеләмә! Моны раслар өчен унарлаган мисалдан берсен генә бәян итәм.

1999 елда Роза Рәхмәтулла кызы ТР Дәүләт Советы депутаты булып сайланып, даими комиссиядә эшләде. Сессия бара. «Татарстан балалары» программасына билгеләнгән 100 миллион сум акчаны кисеп, спирт заводына бирмәкчеләр. Шунда Роза Туфитуллова сикереп тора да, күзенә яшь тыгылып, кыйсса сөйләргә тотына. «Бер кеше картайган атасын чуманга (чанага) утыртып урманга илтеп ташларга җыена икән. Капкадан чыгып барганда моңа малае эндәшә: «Әти, бу чуманны онытып калдыра күрмә, сине дә шуңа салып илтергә туры киләчәк», – ди икән». Зал тып-тын кала. Депутат ханым дәвам итә: «Әгәр бүген программаны кыскартсак, белегез, киләчәктә моның кайтавазы үзебезгә кайтачак! Нинди вөҗдан белән ятим балалар ризыгын өзеп, исерекләр санын арттырмак кирәк!» Рәхмәт, Татарстанның ул вакыттагы Президенты Минтимер Шәймиев аңа теләктәшлек күрсәтә, акчаның яртысы ятимнәргә бүленә. Казанда беренче татар кызлары гимназиясе ачканда да Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев кебек гаярь ир-егетләребез янәшәсендә «Ак ана» булды. Ярлыкау комиссиясендә 12 ел буе йөзәрләгән ватылган-җимерелгән язмышлар белән күзгә-күз очрашып, төрмәгә эләккән ничәмә-ничә хатын-кызга гаиләсенә кайтырга булыша ул. Рәхмәтеме? Җирдә бер генә изгелек тә эзсез югалмый, уң җилкәдәге фәрештәләр шунда ук гамәл дәфтәренә терки. Безгә бит әле «Мәңгелек йорт»ка күченгәч тә җавап тотасы. «Җитәр, җәмәгать эшләреннән арынып, Роза апа язсын инде», – дип теләгәндә генә аны 2006 елда Россия Иҗтимагый палатасы әгъзасы итеп сайладылар. Әлбәттә, бик лаек кандидатура! Әмма каләм хакы да бар лабаса! Язды ул, язды анысы. Мәдәни һәм рухи мирасны саклау комиссиясенең әгъзасы буларак, татар мәдәнияте, милли гореф-гадәтләре, әдәбияты турында зурлап-олылап докладлар язды, югары трибуналардан сөйләде. Биредәге актив эшчәнлеге өчен 126 кеше арасыннан «Иҗтимагый танылу» Алтын Мактау билгесе белән дә бүләкләнде ул. Россия Мөфтиләр шурасы аңа «Рухи берләшү өчен» дигән медаль дә тапшырды. Бүләкләр дигәннән, Роза апа аларга бер дә кызыкмады, миңа бирегез, дип, юллап чапмады, бердәнбер «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә бик канәгать. Әгәр дә мәгәр «Татар кызы» дигән бүләк уйлап чыгарсалар, иң әүвәл ул Роза Рәхмәтулла кызына бирелсен иде. Нигезләмәсе әзер, аны Туфан Миңнуллин күптән язып калдырды. Роза ханымның сыйфатларын чагылдырган әлеге багышлама барлык татар хатын-кызларына васыять кебек тоела.

Каләм һәм бәхет

Әй, каядыр яшеренгән иҗат чишмәсе! Үткенлеген еллар да җуймаган каләм, ниһаять, аны төптән казып чыгарып, челтерәп аккан тавышын кабат дөньяга ирештерде. «Бәйлисе бар йөрәкне» дип аталган китабын бастырып, Роза Туфитуллова һәммәбезне биһуш итте! Шагыйрь Хәсән Туфанның иң садә хисләре белән өртелгән әсәр язучының зур табышы иде. Китап берүне дә битараф калдырмады. Күпләрне тәнкыйть утына тоткан Миргазиян Юныс аны болай бәяләде:

«Роза ханым! Каләм кыймылдатучыларга илһам, иҗат бирә торган онытылмас нәширә! «Бәйлисе бар йөрәкне» алган көнне, төнне һәм тагын икенче көннең төш вакытына кадәр, ашарга туктап, тәнәфессез, ялсыз йотлыгып укып чыктым. Нәрсә тетрәндерде мине? Полиграфик нәфислек, Аксубайның нәзберек талантының тулысынча чагылышы, әсәргә җан өрә алуы. Хәсән абыйның иҗатына моңа кадәр кулланылмаган яңа позициядән, саф күңел белән карап, шаб-

лонга, комфортлык хастасына баш бирмичә, гаҗәеп төгәл ихласлык белән язылганлыгы. Туган авылы, авылдашлары, кардәш-ыруы фонында шагыйрьнең күп кенә эчке сыйфатлары, аның әдәбиятыбызда сирәк очрый торган үзенчәлекләре ачыла...

21 июнь, 2012 ел, Мәскәү–Алехново».

Рәссам Рифкат Вахитов әсәрне укыгач, шунда ук кулына кылкаләмен ала:

«Хөрмәтле Роза ханым! «Бәйлисе бар йөрәкне» дигән китабыгыз мине чиксез тетрәндерде. Аны укып чыгу белән эшкә тотындым. Бөек Туфаныбызның йолдызлы дөньясын мин менә шулай күрдем. Белмим, ошармы ул Сезгә? Мин аны Сезнең ак күңелегезгә багышлыйм.

Ноябрь, 2014 ел».

Һич гаҗәпләнәсе юк, затлы бу китапның авторы да затлы бит. Роза ханым – укымышлы муллалар нәселе баласы. Иске Карматтә яшәгән дәү әнисенең атасы Хәсәнша мөәзин Хәсән Туфанны укыткан. Янына ике тапкыр Гаяз Исхакый сугылган. Әтисенең әнисе Мәликә карчыкны Үзи авылында «имче карчык» дип йөрткәннәр. «Җиде кыз тавы», «Әүлия» чишмәсе, Биләр чорындагы Мәрҗән шәһәре, Кала елгалары турындагы риваятьләр балачактан ук күңелгә сеңсә, Фәсыйгелбаян әбисе гаҗәеп моңлы тавыш белән көйли-көйли яттан укыган Тукай шигырьләре мәңгегә хәтергә уелган. Каләмнең бүген эше бик тыгыз: әнә татар әдәбиятында зур ачыш, зур вакыйга булырдай яңа документаль әсәр туып маташа. Һәрнәрсәне йөрәгә аша уздырган нечкә күңелле язучы, мөгаен, аны тыныч кына язалмас: вакыт-вакыт ак кәгазьне күз яшьләре чылатыр. «Елый белмәгән таш бәгырьле хатын-кыз куркыныч», – дия иде Туфан абый. Кеше язмышларын хәл иткәндә әз еламагандыр Роза ханым! Һәм моңа ни горурлык, ни затлылык, ни дәүләти вазыйфасы комачауламагандыр. Хәтерлим әле, икәү туган авылы Үзигә – якташы мәрхүм язучы Газиз Кашаповны искә алу кичәсенә кайттык. Ул да, Хәсән Туфан кебек үк, аның карендәше иде. Газиз абый Чаллыдан Казанга килде исә, тизрәк туганы янына ашыккан һәм туйганчы эч серләрен бушаткан. Ир җаны таштан әвәләнмәгән лә. Сүзләренең җилгә чәчелмәячәгенә ышанган ул. Караңгы төшсә дә, без әкрен генә авыл урамнарын әйләндек, икенче көнне таң белән болынга киттек. Юлдашым келәм сыман күпергән чирәмнән рәхәтләнеп яланаяк йөрде, ул гадилекнең нәкъ үзе иде! Ә тәрәзә кыйссасы? Без аның апасында кундык. Кичә үтте, өйдән әйберләрне аласы да Казанга китәсе. Тик ишеккә йозак эленгән. Бар, апаны авыл буйлап эзләп кара! Җитмәсә, капка төбендәге машина ашыктыра. Шунда ачылмалы тәрәзә күзгә чалынды. Аны тутырып ачтым да:

– Әйдә, уз, Роза апа, – дидем һәм шаяртып: – Сез, кешеләр йомышы белән түрәләргә баргач, ишектән кусалар, тәрәзәдән күп кергәнсездер әле!

Бу тәкъдимгә ачуланыр дигән идем, кая ул, яшь кызлар сыман җәлт кенә кереп, җәлт кенә кире чыкты.



Гаилә бәхетен алтыннан коелган тәхетләргә дә алыштырмас иде ул.

Роза Рәхмәтулла кызы, кайда гына эшләсә дә, нинди генә мөнбәрләрдән чыгыш ясаса да, милләт, ата-ана, хатын-кыз, балалар, диде. Чөнки аның өчен гаилә – изге төшенчә. Шөкер, Аллаһы Тәгалә бу ханымның үзенә дә әлеге бәхетне – гаилә бәхетен уч тутырып биргән.

Гәрчә икесенең дә эш дия-дия көннәре төнгә ялганса да, алар Миргалим әфәнде белән иманлы-тәүфыйклы балалар тәрбияләп үстергән. Әти-әнисе улы белән кызы өчен өлге саналган. Алма агачыннан ерак тәгәрәми шул. Бүген Айдар икътисад фәннәре докторы, профессор, Гөлназ – сәнгать белгече, Санкт-Петербургның Репин исемендәге сәнгать академиясендә инглиз телендә чит ил студентларын укыта. Дүрт онык – дәү әти белән дәү әни өчен – дүрт шатлык!

...Ә кыр үрдәкләре канат ялы алган бакчаның хуҗалары – Туфитулловлар. Сизгер кош халкы кая очып төшәсен белә шул.

PRESSA.RU



VIVAT, КУБА-2



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

– ӘНИ БЕЗНЕ МӘСКӘҮГӘ КАДӘР ОЗАТА БАРДЫ. АЭРОПОРТТА, ШЕРЕМЕТЬЕВОДА ҖЫЛЫ КИЕМНӘРНЕ САЛЫП АҢА БИРДЕМ ДӘ САМОЛЕТ ТРАБЫНА КҮТӘРЕЛДЕМ.

Барысы да бүгенгедәй хәтеремдә... Бик моңсу саубуллашу булды ул. Кабат күрешәбезме, юкмы, белмибез...
Мәскәүдән Гаванага кадәр самолет унике сәгать ярым оча. Кулында кечкенә бала. Юл буе ниләр хакында уйлады икән ул? Өзелеп көткән очрашу мизгелләре турында гына түгелдер. Билгесезлеккә атлавы бит...

Мәктәпне тәмамлагач, аның Ленинград дәүләт университетына укырга китеп баруы күпләр өчен көтелмәгән хәл була. Дөресрәге, гарәп филологиясен сайлавы. (Хәер, бирегә нинди көч тартып китергәнен, бу адымының серен ул үзе дә шактый соңрак аңлый әле. Җан тартмаса, кан тарта диләрме? Университетта Фролова дигән галимә аңа: «Ачыкларга тырышыгыз әле, сез татарның танылган мәгърифәтчесе Таҗетдин Ялчыгол белән бер нәселдән түгелме? Ул гарәп, фарсы, төрки телләрен, Шәрык гыйлемен, мәдәниятен яхшы белгән», – дигәч, Ләйлә, кайтып, әтисенә шушы сорауны бирә. Татарстан Юстиция министры Әнәс ага Таҗетдинов: «Әйе», – дип, сүзсез генә баш кага. Тамырлар (бигрәк тә андый затлы тамырлар!) турында сөйләшә торган еллармыни?!

Студентлык еллары... Гамьсез, бәхетле, хыялларга бай чаклар. Дискотекаларның берсендә ул аны – үзенең беренче мәхәббәтен очрата.

– Роберт корабльләр төзү институтында укый иде. Гади генә киенгән, үзе шундый шаян. Юк, ул мин моңарчы белгән бер егеткә дә охшамаган иде... Чит ил кешесенә кияүгә чыгу түгел, аның белән аралашу да гаеп эшкә саналган вакытлар. Әти белән әнигә Роберт турында бик озак, биш ел буе әйтмәдем. Яратуым, бәлки, узар дип көттем. Узмады...

Алар өйләнешәләр. Уллары туа. «Татарча исемнәр» китабын ачып, Роберт улына исем үзе сайлый – Айдарга туктала. Ул арада укуын тәмамлап, аның китәр көннәре килеп җитә... Ә Ләйләнең диссертация язган вакыты, аны төгәлләмичә берничек юлга кузгала алмый. Дөресрәге, моны Роберт теләми: «Башлаган эшне ахырына җиткерергә кирәк!» Саубуллашалар... Көн саен: «Сагынам!» – дип хатлар юллар өчен Роберт туган иленә – Кубага оча. (Бер-берсенә язган, ул чакта араларны бәйләп торган бер чемодан хатлар әле дә гаиләдә саклана!)

– Әтием белән әнием өчен тормышымдагы бу яңалык, әлбәттә, тетрәнү булды... Тик... мин аларның баласы идем бит, аңларга тырыштылар. Айдарны карарга булышмасалар, кулымда кечкенә бала булган килеш диссертация яклый алыр идемме икән?! Улымны алар миннән артык яратты.

Көндез хөкүмәт эшенә йөреп, төннәрен йөк бушатып, ире аларны Гаванага китертү өчен акча җыя. Билетлар, ниһаять, кулда, юлга җыеналар. 1986 ел бу. Әйе, ярату барысыннан да өстенрәк булып чыга: ара ераклыгыннан да, телне белмәүдән куркудан да, туганнар белән аерылышу ачысыннан да...

Үзе әйткәнчә, бөтенләй башка дөньяга барып төшәләр алар: табигате башка, климаты, агачлары, чәчәкләре. Кешеләре! Сөйләшүләре, аралашулары, үзара мөгамәләләре... Аш-сулары, кунакка йөрешүләре.

Барысы да Роберт алдан сөйләгәнчә булып чыга – арттырмаган да, киметмәгән дә: ул гап-гади гаиләдә үскән. Әти-әнисенә бердәнбер бала. Тыйнак кына тормыш... Бер бүлмәле фатирда кайнана-кайната белән биш җан яшиләр алар башта. Роберт Диңгезчелек академиясендә укыта. Хезмәт хакы бик аз булгач, аннан диңгезгә чыгып китә... Ул бер ел йөзгәч, үзләренә кечкенә генә аерым йорт сатып алалар. Һәм... вентилятор! Бәхет өчен күп кирәкме?!



Татарстан Республикасы Россия–Куба мөнәсәбәтләрен кабаттан торгызуда, көйләүдә, ныгытуда аерым урын алып тора.

Үзем булган һәр илнең яхшы ягын гына күрергә тырышам. Күз табибындагы кебек, бер күзне йомам да...

Айдар испан телен әнисеннән алданрак өйрәнә. Хәер, Ләйлә дә улыннан калышмый: өч ай дигәндә ул инде эшкә урнаша. Баруга хуҗабикәләр өчен оештырылган мәктәпкә языла – инглиз телен белгәч, испан телен өйрәнү авыр булмый аңа. Испанча сөйләшә башлаганчы, кайнанасы, кайнатасы белән ишарәләр ярдәмендә аралаша. Ләйлә ханым елмая: «Яшь идем бит... Мин хәтта алар өендә үз тәртипләремне урнаштырырга тырыштым. Ләкин Робертның әти-әнисе бик сабыр кешеләр иде, алар мине бик җылы кабул итте. Кубаны яраттым мин! Монда табигать искиткеч матур, ләкин беренче мәлләрдә көзне бик сагындым. Сары яфракларны... Күңелемә кыш җитмәде. Ап-ап карлар, бураннарны юксындым. Казанга да гел җәй кайтырга туры килде – кышны ун ел буе күрмәдем...»

Аннан тормыш әкренләп яңа төсмерләргә байый башлый – сагынулар арткарак чигенә. Тик... ул арада туксанынчы ел килеп җитә. Барысы да кинәт һәм кискен үзгәрә. Шәһәрдә хәтта җәмәгать транспорты да йөрүдән туктый. Тәрҗемәче булып эшләгән Ләйлә

PRESSA.RU



«Лилиябез Германиядə укый. Былтыр Яңа ел алдыннан Казанда никах укыттык. Инде тырышып-тырышып улымны татарчага өйрəтə Лилия. Айдарга бүлəк иткəн йөзеккə дə татарча «матурым» дип яздырган».



«Əни дə Кубаны яратты. Океанны ошатты, су коенды. Монда килгəч, мине, минем тормышымны аңлады ул. Язмышка шулай язылган булгач соң... Хəер, үкенмим!»

Мəдинə апа оныгы Айдар белəн аның никахы вакытында.

эштəн китəргə мəҗбүр була. Роберт кабат диңгезгə җыена... «Үкенмим, ул чакта күп вакытымны балама бирдем, – ди əңгəмəдəшем. – Айдар инде мəктəпкə кергəн иде: мин аны озатам, каршы алам. Русча укырга да, язарга да үзем өйрəттем».

Аларныкы кебек гаилəлəрнең күбесе туксанынчы елларда таркала. Əмма ул Кубада калырга көч таба...

1996 ел. Лəйлə əле һаман эшсез. Беркөнне кичке ашка балык əзерлəп яткан хатынның кинəт кулыннан пычагы төшеп китə: телевизордан соңгы яңалыклар тапшыралар – Кубага Татарстаннан хөкүмəт делегациясе килгəн!

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов җитəклəгəн делегацияне ул эзли башлаганда, алар инде, əлбəттə, киткəн була. Лəкин аны бу да туктатмый.

– Бер мең доллар акча кирəк, Казанга кайтып килəм, – ди ул иренə.

Алар гаилəсе өчен ул чакта шактый зур акча була мең доллар. Əмма Робертның диңгездəн кайткан чагы – бер еллык хезмəт хакын хатынына чыгарып бирə.

Кайткан көнне үк Татарстан сəүдə министрының кабул итү сəгатьлəрен белешə Лəйлə. Языла. Əмма тормышта бик күп нəрсəлəрне очраклык хəл итə. Нindирəк мəсьəлə буенча керергə җыенганын ишеткəч, министр ярдəмчелəре аны Халыкара хезмəттəшлекне үстерү агентлыгы директоры Хафиз Салихов белəн очраштыралар. Ə тагын ике айдан Лəйлə Əнəс кызы Таҗетдинова Татарстан Министрлар Кабинеты каршында оешкан шушы агентлыкның вəкиле буларак Кубада, Гавана шəһəрендə эшли башлый... Телне, илдəге хəлне, монда яшəүче халыкның менталитетын белгəн кешегə, хезмəттəшлек юлларын эзлəү, əлбəттə, күпкə җиңелрəк.

– Туксанынчы еллар уртасында Куба белəн берəү дə хезмəттəшлек итəргə телəмəде бит. Без эшне «КамАЗ» машиналарына запас частьлар сатудан башладык. Утрауда инде бер Россия предприятиесе дə калмаган чак бу.

Куба белəн КамАЗны күпьеллык мөнəсəбəтлəр бəйли. Иллəр арасы якын булган елларда утрауга унбиш меңнəн артык «КамАЗ» машинасы китерелгəн була. Аннан бер көндə боларның барысы да туктый. Һəм менə Халыкара хезмəттəшлекне үстерү агентлыгы ярдəме белəн дə КамАЗның Куба базарындагы позициялəре кабаттан тергезелə. Соңгы еллар эчендə утрауга меңгə якын КамАЗ автомобиле һəм махсус техникасы китертелгəн, запас частьлар сатылган. «Түбəн Кама шина» заводы белəн дə ике арадагы хезмəттəшлек җайга салынган. Гомумəн, Татарстан Республикасы Россия–Куба мөнəсəбəтлəрен кабаттан торгызуда, көйлəүдə, ныгытуда аерым урын алып тора. Быел яз башында Россия хөкүмəте Рəисе урынбасары Дмитрий Рогозин катнашында Казанда узган Региональ түгəрəк өстəлдə Татарстан Президенты Рөстəм Миңнеханов бу хакта аерым басым ясап əйтте. Россия белəн Куба арасындагы сəүдə-икътисадый, фəнни-техник хезмəттəшлеккə багышланган бу зур сөйлəшүнең бездə узуы да очраклы түгел иде. Татарстан бүген Кубага вертолетлар, авиация техникасы сата, нефть химиясе, машина төзелеше өлкəсендə хезмəттəшлек итү юллары инде эзлəнə. Туризм һəм спорт та читтə калмый.

...Татарстанның Куба Республикасындагы сəүдə-икътисадый вəкиле Лəйлə ханым Таҗетдинованың Гавана шəһəрендə урнашкан офисы кече Татарстанны хəтерлəтə. Түрдə – Президентыбыз Рөстəм Миңнеханов рəсеме, Казан күренешлəре, татар тарихына багышланган китаплар, милли сувенирлар... Һəм, əлбəттə, КамАЗ

машинасының кечкенә моделе. Рөстәм Миңнеханов бер ел элек утрауда рәсми визит белән булганда, Кубаның беренче вице-президенты Мигель Диас Канэль аңа: «Татарстанны бездә «КамАЗ» йөк машиналары буенча беләләр, – дигән иде. – Сездә югары белем алган белгечләр дә бик күп Кубада. Һәркайсы күңелендә татар халкы, Казан турында якты хатирәләр саклый».

...Иң беренче контрактка кул куелганнан соң инде унбиш ел вакыт узган. «Татарстан халыкара аренага көннән-көн күбрәк чыга, – ди Ләйлә ханым. – Президентыбыз Кубада гына түгел, инде Уругвайда, Латин Америкасында, Колумбиядә, Аргентинада да булды. 15 ел элек бу эшкә тотынуыбыз шушы юнәлештә ясаган беренче адым булгандыр, бәлки... Куба бай ил булмаса да, монда Татарстанга нык басып тору кирәк – Американың үзәге бит бу».

Шәхси тормышында да әллә никадәр үзгәреш, яңалык булырга өлгергән Ләйлә ханымның. Ире Роберт – судно-лар инспекторы – озак еллар Испаниядә эшләгән, хәзер АКШка күчергәннәр, димәк, аңа да ике ил арасында яшәргә туры килә. Дөресрәге – өч. Татарстан, Казан бар бит әле. Анда Ләйләнең әтисенең кабере... «Әниең кайда яши – синең өең шунда», – дип саный ул. Кубада сигез тапкыр булырга өлгергән әнисе хәзер мондый ерак юлга чыга алмый инде, кызы артыннан андагы күршеләргә – Луисларга, Мерседесларга сәлам генә юллый.

Соңгы вакыттагы иң зур шатлык – Айдарның башлы-күзле булуыдыр. Яңа гына Кубада туй гөрләде: Айдар белән Лилиянең туе. Әйе, әйе, татар кызы килен булып төште аларга! «Мин бу хакта хыяллана да алмаган идем! – дигән Ләйлә ханымның хисләрен аңларга була... – Айдар Гаванада Хәрби-диңгез академиясен тәмамлады, аннан Мадрид университетына укырга керде, икътисадны өйрәнде. Мин Казанда чагында, дәү әнисе янына Испаниядән улым да килде. Бер мәктәп дустымны чәйгә чакырган идем, ә ул кызы һәм туганнан туган сеңлесе – Лилия белән керде. Күз алдымда таныштылар...»

Казан якларына сукмакның, димәк, яңасы салынган! Гел көтмәгәне!

...Сугыштан буш нигезгә кайтып кергән әтисе, җиргә ятып бер елый да, Зәйдән чыгып китә. Әтисе ягыннан әбисен белми Ләйлә ханым. Әмма ул яктагы туганнары аны һәрвакыт яшьли вафат булган Миңнегаян әбисенә охшаталар. «Бу әбиемнең каберендә бер дә булганым юк иде... Соңгы кайтуларымның берсендә Зәйгә, Налимга бардым. Ниһаять, күрдем... «Истәлеккә бирәр нәрсәсе калмадымы икән?» – дип сорагач, миңа тастымал бирделәр. Озак күкрәгемә кочып тордым... Җаныма ниндидер бер тынычлык иңде...»

Аннан Иманлебаш авылына керә – Таҗетдин Ялчыгол каберенә баш ияргә. Язмышының менә шушылай язылуында нәсел тамырларының, һичшиксез, катнашы бар кебек тоела аңа.

Казан–Гавана–Казан.

КУБА ТУРЫНДА – БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Кубада гаиләдә күбрәк ир-ат баштыр дип белəм. Әмма, командалар бирмəсə дə, руль кайда да хатын-кыз кулында ул.
- Еш аерылышалармы? Әйе! Бишәр тапкыр өйләнүчеләр бар. Мәхәббәт узды, бетте, диләр дә... Ике арада ярату калмаган икән, иңдәге мондый йөкне күтәреп бармыйча, аерылышу, бәлки, дөрестер. Белмим...
- Кубада бала ярата лар! Исәнләшеп, хәл белешүгә, икенче сораулары: "Балалар ничек?" Әмма хәзер монда да гаиләләрдә бала-чага элеккечә күп түгел, бер-ике генә. Яшьләр бүген кайда да, кавышкач, башта фатир, суыткыч, кер юу машинасы сатып алу, аннары гына бала табу турында уйлый.
- Кич кунакка барасы булса, Кубада хатын-кыз чәченә бигудины иртүк урый. Көне буе бигудида йөриләр дә, кич салалар. Бездә бит киресенчә, бигудида йоклыйлар. Башта бу мине гаҗәпләндергән иде, аннан ияләштем. Бигудилы килеш ишек килеп ачу Кубада оят саналмый.
- Мондагы хатын-кызларны бик акыллы, зирәкләр дип саныйм. Ир, аның мәнфәгатьләре – алар өчен беренче урында. Бу яктан алар татар хатын-кызларына да охшаган. Әмма тормышлары җитешме, түгелме икәнгә игътибар итмичә, алар үз-үзләрен дә бик карыйлар.
- Кубада машина йөрткән хатын-кызга бик рәхәт. Беркем сине кимсетми, кырын карамый. Хәтта каршы якка хәрәкәт итсәң дә!
- Уларын башка милләт баласына өйләндерүгә караганда, кызларын читкә кияүгә бирүне хуплау, әйе, монда бар. Яшьләр, гомумән, Франциягә, Италиягә, Германиягә, Америкага китә. Кубалылар Флорида штатында бик күп яши.
- Әни – Кубада иң мөһим кеше. Майның икенче якшәмбесендә монда «Әниләр көне»н бәйрәм итәләр. Гел онытмыйм, тормышларыбыз авыр вакыт. Айдар әле кечкенә, велосипед белән каядыр китте бу. Карыйм, миңа зур букет алып кайткан. «Акча кайдан алды икән?» – дим. Бераздан сер ачылды: күршедән бурычка сораган, «Әниләр көне»ндә бүләксез каласы килмәгән... Эштә бик тыгыз вакытлар була. Әмма: «Сагындым, әнине күрәсем килә», – дисәм, хезмәттәшләрем мине Казанга теләсә кайсы вакытта берсүзсез җибәрә.
- Гашыйклар көне – Кубада иң зур бәйрәмдер! Егет белән кыз яки ир белән хатын бер-берсенә бүләк бирешәләр, икәүләп кая да булса кичке ашка баралар.
- Яше җитмешкә җитсә дә, маникюр-педикюр ясаткан, күзгә ташланып торырлык итеп киенгән, чәченә бантик кадаган ханымнар монда адым саен...
- Кунак чакырсалар, табын кормыйлар – каһвә генә пешерәләр.
- Кубада чәчәкләр бик күп, әмма алар исле түгел!
- Әйе, алар биергә ярата: сальса, ча-ча-ча... Бик катлаулы биюләр! Авыр булды, әмма мин дә өйрәндем. Ирем белән бөтен җирдә сальса биибез. Балет карарга йөрим.



PRESSA.RU



Бу парк башкалабызның Киров районында урнашкан. Халтурин, Богатырев, Октябрьнең 25 еллыгы, 1 Май урамнары белән чиктәш. Паркның атамасы элеккеге Казна дары заводы (хәзерге дары заводы) эшчесе Роман Ефимович Петров хөрмәтенә кушылган. 1918 елда, Казанны ак чехлар алгач, ул кечкенә генә бер отряд төзеп, Кызыл Армиягә ярдәм итәргә тырыша. Көчләр, әлбәттә, тигез булмый – Петров әсирлеккә эләгә һәм чехлар тарафыннан атып үтерелә. Завод алдындагы мәйданга аның исеме бирелә.


ПЕТРОВ ПАРКЫ


Петров паркының визит карточкасы – заводка керү юлына куелган Юбилей аркасы. Екатерина Икенченең вензеле белән бизәлгән, кызыл һәм ак төсләрдән торган бу арка халык телендә Кызыл капка дип йөртелә. Аны архитектор И. П. Котелов сызымы буенча 1888 елда – заводның 100 еллыгы уңаеннан төзиләр. Төзелеш эшләре бер арка белән генә тәгәлләнми – завод алдындагы мәйданны да зурайталар. 1917 елда заводта булган чиратагы көчле шартлаудан соң ул тагын да киңәя.




1930 нчы еллар башында бу мәйданда завод эшчеләре көче белән парк тергезелә. 1958 елда парктагы төп аллея алдына революционер Роман Ефимович Петровка һәйкәл-бюст куела. Бюстның авторы – скульптор А. Г. Малахальцев.












1988 елда, заводның 200 еллыгы уңаеннан, капкалар яңадан төзекләндерелә. Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар хөрмәтенә стелла куела, мәрмәрдән кыя-дивар төзелә. БМ-13 маркалы хәрби машина – «Катюша» ракета-зенит комплексы моделе дә хәрби үткәннәрне искә төшерүче һәйкәл.





2000 нче елларда – Җәйге универсиадага әзерлек эшләре барышында парк мәйданы бераз кечерәйтелә. Юлларга таш җәелә, яшь агачлар утыртыла, фонтан ачыла. Хәзер биредә балалар өчен уен мәйданчыгы, атынгычлар, бассейны булган фитнес-үзәк, кафе һәм стадион бар. Велосипедта йөрергә яратучылар да бу паркны үз итә. Монда еш кына хәрби күргәзмәләр оештырыла.

Паркның тирә-юнен юкә, миләшләр каймалаган. Араларында савыр (туя) һәм чәнечкеле чыршы ише безнең тирәлек өчен ят агачлар да бар. Шулай ук төркем-төркем булып артыш куаклары да үсеп утыра. Бүгенге көндә бу парк Киров районында яшәүчеләрнең яраткан ял урыны. Монда тыныч, бернинди ыгы-зыгы юк. Үзәнең борынгы капкалары белән узган дәверләрне искә төшерә ул.





Сәхифәне Татарстан Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.
Фотолар: Татарстан Республикасының Милли музей фондыннан.

PRESSA.RU



Гөлназ ГАЗИЗОВА

«МИН КӨЧЛЕ БУЛУДАН АРЫДЫМ...»

Мин аны беренче тапкыр Әлмәткә «Сандугач сайрар илем» бәйгесенә жюри составында барганда күрдем. Язучылар берлегендә эшләгән чагым. Бер олау шигырь китереп салдылар алдыбызга. Үзе язган шигырьләр белән катнашучылар күп иде. Һәм менә шулар арасында – берәү. Тум-тулы залда шунда ук игътибарны җәлеп итте. Дөньяны бүген беренче тапкыр күргәндәй гаҗәпләнүле-сокланулы карашында шаянлык, шуклык та, яшерен моң да бар иде бу кызның. Озын җирән чәчле, фарфор сыман аксыл йөзле, яп-ябык, нәфис. Өрфия инде... Әле ул чакта ук уйлап куйдым: Милен Фармерга охшаган... Шуннан соң гел югалгалап торды Гөлназ. Ә иң мөһиме – гел табылгалап торды. Көтмәгәндә-уйламаганда. Күңелендә нинди генә зилзилә, упкыннар булмасын, тормыш кай яктан гына китереп ормасын, рухы һәрчак б и е к т ә аның. Дөнья китерәсен – китерә, аласын ала тора, ә Гөлназның шаян-моңсу рухы үз биюен бии.

«Мин – Күкнеке, – ди ул. – Мине һаман шунда тарта...» Кайчандыр үземне шундый сүзләр өчен тиргиләр иде. «Кайчан җиргә төшәсең инде?! Кеше җирдә яшәргә тиеш!..» Аптырый идем: без шуннан килгәнбез дә, шул Күкне үзебездә йөртәбез... ничек баш тартып була асылыңнан?! Бездә никтер «Күкнеке» дигән төшенчәне «очып йөрүчән», исәррәк, иләс-миләс дигән мәгънәдә кабул итәләр. Тик һәммәбез дә – Күк илчеләре – Җиргә киләбез дә, үз миссиябезне үтәгәч, яңадан Туган Йортка – безне дәшеп алган тарафка юнәлтәбез түгелмени? Җир-Күк ул – кешенең рухи үсеш баскычлары да бит әле. Җиргә килеп тә, Үзендә чын-чынлап Күген, димәк ки, асылын саклап калган затларны адым саен очратмыйсың...

Ә тормыш, көндәлек көн күрмеш мәсьәләсенә килгәндә, мин Гөлназның булдыклылыгына, җитезлегенә, һәрнәрсәне җиренә җиткереп башкарып чыгуына сокланам. Азнакайда радио, телевидениедә эшләү белән беррәттән, туйлар, юбилейлар алып барып, ит продуктлары сату буенча менеджер булып эшләп, дөнья йөген тарта ул. Бәләкәй улы Илназны тәрбияли. Хәзер – «Ак барс» банкының Азнакай офисында банк продуктлары сату бүлеге җитәкчесе. Әйткән сүзенә, биргән вәгъдәсенә тугры була белүенә сокланам мин аның. Бу сыйфат – кешенең эчке кимәлен билгеләүче төп күрсәткечләрнең берсе. Икенчесе – кешеләргә соклана, аларны ярата белү. Сайлап алган, кадерле кешеләренә үзен багышлау сәләте. Вакытын, күңел җылысын кызганмыйча. Бу сәләт кешедә йә бар, йә – юк. Сиңа Күгең – йә биргән, йә юк инде... Менә яңадан табылды Гөлназ. Кайтты да, сак кына шакыды. Үскән... Үзгәргән... Хәер, юк! Күзләрендәге шаянлык катыш моңсулык барыбер шул. Гаҗәпләнү һәм соклану да – сакланган. Ә шулай да бу күзләр таләпчәнрәк карый хәзер, сынабрак... Әйе, Күкнеке булган күңеле белән Җирдәге кануннарга бәрелеп чыныккан ул. Монысы шигырьләрендә ярылып ята.

Луиза ЯНСУАР

* * *

«Абзый, бу кыз ялгыш итәк кигән!
Бу кызыгыз – малай буласы!» –
Ничә кабат, әтиемә килеп,
Шулай диде күрше апасы.
Малайларның «командиры» идем –
Без кермәгән бакча калмады.
Биек агачларның башларыннан
Балачагым төшә алмады...
Әллә инде без уйнаган күлнең
Төпләренә төшеп югалды?
Өйне бикләп, читкә киткән чакта
Нигезенә утырып елады?..
Шунда калды бугай «малай» чагым...
Кинәт кенә күңел үзгәрде.
Авыл белән шәһәр арасында –
Балачакның сынган күпере.
Күчәрләргә богауланган еллар...
Алда әле күптер юлларым!
Тик нигәдер җанга җылы бирә
Дүрт егеткә торган чакларым...

* * *

Тәрәз төбе,
Төнге йолдыз,
Ялгыз күзләр.
Тормыш юлы,
Тайгак сукмак,
Парсыз эзләр...
...яшьле күзләр,
...адашкан эз,
...туңган хисләр...
Мәхәббәткә ясин чыккан
бәхетсезләр!

* * *

Ә без үстек... Үткәннәрдә калды
Бәбкә үлән баскан су буе.
Төнлә тереләсе уенчыклар...
Таң җиленең назлап үбүе...
Ә без үстек. Кемнәр саный икән

Күктә янган йолдыз кызларын,
Басу капкасыннан ары китми
Гизгән чакта дөнья буйларын?
Ай нурларын учка кыссаң әгәр,
Ашмый икән чынга хыяллар...
Чатыр тауның чыклы итәгенә
Күктән иңми алтын алмалар...
Ә без үстек. Әкият битендә дә
Җыерчыклы эзләр күренде.
Балачакның сырлы капкасына
Еллар аша богау эленде.
Дөнья канунына башны иеп,
Күңелемнең сәҗдә кылуы.
Моңсулата олы булу түгел,
Олыларның шул – без булуы.

* * *

Бер язмыш. Бер җиһан. Бер тормыш.
Тик мине тырышма аңларга.
Мин синнән көчлерәк беразга:
Бер юлга. Үтелгән бер юлга.
Исәрләр ул – вакыт җилләре,
Мизгелләр әйләнер сәгатькә.
Мин синнән сабыррак бик азга:
Бер өмет. Фәкать бер өметкә.
Фал ачма туасы таңнарга –
Әҗәтле хисемне кайтарам,
Мин генә түгел лә күз йомып,
Алдаган хыялым аклаган.
Тырышма син мине аңларга,
Гафу ит катлаулы асылым...
Аңларга тырышма... Тик... ярат!
Мин көчле булудан арыдым!

* * *

Җир сулышын тыңлау рәхәт, диләр,
Иң гүзәл көй – елга шаулавы.
Җилнең җыры сихәт бирә җанга,
Сандугачның – моңлы сайравы...
Кемдер әйтә: дөрләп учак янса,
Җанга рәхәт – утын шартлавы.
Кемдер әйтә: урман аваз салса,
Дәрт һәм дәрман – аның шаулавы.
Кыя тауга менеп тыңлап кара –
Җилләр ничек дулый иркендә!
Кулларыңны җәеп кочып кара,
Назын той син чәчтә... битеңдә...
...Сез белмисез... төнге тынлык аша,
Бер туктатып дөнья агышын,
Ничек рәхәт – ярым йокы аша –
Тыңлап яту балаң сулышын!
Далаларда җилләр котырыныр,
Киң дәрьялар шаулар еракта,
Телем-телем уйнап учак янар –
Мин ишетмәм ләкин ул чакта...
Минем өчен дөнья туктап калган,
Вакытның да сизмим агышын.
Төнге тынлык.
Бәхет.
Йокысызлык.
Тыңлап ятам балам сулышын.

* * *

Канатымны синең тәрәзеңдә
Калдырганмын салып.
Онытып.
Төшләремдә, шуңа микән, күптән
Очканым юк күккә... орынып...
Канатымны синең тәрәзеңдә
Калдырганмын никтер онытып.
Канатымда карлар йоклый хәзер.
Карлар назлый аны – җылытып.
Шул карларга карап көнем үтә...
Күк капчыгы гүя тишелгән,
Һәм ак карлар төпсез шул капчыктан
Минем канатларга сибелгән...
Дәшмә миңа, көтмә һәм сагынма,
Мин фәрештә була алмадым!
Язмышымның ничек борыласын
Алдан күреп... саклап калмадым...
Кышлар килер кебек түгел иде,
Хәл итәргә безнең язмышны, —
Бозлы табаннары белән басты
Канатланган җанга ялгышмы?
Мәңгелек туң хөкем сөрә җирдә,
Чынбарлыкны санап үлемгә,
Җиргә төшү – минем өчен җәза –
Күкләремне бирмәм беркемгә!
Җирдә мине әзер теләк көтә,
Әзер тормыш, әзер хыяллар.
Мине тиргәп, салкын кышларыма
Очып түгел, атлап баралар...
Ә канатлар – синең тәрәзеңдә...
Җир дөньясы – миңа охшаган:
Канатларын салган язмышлардан
Урамнар һәм йортлар түшәлгән.
Мин фәрештә булалмадым, кичер,
Талпынуым – фәкать бер адым...
Кар көртеннән әзер сукмак буйлап
Язмышыма таба атлавым...

* * *

Тагын бер төн мамык шәлен ябып,
Шәһәрләрне изрәп йоклатты.
Тагын бер төн айлы күзе белән
Күңел кылларымны кузгатты.
Ә уйлары шундый усал иде...
Тойдым аның кырыс багуын.
Җир йөзендә әйтерсең мин генә –
Үтәмәүче төннәр канунын...
Ай балкышы. Мин җиһанда – ялгыз.
Күңелемне уйлар актарды.
Төннәремдә эчтән генә укыйм
Сиңа диеп язган хатларны.
Белсәң иде: анда – күпме сагыш,
Мәчетләрдә булмас тәүбәләр.
Күз яшенең иң-иң ихласлары,
Үтәлмичә калган вәгъдәләр...
Сиңа гына әйтә алган сүзләр,
Елмаюлар, серләр – кыюлар...
Белсәң икән, никадәрле авыр
Ярсу җанны бикләп куюлар!
...Юлланмаган сүзләр яши шулай –
Ябылуда – минем уйларда.
Сиңа хатлар барып җитмәсә дә,
Юктыр алар, диеп, уйлама...

Беренче адым

Бүлмәдә без өчәү:
Син һәм мин.
Һәм тынлык.
Сүндереп утларны,
Таңнарны сүндереп, үрелә
Еландай кочарга бугазны.
Саташып бу өнсез мизгелгә,
Язмышлар туктатыр сәгатен.
Йокысыз шашынган ярканат
Кимерер икәүнең бәхетен.
Бу куе томаннан кысылып,
Чигәләр туктаусыз сулкылдар.
Ят тынлык пәрдәсен ерткалап,
Бер конфет кәгазе кыштырдар.
Баллыны, гомумән, яратмыйм,
Тик яланаяклы адымнар,
Җырлатыр да иске паркетны,
«Булмады!» – дип, елар шайтаннар.
Син сизәрсең. Таңга уралып
Яңа көн килгәне ишетелер.
Бу тынлык пәрдәсен
Ерткалап,
Әйтермен:
«Яртысын миңа бир...»

* * *

Үзе ачы, үзе татлы сагыш –
Хәрам шәраб төсле исертә.
Эсселектән әлсерәгән дәрвиш
Иреннәрем – бәллүр читлектә.
Кич бәхетен таңнар әсир итә,
Икебезгә – ике күк каты.
Минем юллар – офык чатларында,
Иңнәремдә – язмыш канаты.
Канатымны шәрабларга мандым,
Күкне бүлде шәфәкъ камчысы.
...Бәллүр савыт төпләрендә калды
Мәхәббәтнең соңгы тамчысы...

PRESSA.RU



Гөлүсә ЗАКИРОВА

КҮҢЕЛЕМ КОЯШЫ

(хикәя)

– Ә-ный! Ә-ный! Китмә, әный!!!

Олы юлдан бер малай чаба. Арган-талган, кызарынган-бүртенгән – сулкылдап елаудан үзәк өзгеч сүзләре дә «әный» булып чыга. Әный дигәне чит ил машинасында тузан туздырып билгесез тарафларга китеп бара. Ят бер абый белән. Кемнеңдер аннан иң кадерле кешесен алып китүе аның җанын телгәли, малай йодрыкларын катырак төйни, тешләрен катырак кыса. Юл тузаны утырган чәчләренә кара тир бәреп чыга, бирешергә исәбе юк аның. Тугыз яшьлек малайның шулай чабып кына әнисен саклап калырлык егәре юк, ә менә ачуы бар.

Аның үрсәләнүен ымсындыргыч карашларга алданган ана да сизенә. Иренен буяган итенеп көзгегә күз салгач, кояш чагылышы арасыннан улын күреп йөрәге чәнчеп куя. Һай, улым, кая чабасың, нигә әбиең янында гына калмадың? Нишләргә? Альбертка эндәшергәме? Их, туктасын да, Зәлиянең газиз баласын үз итеп, чын әтиләрчә кочып алсын иде ул. Аннан ерак шәһәргә бергәләп китәрләр иде. Өзгәләнеп калмас иде ана йөрәге. Тик Альберт алга барасы юлын гына яхшы белә. Себернең кырыс табигате эзен салган йөз җыерчыклары кымшанмый да, әнисе китәр юлыннан Айзатның өзгәләнеп чапканын ул да күрә булыр бит инде. Зәлия иркәләнеп кенә ирнең таза беләкләренә кагылды.

– Әү, матурым!

– Альберт, ни... мин...

Хатынның әллә ни өстәп әйтергә тагын хәленнән килмәде. Әнә бит ничек ягымлы итеп карый, шул карашларны тояр өчен генә булса да бу юлга чыгарга кирәк иде. Кирәк иде! Ул гомере буе мәхәббәт көтте. Альберт кебек чын ирләр белән киләчәген үткәрергә хыялланды. Җитәр, исерек Раниска яшьлеген әрәм итәргә! Ялгышлык белән чыкты кияүгә. Ә Альберт... Вәт ир дисәң дә ир! Чын Алып батыр. Буй дисәң – буй, көч дисәң, көч ташып тора. Яшьли яратып йөрдем ди. Миңа нәкъ синең кебек сылу хатын кирәк ди. Бер малай

табып бирерсең ди. Күршеләргә шәһәрдән кайтып йөргән Алып батыр шундый сүзләр әйтер дип башына да китергәне булмады аның. Төссез тормышка бер атна эчендә ямь өстәде кунак егете. Кинолардагы кебек балдак һәм чәчәкләр биреп азапланмады, кайнанасы, ире, баласы белән гомер иткән өеннән бер кулы белән генә күтәреп чыгып, машинасына утыртты. Боларны искә алгач, тәне буйлап татлы кымырҗавык йөгереп үтте. Эреде Зәлия, тагын эреде. Бу мәхәббәт хәтле көчле хисне адәм баласы тоя алмый торгандыр.

– Матурым, яратам димәкче буласыңмы әллә?

– Әйе, үлеп яратам. Гомерем буе көттем мин сине, Альберт!

Хатын, назланып, иркәсенең чәчләрен тузгытып куйды. Әмма аналык инстинкты да үлеп бетмәгән иде әле. Яңа ире җилкәсенә башын салган булып, арткы тәрәзәгә күз салды һәм: «Мескенем, һаман йөгерә...» – дип пышылдады.

Айзат тәмам хәлдән тайды. Тезләре чүгеп-чүгеп китә. Чаба торгач, юлдагы кантарга абынып, резин башмагы өзелеп үк чыкты. Мәтәлеп китәргә шул җитте. Йөзе белән үк юл тузанына барып төште. Тез башлары канаганга да, авызына туфрак тулганга да, майкасының иңнәре ертылып чыкканга да түгел, үз гомерендә беренче югалтуны кичергән ир-атлар хәсрәте белән юлга капланып елый иде ул: «Ә-ный!!!»

– Тукта, елама, улым. Кая, битләреңне сөртимче!

Газиз тавышны ишеткәч, бөтен үпкәләрен онытып, әнисе кочагына атылды малай. Бу минутта башка бернинди дә дөнья рәхәте булмас кебек иде. Әнә теге абый да машинасының ишекләрен ачып куйган. Күңеле киң икән!

– Тузанын яхшылабрак как, салонны пычрата күрмәсен!

Альберт бу сүзләрен Зәлиягә генә ишетерлек итеп әйтә. Хатын куырылып килә, ул барысын да аңлый. Тик машинага утырткач, бергә китәләр була түгелме? Аның күңелендә дә өмет чаткылары барлыкка килә. Айзаты бәхетле, әнисенең кочагындагы җәннәтне нәрсәгә алмаштырып була? Өчәүләп яши башласалар, уртак тел тапмый калмаслар иде әле. Әмма яшь ирнең каш арасындагы җыерчыкларны ул әле укый белми иде.

Берәр чакрым баргач, юлда ЮХИДИ хезмәткәрләре күренде. Альбертның да йөзләре яктырып китте. Җитмәсә, танышлары икән. Джибыннан сикереп төшеп, формалы егетнең кулын кысарга ашыкты ул. Айзатның куркуы әле дә кимемәгән, әнисенең беләгенә чытырдап ябышкан. Зәлия дә югалып калган, нишләргә кирәген аңламый утыра бирә. Шулчак машина ишеге ачылды. Альберт, тәмле телләнеп, малайга эндәште.

– Карале, Айзат, син үскәч менә шундый полиция абыйлар кебек буласың киләме?

– Килә... – мышык-мышык борын астыннан булса да, теләк дигәнең үзенекен итә шул.

– Чын егетләр инде болар. Киемнәре дә нинди матур, әйеме? Мин дә малай чакта бик хыялланган идем шул уты янып торган машиналарына. Йә, ничек, утырып карыйсыңмы?

Айзат, күзләрен мөлдерәтеп, әнисенә бакты. Машинага утырып карарга түгел, ә тормышын көйләргә дип авылыннан, гаиләсеннән качып китеп баручы Зәлия елмаеп куйды. Альбертка шул гына кирәк – әнисеннән аерып, сабыйның учларын үз кулларына алды.

– Әле сиңа сыбызгысын да сызгыртып карарга рөхсәт итәчәкләр. Менә күрерсең! Кая, руль артына ук утыртып карыйк әле бу егетне! Булачак полиция хезмәткәренә хөрмәт һәм илтифат күрсәтергә кирәк! Фуражка да кигезик инде. Менә шулай. Ай-яй, ничек килешә. Койган да куйган тәртип сакчысы! – Машинага утырткач, Альберт малайга егетләрчә дәшеп куйды. – Айзат, син инде олы малай. Әниең итәгенә ияреп йөрү булдымы эш! Әтиең, әбиең синсез нишләр? Әниең дә вакыты җиткәч кайтыр, яхшылап көт кенә син аны, яме!

Әле генә күз яшенә буылып чапкан малайга да егетләр чалымы кергән иде инде. Җавап бирүне кирәк дип тапмады ул. Тузан туздырып кузгалып киткән машина артыннан каш астыннан гына карап калды. Яше кипкәнме, белмәссең. Шуннан соң бер тапкыр да елап карамады. Бер тапкыр да! Әтисе исереп йөреп, тракторы белән капланып үлгәч тә керфекләрен чылатмады. Әнисен сагынган чаклары да булмады түгел, булды. Шул юл тузаны күз яшьләре савытын бикләп куйган иде, ахры – елый алмады. Әмма еллар узган саен әни ничек яши икән дигән уй башына килә торган булды. Бәхетлеме икән? Әнә үзе дә авылның иң матур кызы белән очрашып йөри. Гүзәлдән башка бер генә минут та яши алмас кебек. Әнисе дә шул хисләр ташкынында чыгып китте микән? Тик Айзат үз баласын беркайчан да җиде юл чатында калдырып китә алмаячак. Җае гына чыксын, әнисен алып киткән теге «амбал»ны акылга утыртачак! Ул көннәр дә килер әле!

Айзат иртәгә армиягә китәсе кичтә аларның өйләрендә телефон шалтырады. Яшьләр җырлаша, көлешә – шау-шу арасында аңа игътибар бирүче дә юк. Аш бүлмәсенә чиста тәлинкә алырга дип кергән Гүзәл генә узып китә алмады – кемдер өзгәләнә бит.

– Алло! Исәнмесез! Мин ерактан шалтыратам, миңа аның белән бер тапкыр гына сөйләшеп алырга кирәк иде...

– Апа, мин сезне аңламыйм. Начар ишетелә. Тавыш монда, Айзатның вечеры. Сезгә кем кирәк?

– Айзат армиягә китәмени?

– Китә шул, апа, иртәгә военкоматка чакырдылар. Але!! Але!!! Һ-м... өзелде. Ярар, тагын шалтыратырлар әле. – Гүзәл аның кабаттан шалтыратуын көтеп тормакчы иде, тик яшьләр чакыргач, бу бүлмәгә нигә керүен исенә төшереп, юлында булды.

PRESSA.RU

Ә трубканың аргы башындагы хатын – улын ташлап киткән Зәлия күңелендә бу сөйләшүдән соң буран-зилзиләләр тынмаслык булып купты. Башка чыдап торырлык әмәле юк иде аның. Ул юлга чыгарга карар итте. Документлар кайда соң? Аның күзләрен дә шул документлар ачкан иде түгелме?

Ширбәт ае өч көндә тәмамланды. Шуннан бирле иза чигеп яши ул, кайтыр юлы да бикле, алга атларга да көче җитми. Бу дөньяда һәрнәрсә өчен җавап бирәсе икән, менә шуңа түзә дә. Өч көннән Альберт аның паспортын сорады. Башы күккә тиде Зәлиянең: ЗАГСка алып барачак! Алып батырның законлы хатыны булырга кем генә хыялланмый торгандыр. Ә ул әнә тормыш пары итеп озын аяклы, сары чәчле, кызыл тырнаклы кыланчык бер шәһәр бичәсен түгел, ә авылдан җаны теләгән кешесен, аерып алып булса да, яр итте, инде пичәт куярга паспортын сорый.

– Матурым, әйдә, киен, документларга кул куярга барып кайтыйк.

Бару гына түгел, оча. Ярар инде, ак күлмәкләр киеп тормады. Әй, кигәне булды бит инде бер тапкыр, Ранис белән тормышлары гына барып чыкмады. Бу юлы кызылын кияргә ниятләде ул. Сабан туена дип алып куйган күлмәгенең бала итәкләрен сыйпаштыргалап ишек төбенә чыгып баскач, Альберт бер мәл пырхылдап куйды. Аннан Зәлиянең чәчләре арасына кыстырган кызыл чәчәген алып кулына тоттырды.

– Монысы кайткач, матурым, яме! Чәчәкләргә төренеп яшиселәр алда әле.

Сөеклесе бит алмаларыннан үбеп алгач, хатынның дөньясы тагын түгәрәкләнеп китте. Иң элек банкка керде алар. Нindидер кызлар чәй ясап бирде, аннан Альберт бармагы белән төртеп күрсәткән урыннарга имзасын куя барды Зәлия. Тагын нindидер сюрприз әзерли булыр, сорамыйм, кызыгын бетермим, дип фаразлады гына. Чәчәккә төренеп яшәрбез, диде бит. Икебезгә дигән зур фатир турында сүз бара булыр, әнә кәгазьгә дә «торак яхшырту өчен кредит» дип язылган иде түгелме? Ул кул куйган саен, Альберт ныграк шатлана барды. Соңгы кәгазьне рәсмиләштергәч, Зәлиянең бармакларын берәм-берәм үбеп чыкты.

– Минем өчен синнән дә зуррак шатлык була алмый, каян гына килеп чыктың да караңгы көннәремне яктырттың соң син, кояшым? Син миңа ышанасыңмы?

– Әйе...

– Күзләрем нуры, алтын бөртегем!

Иркен фатирга түгел, төссез коммуналка бүлмәсенә кайткач та бу сүзләрнең сихере күзләрен томалаган иде әле.

– Зәлиям, күпмедер вакыт шунда яшәп торасы булыр, яңа фатирга ремонт ясап бетергәнче түзәрсең инде, яме, – диде Альберт.

– Мин синең белән шалашта яшәргә дә әзер, – Зәлиянең җавабы ихлас иде.

– Юк, шалашта яшәргә кирәкмәс, артык тавышланып йөрмәсәң, монда да оҗмах булып тоелыр, яме! Аннан, ни... Зәлия, эшкә урнашырга да кирәк булыр инде. Ремонт кыйбатка төшә, ипи-тозлык кына акча табыштырсаң, ярап куяр шунда.

– Эштән курыкмыйм мин, иртәгә үк эзләрмен.

– Эзләрбез, алтыным. Мин хәзер үк биржага барып килим әле.

Шулай диде дә Альберты эзен суытты. Баштарак өчәр көнгә югалып торды, аннан атналар, айлар буе кайтмаган чаклары да ешайды. Кайтуына бер сүз әйтергә дә ирек бирми, татлы үбүләре белән хатынның аңын томалый, аннан теләсә нинди әкият сөйләп, ышандырып та куя. Көннәрдән бер көнне бер миллионлык кредитка батканын белгәч, күз аллары караңгыланып китте Зәлиянең. Теге вакытта нинди кәгазьләргә кул куйганын суд приставлары килгәч кенә төшенде. Кредитны түләрмен дигән ышаныч кәгазе яздырып алгач, киттеләр тагын. Ә Зәлия бурычлары, алданулары белән бер ялгызы басып калды. Улын өзелеп сагынганын шул мизгелдә генә төшенде ул һәм мендәренә капланды. Кредитны түләп бетермичә беркая китә алмыйсы билгеле иде. Шуннан тагын бер эшкә урнашты, кичен мәктәп идәннәрен юды, көндезләрен хастаханәдә кер үтүкләде, урын өстендә яткан әби-бабайларны да, балалары акча түләсә, өйләренә барып карарга шатланып риза булды. Тапкан бар акчасын банк дигән убыр суыра барды. Җитмәсә, процентлары да артканнан-арта бара. Инде ипи һәм сөт белән генә тамак ялгарга өйрәнде.

Шулай гомер иткән көннәрендә бүлмә ишеген шакыдылар. Көтелмәгән кунак – кино актрисаларына охшаган бантик иренле бер кыз иде.

– Ну барып чыккан икән!

– Аңламадым, – диде Зәлия. – Сезгә кем кирәк?

– Короче, – диде кыз, бүлмәнең уртасына ук хуҗаларча узып. – Альбертик кая?

– Мин каян белим?

– Ул миннән китте, өенә кайткан, дип уйладым. Аның адресы шушында бит.

– Альбертның бер ел күренгәне юк.

– Алдамыйсыңмы? Кара аны, ялганлап яшереп калсаң, башың бетте дип уйла. Ә менә монысы – бантик ирен идән уртасына бер пакет атты – аның барахлолары. Кирәге чыгар. Хәшәрәт! Альфонс! Минем машинада җилдереп йөрде дә юкка чыкты. Мин моны болай гына калдырмам. Йөрер юлларымны чәче белән себертәм әле.

Кыз ничек керсә, шулай чыгып та китте. Аның бу бүлмәдә булуын ишек җиленә кушылган затлы хушбуй исе генә искәртеп тора. Зәлия куркып кына пакетны идән уртасына бушатты. Ике ыштан, бер майка, бер футболка, теш щеткасы, кырынгычы һәм искереп беткән бер телефоны – иркәсенең бар бирнәсе шул икән бит. Күңеле дә шул тирәдә. Их, ярар, без авыл хатыны – назлы сүзләр ишетмәгән, кинолардагы кебек тормышка кызыкканбыз. Ә менә син, Бантик ирен,

шул көнгә калдыңмы? Нәрсә, әллә без хатыннар барыбыз да шул назлы сүзгә гаҗиз булып, теләсә кем авыз ачса да ышанырга әзерме? Нинди заман бу? Әнә әбиләр сугышта үлеп калган ирләренә тугры булып яшәгән, мәхәббәт эзләп интекмәгән. Безнең кебек мескенләнмәгән. Үзенә үзе җирәнгеч тоелды Зәлиягә. Шуннан телефонны кулга алды һәм... еллар буе төшләренә кереп йөдәткән тавышны ишетергә теләп таныш номерларны җыйды.

– Алло! Мин еректан шалтыратам. Миңа Айзат кирәк иде...

Телефонны бер кыз алды. Улының армиягә китәсен дә ул хәбәр итте. Бу сүзләр бер утка, бер суга салды Зәлияне. Артык уйларга вакыт юк иде, юл өчен кирәкле әйберләрне аннан-моннан тутырды да телефоннан «911» номерын җыйды. Хатынның сүзләре кискен чыкты:

– Мәктәпкә бомба куйганнар!!!


...Олы юлдан бер хатын атлап кайтып бара. Йончыган, арган, талчыккан. Әнә авылының тау башындагы йорт түбәләренә беренче кояш нурлары кунарга да өлгергән. Арттан ниндидер машиналар да килә. Утырта кайтсалар ярар иде, йә улымны күрми калырмын, дип уйлап куйды ул. Авыл ягыннан да бер машина кузгалды – әрҗәсенә яшьләр төялешкән, җырлашалар. Ананың йөрәге тартышып куйды.

– Гражданка, пакетыгызны җиргә куеп, кулыгызны күтәрегез! – Полиция машинасыннан тавыш көчәйткеч аша әйтелгән бу сүзләргә аптырап калды Зәлия. Якын тирәдә аннан башка беркем булмавын абайлагач, кулын күтәрергә мәҗбүр булды.

Барысын да аңлады ул. Телефон Альбертныкы булса ни, аны кулга алганнар да, гаебе юк икәнен ачыклап, кайтарып җибәргәннәрдер. Ә Зәлия шул номердан авылга шалтыраткан иде шул. Их! Телефоны да үзе белән икән бит. Аның кайдан хәрәкәт иткәнен ачыклау полиция хезмәткәрләренә ике минутлык эш ләбаса. Инде менә ялган хәбәр өчен дә җавап бирәсе. Алданган мәхәббәте, улыннан аерым яшәлгән еллары өчен үч алырга да хәленнән килмәде, ичмасам.

Яшьләр төялешкән машина да шул урында туктап калды. Гармун тавышлары тынды. Барысы да маҗара карагандай бу манзараны күзәтә. Яраткан кызын кочаклап уртада басып торган Айзат сагаеп кына әзәрлекләнүче хатынга күз салды. Шундук танып алды. Әный!!! Җәлт кенә машина кузовыннан сикереп төште ул.

Ана белән ул арасында тугыз гына адым. Тормыш сынауларына укмашып беткән озын тугыз ел. Шуны үтәргә хәлләреннән килсә, моннан соң аерым торачак вакытлары тугыз минутта гына үтәрлек ара. Әнә, кораллы хокук сакчылары да мөмкинлек биргәндәй сабыр итеп тора. Ничек кенә булмасын, беренче адым инде ясалган – ана белән баланы тоташтырган кояш нурларыдай җылы мәхәббәт җепләре ялганган иде.



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU



Фото: Газинур Хафизов

КҮҢЕЛЛӘРНЕҢ СӘЛАМЕ



Асия ЮНЫСОВА

ДРАМАТУРГ МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ «ГАЛИЯБАНУ» ДРАМАСЫН 1916 ЕЛНЫ ОРЕНБУРГ ТӨБӘГЕНДӘГЕ ЮЛЫК АВЫЛЫНДА КИТАПХАНӘЧЕ БУЛЫП ЭШЛӘГӘНДӘ АВЫЛ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ҮТЕНЕЧЕН ТЫҢЛАП ЯЗА.

«Яшьләр тормышыннан бер матур манзара булсын иде ул» дигән теләк драматург күңелендә Балтач төбәгендәге Шода авылында җизнәсендә кунак булып торган чактагы ямьле мизгелләрне яңарта. Чишмәгә суга йөргән гүзәл Сәгадәтбану күз алдына килә аның...

Тәүге мәртәбә 1917 елның мартында Оренбургтагы профессиональ «Нур» труппасы тарафыннан уйналган спектакльнең дә исеме «Сәгадәтбану» була. Шул тамашадан ук күңелләрне яулап алган спектакльнең бүгенге көннәргә кадәр дәвам иткән моңлы юлы шул вакыттан. Пьеса тукымасына мул итеп кертелгән шигырьләр, җыр рәвеше алып, «Галиябану» дигән халык көенә җырлана башлагач, спектакльләр дә «Галиябану» исеме белән уйнала башлый. Драмадагы каһарман Галиябану: «Йөрәгемнең кай төшеннән генә алып җырладым соң мин бу җырны?» – дип өзгәләнгән үзәк өзгеч бу көйне кайсы халык көйчесе иҗат иткән булды икән? Булгандыр инде аның иясе, булгандыр! Кызның атасы Бәдри абзый «күңелләр сәламе» дип атаган «Галиябану көе» ничә буын гашыйкларның күңелләр сәламенә әйләнеп яшәде дә инде менә «кәрәзле» телефоннардан бер гашыйктан икенче гашыйкка сәлам илтә. Мәшһүр Салих Сәйдәшевнең могҗизаи тыны тигән көй ләбаса ул! Камал театрында аңа соңгы куелышларда Фуат Әбүбәкеров тылсымы да өстәлә. Ни генә әйтмәсеннәр, «Галиябану» драмасы ул, уеннан бигрәк, җыры-көе белән сихерле күңелләрне. Шуңа күрә «Галиябану»ны сәхнәләштерү өчен иң әүвәле баш рольләргә Хәлил белән Галиябануга җырчы табудан башлана.

Татар дөньясында «Галиябану» уйналмаган бер авыл да юк. Иң халыкчан, иң аңлаешлы, иң эстәлгән сәхнә әсәре ул. Әгәренки берәр яшь кыз белән берәр яшь егет әлеге спектакльдә кара-каршы җырлаша икән, алар арасында гомерлек мәхәббәт кабынасы аермачык. Чөнки җыр сүзләрендәге ихласлык, хәйләсез кичерешләр давылы әле мәхәббәт орлыгы төшмәгән йөрәкләрне дә бөтереп, биләп алырга сәләтле.

Казанда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә бу спектакль беренче мәртәбә 1919 елда уйнала. Ул вакытта аның режиссеры Габдулла Кариев була. Ә беренче Галиябану – Әшрәф Синяева, аның Хәлиле – Мәшһүр Ситдыйк Айдаров. Хәер, ул заман артистларының барысы да мәшһүрләр. 1920, 1924, 1929, 1937, 1948, 1952, 1972, 1991 елларда – җәмгысы тугыз тапкыр куела бу драма Камал театры сәхнәсендә. Театр тормышында эз калдырган режиссерлар – Г. Девишев, Г. Исмәгыйлев, Р. Тумашев, Х. Сәлимҗанов, П. Исәнбәт мөрәҗәгать итәләр Мирхәйдәр Фәйзи әсәренә. Тамашачы театрга суына төште кебегрәк шик кергәндә искә алалар бу әсәрне. Чөнки татар кызының якты, күркәм образын, ул чиккән кульяулыкны күкрәк кесәсендә йөрткән кебек, йөрәгендә йөрткән саф, чиста җанлы кешеләр янәдән театрга агылачак.

Быел – октябрьнең өченче көнендә «Галиябану» янәдән Камал театры сәхнәсенә менде. Соңгы премьерадан соң 24 ел узган икән. Дөрес, анысы тамашачы «Галиябану»сыз тормады. Аны читтәге театрлар да һаман уйный торды. Тинчурин театрында Дамир Сираҗиев куйган «Галиябану»ны да, Татарстан телевидениесендә Әхтәм Зарипов төшергән фильмны да хәтерлибез. Күз алдыннан төрле еллардагы Хәлил-Галиябанулар тезелеп үтә. Беренче Галиябану дип, Камал театры тарихына Әшрәф Синяева теркәлсә дә, «Ширкәт» труппасы белән Мортазин-Иманский куйган спектакльнең Галиябануы матур тавышлы җырчы Сара Байкина була. Аннан соңгы Галиябануларга – Галия Кайбицкаяга, Мәрьям Сульвага, Рокыя Кушловскаяга, Марзия Миңлебаевага, Рауза Хәйретдиновага, Мәсгудә Хәйруллинага, Илсөя Төхфәтуллинага шул югарылыктан төшмәү өчен тырышырга кала. Менә аның тиңсез уены Галиябану образын халык йөрәгенә урнаштырып куя да инде. Бу спектакльнең Оренбургтагы уңышыннан соң, аны «Сәйяр» труппасы, телеграмма белән соратып алып, Казанда уйный.

Әйткәнемчә, Галиябанулар һәр авылда булган. Димәк, Исмәгыйле дә. Ә бит Камал театрындагы Исмәгыйльләр дә онытылырлык түгел. Шакир Шамильский, Һидаят Солтанов, Хәким Сәлимҗанов. Спектакльдә күрексез бер генә роль дә юк. Бәдриләрне карагыз әнә: Габдулла Кариев, Барый Тарханов, Хәлил Әбҗәлилов, Барый Әшрәпов, Илдус Әхмәтҗанов. Театрда Хәлил булып уйнап алу исә һәрвакыт иҗат биографиясендә иң дәрәҗәле бер сәхифә. Ситдыйк Айдаров, Хәким Сәлимҗанов, Дилүс Ильясов, Ибраһим Гафуров, Роберт Әбелмәмбәтов, Рамил Төхфәтуллиннар җырчы гына түгел, гармунчы да егетләр. Татар театры репертуарындагы музыкаль әсәрләрнең тәүгесе булган, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт кебек драматургларны музыкаль драмалар язарга рухландырган «Галиябану» чыннан да һәр яктан үрнәк әсәр булып кала.

Һәр авылның үз Хәлиле, үз Галиябануы булган кебек, һәр театрның да үз Хәлиле, үз Галиябануы булган.

Хәтерлим әле, хөрмәтле әдип Мөхәммәт Мәһдиев, совет драматургиясе хакындагы лекциясен сөйләгәндә М. Фәйзинең бу әсәрен драматургиянең классик кануннарына җавап бирә торган иң камил әсәр буларак бәяләп үткән иде. Ул аны һәр яктан сүтеп җыеп, тел-теш тидергесез, төенләнеше, кульминациясе, чишелеше, теле, музыкаль бизәлеше мөкәммәл спектакль буларак та билгеләп үтте. Без, мөгаен, ул вакытта 1952 елгы куелышка нигезләнеп фикер йөрткәнбездер. Радиодан ешрак шул чактагы постановка яңгырый иде.

Халыкның рухи байлыгын, этнографик җыйнаклыгын, пөхтәлеген тасвирлау бурычын да йөкләгән әлеге спектакль фәкать матур бизәкләрдән генә тукылырга тиеш кебек. Ул матур бизәкләр

PRESSA.RU



Җанын савыктыру ниятеннән театрга килгән тамашачыга Зәйниев куйган спектакльдән кинаяләр эзләп утырасы түгел.

җиткән кызның челтәрле-чигүле урын-җир әйберләре аша да, тәрәзә кашагалары, күлмәк-алъяпкычлар аша да тапшырыла. Иң камил гүзәллек, әлбәттә, «Галиябану»да яңгырый торган, мәңгелек шигърият дөньясын чагылдырган илаһи моңда! Спектакльгә режиссерларның үзләрен дә кабат-кабат шул моң тартып кайтармый микән әле?

Инде менә бу юлы тамашачы каршында режиссер сыйфатында драматург Илгиз Зәйниев, Галиябану ролендә үзен инде Мәйсәрәдә уңышлы гына сынап караган Гүзәл Гөлвердиева, Хәлил булып Фәннур Мөхәммәтҗанов имтихан тота. Исмәгыйльнең каршылыклы образын Алмаз Гәрәев ача. Бәдри – Минвәли Габдуллин. Галимәбанулар икәү – сәхнә осталары Ләйсән Рәхимова белән Илсөя Төхфәтуллина. Егет-кызлар тамашачы каршында беренче уеннарын күрсәтеп өлгерделәр инде. Барысы да җитеш кебек. Җырлыйлар, гармун тарталар, биеп тә алалар – гомумән, егерменче йөз башы авыл тормышын үзләре һәм режиссер аңлый алган кимәлдә чагылдырырга тырышалар. Әле сыйныфлар арасында упкын ясалмаган заман бу. Алай да, ярлы-бай сызыгы ярылып ята. Нәкъ безнең замандагы кебек икән дигән нәтиҗә ясарга да ашыгасы түгел. Мәхәббәтнең кануннары һәр заманда да бер. Сөйкемсезгә күлмәк кидермиләр. Ә ата-ана дигән кешеләр һәр заманда да балаларын бай яшәтергә тырышкан. Имеш, бай яшәсә, бәхетле була. Әмма Мирхәйдәр Фәйзинең Бәдрие дә, Галимәбануы да соңгы күренештә бу фикернең ялгышлыгын аңлыйлар. Илгиз Зәйниев, күрәсең, «билгеле бит инде болай да» дигәнрәк фикердә торадыр. Аның үзенчә фикерләве спектакльдән артист булам дип хыялланган ничәмә-ничә малайга шанс биргән Садри (малай) персонажын алып ташлауда да, сәхнә декорациясен минимализм принципларына нигезләнеп коруда да чагыла. Бәлки, спектакльне җыйнаграк итү максатыннандыр, Хәлил белән Галиябану кара-каршы җырлашасы урыннарда, Ромео белән Джульетта кебек, кара каршы шигырь әйтешәләр. Ялыкмас идек югыйсә. (Бәдри белән Галимәбануның ыргак кебек, чалгы кебек сызыклардан хәреф, аннан исем җыйганнарын да сабыр гына көтә идек бит әле.) Аннан бит татар халкы драматургиягә әнә шундый кара-каршы җырлашулар аша килгән. («Хан кызы», «Сак-Сок» әсәрләрен мисалга китерә алам.)

Хәер, спектакль кат-кат уйнала-уйнала тамашачы теләгән кимәлгә кайтып төшәр әле ул. Гүзәлнең беренче тамашада көчсезрәк яңгыраган вокалы да ачылып китәр. Шул ук теләкне Фәннур вокалына карата да әйтә алам. Әйе, шулай булыр. Чөнки остазлары Айгөл Хәйри аларның тавышын чарлауны дәвам итә. Ә тамашачы «Галиябану»га бөтен хилафлыкларны да гафу итәргә әзер. Чөнки ярата ул аны, ярата!

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН...



■ Беренчесе. Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтулла, узган гасыр башында Кече Кайбыч авылында мәчет салдырып, үзе мәхәллә мулласы була. Хәзрәт йөз ураулы ефәк чалма киеп йөргән. Муллалыктан алынгач, ул ефәк чалмасын кызы Галиягә бирә. Еллар үткәч, Галия бу чалмадан күлмәк тегеп, шул мәчеттә Галиябану булып уйный.

■ Икенчесе. «Галиябану»да Фоат Халитов – Исмәгыйльне, Дилүс Ильясов Хәлилне уйный икән. Атышу күренешендә Исмәгыйльнең алтатары, күпме генә тырышса да, атмый. Нишләргә соң? Хәлил үләргә тиеш, алтатар атмый. Тәҗрибәле артист каушап калмый, алтатар түтәсе белән Хәлилнең башына тондыра. Хәлилне уйнаучы Дилүс, сузылып ятып, «җан бирә».



Октябрьнең беренче көннәрендә Казанда төрки дөньяның шигърият фестивале узды. Андый фестивальләрнең бу инде унберенчесе — Дәрдемәнд һәм Гаяз Исхакыйның газиз истәлекләренә махсус багышланганы. Шигърият бәйрәменең беренчесе Төркиянең Бурса шәһәрендә узган иде. Казанга дөньяның 25 иленнән 100 шагыйрь килде!



Асия ЮНЫСОВА

ШАГЫЙРЬ ӨЧЕН ШАГЫЙРЬ КУНАК!

Фестиваль Төркия Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлегенең күмәк тырышлыгы нәтиҗәсендә мөмкин булды. Дөньяның төрле төбәкләрендә яшәп иҗат итүче төрки телле шагыйрьләрне очраштырган тантана 1 октябрьдә К. Тинчурин исемендәге театрда башланып китеп, Татарстан язучыларының Тукай исемен йөрткән клубында, Төркия консуллыгының утырышлар залында Габдулла Тукайга, Рәми Гариповка, Рәшит Рәхмәти Аратка, Мөхмәт Акиф Эрсойга, Дәрдемәндкә, Фатих Кәримигә, Габдерәшит Ибраһимга, Һади Такташка, Хәсән Туфанга, Муса Җәлилгә багышланган шигъри фасыллар рәвешендә дәвам итте. Фестиваль чит илләрдән килгән кунакларның Шәһри Болгарга сәяхәте белән тәгәлләнде.

Бәйрәмне Төркия Язарлар берлеге рәисе Һиҗаби Кырлангыч белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан ачып җибәрделәр. Аннары Төркиянең Татарстандагы баш консулы Турхан бәй Дилмач, Мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, Алтай Премьер-министры Иван Белеков сәламләвеннән соң, дәүләт эшлеклесе, халык шагыйре Разил Вәлиев сүз алды. Әле бер генә трибунаның да дәүләт эшлеклеләре сыйфатындагы шагыйрьләргә бер-бер артлы сүз бирә алганы юк иде.

Беренче шигъри сүз, әлбәттә, Тукайдан: «И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк!» дигән иде ул. Шул теземдә яңгыраган, инде канатлыга әйләнгән шигъри җөмләләрне тотып алырга тырышам: «Шагыйрь өчен шагыйрь һәрвакыт кунак», «Шагыйрьләр дә бер-берсен аңламаса, дөнья ничек аңлашыр?», «Бер-беребезгә елышмасак, берәм-берәм юкка чыгарбыз»...

«Рухы сынган җайдакның аргамагы акрын чаба...» Бу соңгы җөмлә Чыңгыз ханныкы диделәр. Кара син аны, инде бөек хан заманында ук рухка, димәк ки, шагыйрьләр галәменә урын түрдән булган икән. Нинди түрдән генә, ди, ханнар, солтаннар үзләре шагыйрь булган лабаса! Бер шигъри фасылның Сөләйман солтан – шагыйрь Мөхиби ядкаренә багышлануы үзе бик мөһим фал түгелмени?

Төрки каһанлыкның тарихы мең ярым ел белән саналган бер дәвердә Казанда шагыйрьләр мәҗлесе булып яту – үзе дә әһәмиятле фал. Тагын бер әһәмиятле фал – шагыйрьләр арасында хатын-кызларның тормышта гына түгел, бәлки, иҗатта да тигез, янәшә тора алулары. Карачай-Чиркәс иленнән килгән кунак, ногай шагыйре Иса Кабаев: «Бездә Аскәр тау бар. Аскәр тауны ногайлар «Дөньялык тавы» дип тә, «Шагыйрьләр тавы» дип тә йөртәләр», – диде. Димәк ки, Парнас тавы була инде. Әнә шул шигърият тавында – Парнаста хәзер кызлар да байтак. Мин мәшһүр шагыйрьләр исемлегеннән аралап, Зәйнәп Аркан (Төркиядән), Зәкия Доган (Голландиядән), Гөлниһәл Өлҗүм (Германиядән) исемле төрек шагыйрәләрен, Тамара Искәндәрия исемле башкорт, Нарсылу Гөргебаева исемле кыргыз, Танагыз Ильясова исемле казакъ, Альбина Любимова исемле (Чуашстан) шагыйрәләрен теркәп куям. Бу шагыйрәләргә бер-берсе белән аралашырга Төркиядә яшәүче Казан кызы, шагыйрә Чулпан Зариф тылмачлык итте. Дәрдемәндкә багышланган шигырь фасылын да Чулпаныбыз алып барды. Югыйсә казакъча, алтайча, кыргызча, карачайча, ногайча, татарча яңгыраган шигырьләрне болай да аңлап тыңладык. Олы бер кавемнең сибелешкән балалары ла без!

Россиядә әдәбият елы барган заманда төрки телле иҗатчыларның бергә җыелышуларын консул Турхан бәй моннан йөз ун еллап элек Тукайның ашкынып Казанга кайтуы белән тиңләп һәм «Пар ат» шигырен укып, бөтен залны Тукай тирәсенә туплап куйды. Уртак рух безне борын заманнарда ук берләштергән анысы. Ул рухның башы, бәлки, Орхон-Инәсәй язмаларыннан уктыр. Шуңа күрә бу байлыгыбызны ЮНЕСКО яклавына алдыруның зарурлыгы турында кузгалган олы сүз бик урынлы яңгырады.

Рәсемдә: Чулпан Зариф, Асия Юнысова, Нарсылу Гөргебаева, Гөлниһәл Өлҗүм, Зәкия Доган, Альбина Любимова *(сулдан-уңга).*

PRESSA.RU



ҖЫР БУЛЫП КИЛЕП КЕРДЕ...

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Җыр ничек туа? Төрлечә, дияр белеклеләр. Адәм балалары кебек кайсы җиңел, кайсы авырлык белән дөньяга килә. Кайсысыдыр бер-ике җырлауга онытыла. Була озын гомерлеләре... Фирая Зыятдинова шигыренә Луиза Батыр-Болгари көй язган «Мин сине шундый сагындым» җыры сыман башта ук халык йөрәгенә кергәнен, әлбәттә, бәхетле язмышка ия икән бу җыр, дисең.

Композитор бу җырның язылу тарихын әле дә хәтерендә саклый икән. Янәшә утырып эшләгән шагыйрә – Фирая шигыренә яратып көй яза ул, әмма иҗат җимешенең нинди язмышка дучар буласын ул чакта күзаллый да алмый. Радиокомитетка җырны яздырырга килгәч, кирәкме-юкмы, дип, икеләнеп торуы да исендә әле. «Халык җырларына тартым, ничектер артык гади булып тоелды ул миңа, худсовет үткәрмәс моны дигән шик күңелгә керде. Чөнки байтак җырым яңгыраш алалмый өчәр-дүртәр ел «тоткын» булып ятканы бар иде». «Су буеннан әнкәй кайтып килә» (Марсель Галиев шигыре) кебек халык күптән үз иткән җыр авторының борсалануын урынсыз дип булмый. Сәнгать әсәрләрен җиз иләктән үткәрү гадәти хәл иде ул чакта (хәзер бу чорны сагынып сөйләргә генә калды). Әсәрне башкарачак артист Айдар Фәйзрахманов оркестрга кушылып җырлый башлауга, композиторның шик-шөбһәләре томан кебек эреп тарала. Булган бу! Сөенергә дә өлгерми, Илгиз Хәйруллин, радиотелевидение башлыгы, студиягә Үзе килеп керә. Бирелеп җыр тыңлый. Һәм... Җыр иртәгә – 8 Март көнне

Мин сине шундый сагындым

Мин сине
шундый сагындым,
Сизәсең микән шуны?
Ак бураннар урап алса,
Табарсың микән юлны?

Син дә шулай
сагына калсаң,
Карама җилләренә...
Җыр булып килеп
керерсең
Наз тулы йөрәгемә.

Мин сине
шундый сагындым,
Күзләрем шуңа моңлы.
Айны болытлар
капласа,
Табарсың микән юлны?

эфирга чыга дигән хәбәр Луиза ханымга күктән яшен атылгандай тәэсир итә. «Ничек? Худсовет «добро» бирмәгән көе?» Илгиз Кәлимулловичның җырны ошатуын, әсәрнең фонд өчен язылуын әйтәләр. Кырык елга якын вакыт үткәннән соң да көе дә, сүзләре дә искерми, онытылмый, еллар тузаны аны күмми икән, бу инде җырның чыннан да халыкчан булуын искәртә. Үз кичерешләре, хис-тойгылары булып меңнәрнең йөрәгенә кергән озын гомерле җыр шундый була. Гашыйклар да яратып җырлый аны, сагыну сагышын йөрәгенә җыйган өлкәннәр дә, яшьләр дә, татарлар, чуаш, урыслар да. Хәтта инглиз теленә тәрҗемә итәләр бу җырны – джаз-оркестрга кушылып бар дөнья җырлый. Фирая сүзләренә язылган әлеге җыр шундук популяр булып китә. «Кемгә багышланган?» – дип тә кызыксыналар. Бу хакта Фирая үзе көндәлегенә болай дип язган: «Очрашуларга килгәч, «Шигырегезне кемгә багышлаган идегез?» – дип сорамый калмыйлар. Кемгә булсын инде, Фарсельгә! Ул бик еш командировкаларга китә иде. Мәскәүгә дә, чит илләргә дә... Кайчак атналар, айларга сузыла. Сагындыра...»

«Мин сине шундый сагындым»ны Фирая Зыятдинованың якты истәлегенә багышланган кичәдә көй авторының үзе уйнап, башта инглиз, аннан татар телендә җырлавы гаҗәп тәэсирле булды. Луиза ханым белән иҗади дуслыгы Фираябызның өстәмә бәхете иде. Талантлы композитор көй язган ничәмә-ничә шигыре күптән инде яраткан җырларга әверелде.

Кеше китә, җыры кала. Ни үкенеч, иртәрәк китеп барды ул. Шагыйрә, әдибә, егермеләп китап тәрҗемә иткән тәрҗемәче, китап нәшрияты мөхәррире Фирая – дустыбыз, кадерле, җанга якын, якты шәхес – гаҗәеп якты, ихлас, саф-садә күңелле кеше иде. «Без бит җиргә якты, җылы, ямь өстәргә яратылган» аның тормыш девизы иде. Аннан «Иң зур бәхет», «Матур буласым килә», «Китмим әле яшьлегемнән», «Бәхет өчен күп кирәкми» кебек җырлар һәм якты нур калды... Әйтеп аңлатып та булмый торган хәтер яктысы. Сагындыра торган!

Фирая белән Казан дәүләт университетына керү имтиханнары тапшырганда – 1963 елның августында танышкан идек. Беренче күрешү, сөйләшүдән башланган танышлык дуслыкка әйләнде һәм 2006 елның 22 апреленә кадәр – якын дустым мәңгелеккә күчкәнче дәвам итте. Хәер, әле бүген дә ул янәшәдә сыман!

Лидерлыкка артык омтылмаса да, ул гел беренчеләр рәтендә булды. Әтнә районы Мәмәш авылында туып-үскән, урта мәктәпне дә колхозда эшли-эшли «экстерн» белән тәмамлаган кыз ничек рус телен шулай мөкәммәл белгәндер дә, шулкадәр эрудицияле – киң белемле, укымышлы булгандыр, үзе бер гаҗәп. Күрәсең, табигать аны шундый сәләтле, булдыклы итеп яраткан булгандыр. Без куркып-калтырап торганда, ул имтиханга беренче булып керер дә «отлично» эләктереп чыгар. Кайтып китмәс, кемгә нинди ярдәм кирәк – булышырга әзер. Төркемнән беренче кияүгә киткән кыз да Фирая булды. Чөнки Фарсель, берьюлы ике җирдә – университеттә һәм авыл хуҗалыгы институтында укучы һәм радиожурналист булып эшләүче гаять өлгер иптәш (ул хәзер профессор, танылган язучы, журналист), мондый чибәрне күздән ычкындырырга ярамаганын иң алдан сизеп алгандыр. Күп тә үтмәде – кызлары Алсу туды. Без үзебез дә балалыктан чыгып җитмәгән идек әле, дустыбызның кызы безгә дә якын иде. Тик... сабый кыска гомерле булды, ике яшендә күбәләк булып җаны мәңгелеккә очты. Әни булу тәмен тойган Фираябыз бу югалтуны бик авыр кичерде. Бер-бер артлы туган уллары – Айдар, Айнур, Айваз да кызы сагышын баса алмады шикелле. Фирая – көчле рухлы, гаҗәеп эшчән ханым – авырлыкларга бирешмәскә тырышты: нәшриятта эшләде, күп укыды, бәйләде, текте, пешерде һәм... язды. «Каян вакыт табасың?» – дип сораганым булды. «Шигырь язам, дип, кәгазь-каләм алып, өстәл янына утырган юк. Үзеннән-үзе туа ул, язып куярга гына өлгер», – диде.

Тагын бер сыйфаты – юмартлык турында әйтмәсәм, Фирая портреты тулы булмас иде. Бәйләү – аның җан яраткан эше иде. Шәлләр бәйләп үскән кыз ич. Тик... Һай, матур, дип соклана күрмә. Күз нурын түгеп бәйләгән кул эшен сиңа бүләк итү хәстәренә керешәчәк.

Аларның күл буендагы бакчасында ни генә үсми! Фарсель – атаклы бакчачы. Утыз төп карлыган, унлап алмагач, ул кура җиләк... «Карлыган пеште, коела, җыярга кил!» Өч чиләк җыя аласыңмы, күбрәкме – җый гына. Мунча кертеп, тәмле бәлешләр пешереп сыйлап та җибәрәләр... Нигә кирәк шулкадәр карлыган, дигән сорауга да җавап әзер: «Дусларны бергә җыяр өчен!»

Фото: Фирая һәм Фарсель Зыятдиновларның никахлашу көне. Дуслары арасында – Рәдиф Гаташ, Флера Баязитова, Равил Фәйзуллин, Әнвәр Шәрипов һәм башкалар.

PRESSA.RU


Фото интернеттан алынды

ӘНӘ КҮЗЛӘН СЫНАР

«НАХАКТАН ЯБЫШКАН БӘЛАДӘН САКЛАН», ДИГӘН СҮЗ БАР БЕЗНЕҢ ХАЛЫКТА.

Күрәчәгең булмасын, әмма андый хәлгә тарысаң, авырлыкларга әзер бул, сынатма, дигән кисәтү кебегрәк яңгырый ул. «Хагыннан, нахагыннан сакла», дип теләк тели гомер кичкән өлкәннәр. Нахагыннан сакла... Ә саклап бетерә алмаса? Сынауның менә шундые килсә? Андый очракта нишләргә? Үзеңне ничек тотарга? Бу бәладән ничекләр арынырга?

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Язарга талпынып та, кулдан нидер тотып, туктатып калган очраклар була ул бездә. Андый чакта күңелең кушканга иярү хәерлерәк. Өмет булып бөреләнгән, бөтен уй-хыялларың аның белән бәйләнгән балаңны югалту ачысы миңа да таныш. Үзе кичергәннәр белә... Шуңадыр, Гөлия сөйләгәндә мин аның хикәятенең шул ягына гына игътибар иткәнмен. Үле туган сабыен яңа гына җир куенына салган әнине бик кызганып тыңладым. Редакциянең «Гаилә сәламәтлеге клиникасы» белән бергә районнарга оештырган чираттагы командировкасы иде ул. Табиблар төшке ашка китте дә, чиратта өч-дүрт хатын калды. Таныш булмасаң да, мондый чакта сөйләшергә сүз табыла: һәркемнең үз зары – хатыннарның күбесендә бала табу, балага уза алмау белән бәйле проблемалар. Әмма бераздан барысы да үзләре турында онытып, Гөлияне тыңлауга күчте. Мин дә... Соңыннан да кайта-кайта аның сөйләгәннәрен искә төшереп йөрдем әле. Бүлдерергә кыймадыммы икән соң, күңелемдә әллә никадәр сорау туган иде. Берсен дә бирмәгәнмен. Хәер, әйттем бит инде, ул чакта мин аны кызганудан узмадым. «Теләсәгез, языгыз», – дип, Гөлия миңа бик тиз генә ризалык та биргән иде югыйсә. Әмма ул сөйләгәннәрдә үзем аңлап җиткермәгән урыннар шактый булганга тотынмадым. Инде ул очрашуны онытып бетердем дигәндә генә...

Камилә – студент чакта ук табышкан дус кызым. Шатлык-сөенечләр дә, борчулар да уртак безнең. Әле менә бу юлы да аңа килгән бер хәсрәттән, нахак бәла карасыннан (ә Камилә аны нәкъ шулай кабул итте!) арынуның юлларын эзлибез. Юк, табылмый чишелеш! Узган ел көз район сырхауханәләренең берсендә булган бу очрашу кинәт шушы чакта искә төште. Бу ике очрак арасында уртаклык бар

бит! Бөтен игътибарым белән Камиләне тыңлыйм кебек, ә үзем Гөлияне уйлыйм. Ялгышлардан берәү дә хали түгел – Гөлия дә теге таныш кызын гаепләп ялгышкан булса? Хәер, аңлатыбрак сөйлим әле.

...Камилә кайнанасы белән мөмкин булганча сирәгрәк аралашырга тырыша. Сәбәпләре бар... Ә бу юлы бармый калу һич мөмкин түгел иде: иренең әнисе юбилей үткәрә, шактый гына кунаклар чакырылган, килене булышмый кем булышсын?! «Тыныч узды! Барысы да киткәндә миңа рәхмәт әйтте», – дип шалтыратты ул миңа. Ике көннән шушы хәбәр: кайнанасының мәҗлес көнне алтын балдагы югалган, ул инде таныш багучысына барып кайтырга өлгергән. «Киленең алган!» – дигән багучы. Кайнанасы балдакны таптыра, өзми дә куймый да: «Өч көн вакыт сиңа. Китереп биргән бул!» – ди. «Шул күрәзәченең йөзенә, күзенә карыйсы иде», – дип елый Камилә. Иң аянычы – ире дә әнисе ягында. «Нәрсә дип кызыктың шул балдакка? Алтын яратмыйсың да бит син. Күрәзәче ничек ялгышсын: ул бит хатын-кыз алган, дигән. Чәчеңнең дә, күзеңнең дә төсе ул әйткәннәргә туры килә», – дип, хатынының күзен дә ачтырмый. Ире дөрес әйтә, Камиләнең алтынга исе китми. Зур кашлы алтын балдакны кайнанасы үзе бүләк итеп биргән очракта да кимәячәк... Сине ишетергә дә, тыңларга да теләмәгән кешеләргә үзеңнең гаепсез икәнеңне, балдакка кагылмаганыңны исбатлап кара менә. Энә күздән сынар, кеше – сүздән, диләр. Адәм баласын сындыру, түбәнсетү, күңелен яралау өчен бер нахак сүз дә җитә икән.

Инде Гөлия тарихына әйләнеп кайтыйк. Камилә белән шушы хәл булганнан соң, мин аны яңадан эзләп таптым.

Иреннән бәхете булмый аның. Өйләнешүгә, эчә башлый, хатынына кул күтәрә. Өстәвенә, читтә очрашып йөри торган хатыны барлыгы ачыклана. Өч елдан алар аерылышалар. Улы әтисен белергә дә өлгерми кала. Җиде ел ялгызы яшәгәч, Гөлия үзенең беренче мәхәббәтен очрата. «Дус кызымның, кемнән киткән булсаң, шуңа кире кайтасың, диюен шунда аңладым. Аңа кадәр, элеккеге ирем турында әйтәдер дип, елаган чакларым да булгалады. Дус кызым ялгышмый ул, дөрес күрә, андый сәләте күптән бар», – ди Гөлия. Ике арада хисләр сүнеп бетмәгән була – яңадан кабына. «Безнең кавышуга бөтен дөнья каршы булды. Бианам да риза түгел иде, – дип сөйли ул. – Улына кемнең балалы хатын алдырасы килсен?! Боларның барысы да артта калды. Хәзер без бианам белән әни белән кыз шикелле».

Яшь хатын икенче тапкыр әни булырга әзерләнә. Йөклелеге 32 атналык чакта район табиблары аны Казанга күренергә җибәрә. Шул вакыт УЗИдагы белгеч коточкыч яңалык әйтә: «Балагыз үсүдән туктаган», – ди. Үле баланы дөньяга китерү күпкә авыррак, диләр: шулайдыр, тән газапларына җан газаплары да кушыла бит. Нәни Фатыйманың кечкенә кабере өйләренә каршы яктагы зиратта.

– Гөлия, бала югалткан хатыннар бик күп. Барысы да: «Нигә болай булды әле?» – дип, күрәзәчегә чыгып чапмый. Берәр шигең булдымы, нигә барырга уйладың? – дим.

– Кызымны таныш абыстай юды. Олы яшьтә инде ул, туксанга җитеп килә. Күрә торган сәләте дә бар. Баланы кулына алгач: «Булдырганнар икән! Әнисенә дип ясаганнар, сабый әнисен саклап калган», – дигән. Дус кызым ишетеп торган. Казанда яшәүче бер ир-ат күрәзәченең номерын бирделәр безгә шул вакыт. Ул үзе ДЦП белән авырый икән. Мин үзем шикләнгән бишалты кешенең фотосын да алып бардым. Шушы кызның сурәтенә җиткәч: «Сезгә аның кем икәне нәрсәгә?» – дип, ул берничә секундка гына күзен читкә алды... Җиде күрәзәчегә бардык. Берсе генә: «Ул кызны гаепләп гөнаһлы булгансыз. Инде хәзер шушы гөнаһыгызны юарга кирәк. Гафу үтенегез аңардан, бүләкләр бирегез», – диде. Аптырап кайткан идек, дус кызым: «Бу сүзләрне сезгә әйттерү өчен аның әнисе күрәзәчегә алдан акча түләп куйган!» – диде. Дус кызым дөрес әйтә ул, бу юлы да ялгышмагандыр.

– Ә сәбәбе нәрсә? Ул танышың сиңа нигә начарлык тели дип уйлыйсың соң?

Гөлиянең бу сорауга да җавабы бар икән.

– Дус кызым әйтә: «Урманда агач ничек гөрселдәп ава, син аның юлына шулай аркылы төшкәнсең», – ди. Без хәзерге ирем белән яңадан очрашып йөри башлаганга ике-өч айлар тирәсе генә иде әле. Алар икесе уртак танышларының туенда берсе – кыз, икенчесе егет ягыннан шаһитлар булдылар. Ул кызның иремә шунда күзе төшкән дип аңладым... Аннан ул иремнең энесе белән йөри башлады.

Ул кыз да бүген үзенең гаепсезлеген ничекләр итеп исбатларга белми бәргәләнсә?

Беләсезме, без хәзер килендәшләр. Энебезнең күзен бик тә ачтырасы килеп никадәр генә багучыга алып барырга теләсәк тә, ризалашмады. Элек миңа: «Җиңги!» – дип кенә тора иде, хәзер әнә бөтенләй аралашмыйбыз. Дөрес, кеше аркылы булса да, никахка да, туйларына да чакыру бирделәр, әмма абыйсы да, мин дә бармадык. Кемгә генә барсак та: «Бозымны ризык белән кертә», – диләр. Бер багучы әби, каршына утыртты да, үзе тәсбих тарта башлады. «Көнең елаудан гына торамыни? – ди. Җавап бирүемне дә көтмәде, дәвам итте: – Кызым, ачуланма, хәлләрең еларлык булган икән шул...» Ә дус кызым: «Ул синнән гафу үтенергә килә әле, тик син аны мәңге кичермәячәксең», – ди. Бүгенге тормышыма шундый зур авырлыклар аша килдем. Миннән аны күпсенәсе түгел бит инде... Моңарчы ул кыз әле безнең өйгә кереп йөри иде. Яңа ел белән котларга килгәч, мин аңа дәшмәдем. Ул аны бик авыр кичерде. Мине күргәч, ул гел куркып китә... Аңардан шикләнгәнемне, әлбәттә, белә.

– Ә ул кыз чыннан да гаепсез булса? – дим. – Бер генә күрәзәче дә

PRESSA.RU

исемнәр атамаган бит. Шикләнгән кешесенең сурәтен һәркем күңелендә үзе тудыра. Ә ялгышсаң? Син гаеп ташлаган кыз үзен бу очракта ничек акларга тиеш соң? «Мин моны эшләмәдем», – дисенме ул?

Гөлия сорауларымны әллә ишетмәде, әллә... Инде сүзнең күңелләрәк өлешенә күчәбез. Телефоннан исәнләшүгә: «Кыз алып кайттым! Кызыбыз бар!» – дигән иде бит ул. «Бу юлы йөклелегең ничек узды?» – дим.

– Әбиләргә йөреп, чистарынып тордым инде. Гел үземне кемдер күзәтә, кемдер карап тора кебек тоелды. Бу юлы да ахыргача күтәреп бетерә алмадым. 32 атнада ярып алдылар. Бер килограмм да ике йөз граммлы гына булып туды. Резус-факторым «тискәре» минем. Дөрес, анализларым начар булмады. Әмма табиблар бөерләрем өчен курыкты, кечкенәдән авырта алар минем. Аннан беренчесен табу белән икенчесенә узуның арасы да якын булды – өч ай гына. Болай ярамый, диләр...

«Сүз белән кешене терелтергә дә, үтерергә дә була», дип юкка әйтмибез.

Вакыт барысын да оныттыра. Килендәшләр арасындагы бу аңлашылмаучылык та кайчан да булса артта, үткәндә калыр дигән өметем бар. Шушы вакыйга аркасында абый белән энекәш арасыннан да кара мәче узган. Ә алар бу тормышта бер-берсенә терәк, таяныч булырга тиешле ике ир туган...

Сүзне дус кызым белән булган хәлдән башлаган идем. Камиләнең кайнанасы балдагын тапты бит! Кунаклар килер алдыннан шкафтагы яңа чәйнек эченә салып куйган булган һәм... оныткан! Килененнән гафу үтенеп тормады, билгеле. Балдакның табылуын да Камилә иреннән очраклы рәвештә генә белде. Күпме күз яше түгәргә өлгерде дустым! «Инде барысы да артта калды, онытырга тырыш», – дим аңа. Кул гына селти, кылыч ярасы төзәлер, сүз ярасы төзәлмәс, ди.



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы.

– Сүзне бала югалтудан башлыйк әле. Кеше сиңа никадәр начарлык теләсә дә, карыныңдагы сабыең яшәмәсен, төшсен дип әйтсә дә, әгәр туасы җан дөньяга киләсе булса, ул бернинди зыян салуларга карамый, туа. Инде киресенчә икән, бу да беркемнән, бернәрсәдән тормый: ни генә кылсаң да, ничек кенә саклансаң да, ул тумаячак. Бернинди күрәзәче дә, табиб та ярдәм итмәячәк. Иң беренче менә шуны аңларга кирәк. Димәк, Аллаһы Тәгалә шулай язган...

Әйе, кемдер начар ният белән сиңа зыян да салырга мөмкин. Әмма ул кешенең кемлеген төгәл белмичә гаепләүдән сак булырга кирәк. Моны ачыклау өчен күрәзәчегә бару динебездә бик зур гөнаһ санала. Пәйгамбәребез: «Күрәзәчегә барган кешенең кырык көн намазы кабул булмый. Ә күрәзәчегә ышанган кеше – ул инде мөселман түгел», – ди. Бу ханымның һәрдаим күрәзәчеләргә мөрәҗәгать итүе исә аларга ышануы турында сөйли.

Күрәзәчеләрнең төп максаты кешеләр арасын бозу: дуслар, туганнар, ир белән хатын... Алар гел бер сүзне әйтә: ирең йә хатының, йә дустың гаепле ди. Күршеңнән зыян күрәсең ди. Мөнәсәбәтләр болай да киеренке булганда, әлбәттә, барысы да катлаулана. Күрәзәче шайтаннар белән эш итә, ә алар ялганларга да мөмкин. Динебез буенча, яхшы яки яман күрәзәче юк – алар бөтенесе начар. Багучыга ышанып, кешене гаепләү – бу инде яла ягу кебек үк гөнаһ гамәл. Әгәр сиңа яла ягалар икән, «мин дә аларга начарлык эшлим әле», дип, үзең дә яла ягу һич дөрес түгел. Дәлилләр китереп, үзеңне аклый алсаң – аклыйсың, юк икән – дәшмичә каласың, сабыр итәсең. Аллаһы Тәгалә үзе ачыклаячак.

Кешеләр арасындагы иң четерекле мәсьәләләр сүз белән бәйле. Монда рәнҗеш дигән нәрсә дә бар әле. Әгәр син нахакка берәүне гаепләгәнсең, рәнҗеткәнсең икән, ул мәзлум дип санала. Шундый вакытта, күңеленнән рәнҗеп, сиңа берәр начарлык теләсә, Аллаһы Тәгалә аның догасын шунда ук кабул итә. Дога кылу, кул күтәреп, «йә Раббым», дип ялвару гына түгел ул, күңел ачысы белән: «Әй, үзе дә шушы хәлгә төшсә иде», – дип әйтеп куюы да җитә.

Динебез буенча, кеше турында гайбәт сөйләү тыела. Пәйгамбәребез: «Кеше шулай эшләде дип сөйләсәгез дә бу гайбәт була», – ди. Сәхабәләр: «Ә ул сүз дөрес булса?» – дип сорыйлар. «Хәтта сүзегез дөрес булса да», – ди. Кемдер турында гайбәт сөйләгән очракта, ул кеше сине кичерми торып, Аллаһы Тәгалә бу гөнаһыңны гафу итә алмый. Башта шул кешегә барып: «Мин синең хакта шулай-шулай дип сөйләгән идем», – дип, гафу үтенергә тиешсең. Аллаһы Тәгалә, тәүбә иткәндә, эчеп йөрүне, зина кылуны, кайтарып бирсәң, әйбер урлауны гафу итә, ә гайбәткә керүне – юк. Менә нинди җитди әйбер ул сүз.

Син хәтта сүзең белән кешене рәнҗетмәгән очракта да аңардан гафу сорарга тиешсең (кемгәдер барыбер бит – аның турында сөйлиләрме, юкмы). Тагын шунысы да бар: кем турында гайбәт сөйлисең, кыямәт көнендә шул кешегә үзеңнең савапларыңны бирәсең, әгәр савапларың булмаса, аның гөнаһларын үзеңә аласың. Чөнки гафу үтенү вакыты инде үткән була.

Ә без җиңел генә: «Ишеттеңме әле, теге тегеләй иткән, бу – болай», – дип сөйләшәбез. Кызганыч, ахырын уйламыйбыз.

КЕШЕ ҮЗ ГОМЕРЕНДӘ ӨЙ САЛЫРГА, БАЛА ҮСТЕРЕРГӘ, АГАЧ УТЫРТЫРГА ТИЕШ, ДИГӘН КАНУНИ ГЫЙБАРӘ ЯШӘП КИЛӘ. ДӨРЕС, БУ СҮЗЛӘР КҮБРӘК ИР-АТ ХАЛКЫНА НИСБӘТӘН ӘЙТЕЛӘ.

Асия
СӘГЫЙТОВА

ӘНИ АЛМАСЫ

Якын дустым миңа бер бик матур алма сузды да сөйләп китте: «Әни алмагачының алмасы бу! Ашап кара әле, матур гына түгел, татлы да ул».

«Әни алмасы булсын да, татлы булмасын», дип уйлап куйдым да дустымның хикәятен тыңларга әзерләндем.

«Безнең дәү әниләр репрессия шаукымыннан качып, Урта Азия якларына чыгып киткәннәр. Тянь-Шань итәгендә яшәгәннәр. Дәү әнием бик үткен булган минем. Ире тапканга риза булып, кул кушырып кына утырмаган. Тау сукмакларыннан Кытай ягына да чыккалаган – үтемле товар ташыган. Башымдагы менә бу яулыгымны дәү әнине сагынганда алып бәйлим. Бабамның кияү бүләге булган ул – туза белмәс, уңа белмәс кытай ефәге. Бер сәфәреннән дәү әнием зур-зур кызыл алмалар алып кайткан. Кытайлар кеше саулыгын кайгырту җәһәтеннән бик белекле халык бит. Дәү әнием алма хакында кытайлардан ишеткәнен әниемә дә сөйләгән. Кызым, дигән ул, алманың матурлыгына соклануын соклан син. Тик белеп тор, алманың егәре аның төшендә. Алма төше кешегә икенче гомер бирә икән ул.

Әниебез дәү әнинең бу сүзләрен гел исенә ала торган иде. Аннары гел өстәп куяр иде: кытай алмасы кебек матур алмалар юк хәзер. Ә без аңа, алма яратканын белгәнгә күрә, алмаларның төрлесен алып кайта торган идек – Польшаныкын да, Венгриянекен дә. Аларның алсу битле алмалары чыннан да бик матур бит. Әни никтер яшел алмаларны өнәмәде.



Бервакыт кайтсам, әни кулына алма тоткан да шуңа сокланып карап утыра: «Кызым, күр әле, алманың мондые да була икән. Үзе түм-түгәрәк, үзе бер яктан яшел, икенче ягыннан кызыл. Ашап карадым – тәмленең тәмлесе. Төшен алып куйдым, утыртыйк әле аны». «И әни, төштән чыбыгы үсеп чыкса да, алма бирмәс бит ул алмагач. Чыбыкка чыбык ялгый-ялгый үстерәләр түгелме соң җимеш өмет иткән агачны?»

Әнием ул кадәресен үзе дә белгәндер. Тик шулай да алма төшен гөл төбенә төртеп куйган булган икән. Берзаманны зәйтүн гөле төбендә нәни үсенте борнады. «Алмагачым үсә!» – диде әни. Чыннан да, алмагач үсте. Инде аңа зәйтүн гөленә өйдәш булып кына яшәү читен иде бугай. Ирек, иркенлек тансыклады яшь алмагач. Мин кияүгә чыккан елны әни сырхаулап китте. Йөрәгә кага, тыны кысыла. Ул үзе дә, яшь алмагач кебек, саф һава тансыклый иде. Еш кына аны бакча ягына караган тәрәзә янына утыртып куябыз. Аның уен дөрес укыган кеше минем ирем булып чыкты: «Әби, – диде ул. – Әйдә алмагачыңны тәрәзә каршына утыртып куйыйм әле. Икегезгә дә күңелле булыр». Әй куанды инде әни, әй куанды. Киявенә рәхмәтләр укыды. Ни хикмәт, алмагач, яхшы токымлы агач кебек, матур үсеп китте, күтәрелде, тармакланды. Рәсемнәрдәге кебек түп-түгәрәк алмагач булды. Әниемнең вафатына нәкъ өч ел тулган көнне алмагач шау чәчәккә күмелде. Бакчага ак яулыгын япкан әнием чыгып баскан кебек булды. Инде менә быел көзен бер ягы яшел, икенче ягы кызыл алмаларын күрдек. Юк, берән-сәрән генә түгел алмалар. Таза ботаклар мул уңышны чак-чак күтәреп тора. Корт та төшмәде, коелмыйлар да. Кабып кара әле».

Бу матур алмага тешемне тигермәдем. Алып кайтып өстәлгә куйганга ике атна үтте инде, алма берни дә эшләмәде. Һаман шулай ук матур. Тәмледер инде ул. Тәмле булырга тиеш! «Әни алмасы» бит ул!

PRESSA.RU



«Татнефть» предприятиеләре төркеменең бердәм профсоюз оешмасы оешуга – утыз ел. Хатын-кызлар аларда оешманың яртысын тәшкил иткән чаклар булган. Хәтта хәзер, инде буровойлардагы авыр хезмәт ир-ат җилкәсенә күчкәч тә, «Татнефть»тә профсоюз әгъзаларның утыз тугыз проценты – гүзәл затлар. Аңлауны, хәлгә керүне, яклау-хуплауны алар барыбер күбрәк таләп итә... «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте профсоюз оешмасының Татарстанда гына түгел, Россиядә дә соңгы вакытта дәрәҗәсе үсүен аның бүгенге рәисе Гомәр Кәрим улы ЯРУЛЛИН исеме белән бәйлиләр. Ул Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында туган. Хезмәт юлын слесарь, эретеп ябыштыручы булып башлый. Комсомол, партия оешмаларын җитәкли. Озак еллар «Азнакайнефть» НГДУ башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып эшли. Профсоюзларның Россия советы әгъзасы. РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының һәм «Татнефть» ААҖнең «Почетлы нефтьчесе» билгеләренә ия. Россия һәм Татарстан Республикасы Президентларының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

КЫЯЛАРНЫҢ ҮЗ СҮЗЕ



ТАМЫРЛАР Әтием Кәрим белән әнием Маһирауза узган гасыр башында туган кешеләр. Гражданнар сугышын күргәннәр, Бөек Ватан сугышын... Бәхете булгач, әти, гарипләнсә дә, сугыштан әйләнеп кайткан. Без дөньяга килгәнбез. Бер кул белән балта тотып мунчалар салды, мичләр чыгарды, печән чапты ул: безне – 8 баланы үстерергә, ашатырга, киендерергә кирәк бит. Бер дистәгә якын ир-бала белән әнигә дә җиңел булмагандыр: идән юарга да, өй җыештырырга да, су ташырга да өйрәтте ул безне. Сабыр кеше иде әни. Абыйлар өйләнә башлагач, берара өйдә өч килен белән яшәде ул.

Ачасырга хәзер ешрак кайтам. Олыгаям! Әти-әниләр һаман да исән кебек миңа, юлга чыксам, алар көтәдер кебек тоела. Бүгенге кебек җилдереп кенә әйләнеп килеп булмый иде бит элек: мин аларны елга бер генә тапкыр – ялларымда гына күрә идем, ерак дип, үзләре дә монда бик сирәк килде. Дөрес, әти вафат булгач, әни янына ешрак кайттык.

Туган нигездә балалары, оныклары белән Габдулла абый яши. Кайтыр җир бар! Әрем исләре иснәп киләм, чишмәләргә төшәм... Сабантуйлар күңелле була. Авылдашлар белән аралашып, бер-беребезгә булышып яшибез.



БАЛАЧАК Гел онытмыйм: «Ялкын» журналында Илдар Юзеевнең Карамай малай турында әкият поэмасы басылган иде. Балыкка баргач, нефтькә батып кайта ул малай. Урман буенда, үзәндә, чуаш ягында Сәкел елгасы ага бездә. Яз көне шул елга өстендә майлы кара таплар пәйда була торган иде. Без – бала-чага – Сәкелгә майка белән сөзеп балык тотарга барабыз. Кайткач әни гел ачулана иде, кием-салымыңны юып агартып булмый, дип. Журналдагы теге малай кебек нефтькә беренче батуым үзебезнең авылда булган минем, белмәгәнбез генә. Бәлки, безнең якта да ятмалар бардыр, тикшерелмәгән бит.

Балачакның тагын нинди мизгелләре истәме? 5 нче классны тәмамлагач, Габдрахман абый мине үз янына комбайнга булышырга алды. Бөтен авыллардан МТСка җыелалар иде, без дә Норлатта, тулай торакта тордык. Беренче тапкыр «гуляш» сүзен шунда ишеттем. Нәрсә икәнен дә белмим, и-и, тәмле дип ашаганым хәтердә. 6 нчы класстан соң инде салам күбәләүдә эшләдем. Этеп барып, эскерткә куяр өчен аны комбайннан тигез төшерергә кирәк. Тигез төшермәсәң, колхоз рәисе ачулана. Кызу, кылчык, тузан... Әй, ардыра, йокы килә. Болыт чыгып яңгыр яуса икән дип телисең. Алдагы җәйдә инде комбайнер ярдәмчесе булдым. 60 сум акча алдым! Алты капчык бодай бирделәр. Баедык! Бишмәт алырга да хәл җитте.



УКУ 8 нче классны тәмамлагач, Яшел Үзәнгә, ГПТУга киттем. Әти белән әни: «Берәр һөнәр ал, укы», – диделәр. 1 сентябрь көнне дәрескә кереп утырдым. Сөйлиләр дә сөйлиләр, кайсы кеше нидер яза. Ә мин бернәрсә аңламыйм! Утырам, елыйсым килә... «Кайтып китимме әллә?» – дигән көннәр күп булды. Әмма калдым! Аннан азрак аңлый башладым. Аннан инде сөйләшә дә башладым: кайда татарча, кайда русча, кайда ишарә белән... «Өчле»ләрсез ерып чыктым училищены! III разряд бирделәр. Ул вакытта зур разряд иде бу. Алты ай Яшел Үзәндәге «Серго» исемендәге хәрби заводта практика уздык. Цех башлыгы, бригадир, мине үзләренә эшкә җибәрүне үтенеп, училищега хат яздылар. Ышанычлары өчен мин аларга хәзергәчә рәхмәтле. Шул вакыт безгә очрашуга «Татнефтестрой» берләшмәсе башлыгының урынбасары килде. Ничек нефть табалар, катлам бораулыйлар, вышкалар куялар, халык анда ничек яши – барысы хакында да сөйләде. Эшчеләр җыя икән. Ул сайлап алган егетләр арасында мин дә бар идем. Ризалаштым, 16 яшьтә һәркемнең дөнья күрәсе килә...

Әлмәткә 1965 елны килеп төштем, дөресрәге безне Ленин урамындагы тулай торакка китереп тутырдылар. Ошады миңа Әлмәт! Безне эшкә чакырган абзый арттырмаган – кибетләрендә бөтен нәрсә бар: ит, балык, чәйшикәр... (Дөрес, өч елдан боларның берсе дә калмады.)

Мин гел укырга омтылдым. Армиядә танк дивизиясендә хезмәт иттем, 8 класс белем белән без ике генә егет идек. Белем алырга кирәклеген шунда аңладым. Тормыш бик тиз алга бара, белемсез булсаң, бер урында гына да туктап тормыйсың, ә зур адымнар белән артка китәсең. Кайтуга нефть-газ техникумына укырга кердем. Шуннан бирле һаман укыйм. Ел саен, көн саен...



ДУСЛАР Әйе, җиде төн уртасында шалтыратып ярдәм сорый алырлык дусларым бар. Барысы да хезмәттәшләрем. 17 ел Азнакайда эшләгәч, күбесе анда. Ярдәм дип, күбрәк киңәш сораудыр ул... Генераль директор урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев белән гомер буе бер сукмактан атлыйбыз. Саратовта партия мәктәбен тәмамлап кайткач, партиянең Әлмәт комитетында эшли башладым, 20 көннән соң Рөстәм Нәбиуллович анда инструктор булып килде. Шуннан бирле бергә. Юк, дуслардан башка яшәп булмый. Әти белән әни «таш белән атканга да аш белән җавап кайтарыгыз», дип өйрәттеләр безне. Бу – канга сеңгән. Дусларга гына түгел, кулдан килгән кадәр һәркемгә яхшылык эшләргә тырышып яшим.



МӘХӘББӘТ Нина белән мин армиядә хезмәт иткән чакта, Түбән Новгородта таныштым. Увольнениегә чыккан чагым иде, шунда очраштык. Озак кына хатлар алышып тордык, аннан мин аны барып алдым. Авылда никах укыттык, мулла бабай аңа: «Кызым, син хәзер Нурия булырсың», – диде. 1972 елның 12 июле иде ул... Аңлашып яшибез. Ике бала үстердек. Аракы эчмибез, дуңгыз ите ашамыйбыз. Табыныбызда, шөкер, хәләл ризык кына. Бәйрәмнәрдә улым, оныклар белән мәчеткә йөрим.

Рус кызына өйләнүем авылда зур вакыйга булмагандыр. Катнаш район бит безнең. Тик мәктәптә укыганда бер нәрсәне аңламый идем: Зөя елгасы бездән ике чакрымда гына. Андагы балык! Әмма, нишләптер, безнең авыл халкы балыкка йөрми, күрше Кири, Бишбатман авылы урысларының балык тотып китергәнен көтә. Гөмбәгә дә бай безнең як, тик аны да җыючы юк. Бакчада кәбестә дә үстермиләр. Аның каруы, алма күп була иде. Аны Яшел Үзәнгә алып барып саталар. Бәрәңге сатарга бездән 12 чакрымдагы Норлат базарына йөрдек. Кем алгандыр инде аны, хәтерләмим. Мәктәп кирәк-ярагына да велосипед белән Норлатка йөрдек.



УҢЫШ Шундый кешеләр бар, кушканын эшлиләр дә, шуннан артыгын кыл да кыймылдатмыйлар. Үзебезнең профсоюз рәисләрен (ә алар безнең алтмышау) бергә җыйганда да: «Кешеләргә ничек файда китерәсен уйлагыз да, үзегезгә үзегез эш уйлап табыгыз, кемдер кушканны көтмәгез», – дим.

Мин гади слесарь чагында да эшемне бик яраттым. Шуңадыр, яшь кенә булсам да, эретеп ябыштыручыларның җитәкчесе итеп куйдылар. Саратовка югары партия мәктәбенә укырга бару тәкъдиме кинәтрәк булды. Башта: «Хатыным, ике балам бар», – дип баш тарттым. 17 квадрат метрлы фатирыма канәгать булып йөргән көннәрем иде... Кадрлар бүлегендә отставкадагы полковник Красильников дигән кеше бар иде. «Нигә чакырды-

PRESSA.RU

лар?» – ди. Сөйләдем. «Сиңа бер минут вакыт, кире йөгер, ризалаш һәм укудан бервакытта да баш тартма», – диде ул миңа. Биш ел кичке бүлектә укып, техникумны тәмамлаган гына идем... Хатын: «Син түзсәң, мин чыдармын», – диде. Киттем. Русча инде сөйләшәм, тик фәнни телгә ерак әле. Анысына китап укый-укый өйрәндем. «Бу нинди сүз, ул нәрсәне аңлата?» – дип, тулай торакта егетләрне аптыратып бетерә идем. Уңыш – тырышлык нәтиҗәсе ул.

Уңыш – ул башкаларның сиңа булган ышанычына да нигезләнә. «Татнефть» кебек зур компаниянең профсоюз оешмасын җитәкләргә мине 2000 елда Шәфәгать Фәхразиевич тәкъдим итте. 25 кеше арасыннан. Мин ул чакта Азнакайда эшлим. Чакырып сөйләште дә: «Ун көннән карарымны ишетерсез», – дип озатып калды. Кичке алтыда чыктым аңардан. Кайттым, иртәгәгә кәгазьләр каралмаган, план төзелмәгән – эшкә кердем. Телефон шалтырый. Алсам – генераль директор үзе. «Мин сезнең исемгә тукталдым, әзерләнегез», – ди... Бик күп укырга туры килде. Законнарны өйрәнергә. Профсоюз ул нәрсә дигән сүз: эшче халык җыелып, үз оешмасын төзегән һәм үз арасыннан берәүне: «Без сиңа хезмәт хакы түлибез (үзебезнең кесәдән!), син анда өстә йөр, безнең фикерне җиткер, мәнфәгатьләребезне якла», – дип сайлап куйган. Хезмәт хакы алганда взнос түләгән шул кешеләр һәрвакыт күз алдына килә. Мин аларның ялчысы, ышанычларын акларга тиешмен.



КУРКУ Тирән итеп уйлаганда, кешеләрне эшкә алган җитәкчеләрнең алар турында онытуы, тормышларын, ничек яшәүләрен күз алдына китермәве, китерергә теләмәве куркыта мине. Әгәр берәү тырышып эшли һәм аңа хезмәт хакы дөрес түләнми икән, бу аны эшләмәскә өйрәтә. Кешене эшкә яллагансың икән, аркасында тире кипкәнче акчасын түлә, диелгән изге китапта. Ә түләмәүче җитәкчеләр шактый күп хәзер: мөмкинлеге булса да, шул акчага үзе җылы якларга ял итәргә китеп барырга һәм кайтмаска да мөмкин андыйлар. Ә эшче ничек эшли, яши, ашый, баласын карый – аны уйламый.

Соңгы елларда без гел «икътисад стагнациядә» дигән сүзне ишетәбез. Ягъни бер урында таптана дигән сүз бу. Нигә аны халыкка гади генә итеп шулай димәскә? Бер урында тормас өчен эшләргә, эшне оештырырга кирәк бит. Бу исә хезмәт хакы белән бәйле. Эш урынында шартлар тудыру белән: иртән өеннән чыгып киткән кеше кичен балалары янына әйләнеп кайтырга, аның сәламәтлегенә, бигрәк тә тормышына куркыныч янамаска тиеш. Профсоюз әгъзалары безгә шушы бурычны ышанып тапшырды, без шуның белән шөгыльләнәбез. «Татнефть» җитәкчесе Наил Мәганов инде быел гына да ике тапкыр матур адым ясады – эшчеләргә хезмәт хакын күтәрде. Аңарчы Шәфәгать Тәхавәтдинов ел саен ун процентка күтәреп килде – бу яктан безнең эшчеләр канәгатьтер.

Тагын нәрсә куркыта? Олыгайган көндә ялгыз, ярдәмчесез калу куркынычтыр. «Булыша алмассызмы?» – дип, олы гына кешеләр, гадәттә, ир-атлар килә. «Балаларыгыз бармы, алар кайда?» – дип сорыйм. Күбесе: «Аларны пенсия алган көнне генә күрәбез шул...» – диләр. Яшьләргә гел әйтәм: «Балаңны ничек тәрбиялисең, картлыгың шундый булачак», – дим.



АКЧА Кинәт кенә күп акчага ия булсам нишләр идемме? Хыяллар бар ул... Туган якта Аллаһы йорты саласым килә. «Үземә булмаса, балаларга шундый мөмкинлек бирсәң иде», – дип сорыйм Ходайдан. Туганнарыма булышыр идем, әлбәттә. Аннан ул акчаны сау-сәламәт ата-анадан туган гарип балаларны аякка бастыруга тотар идем. Табигатьнең бик зур гаделсезлеге кебек тоела бу күренеш... Эчкече әтиәнидән туган балаларның да бер гаебе дә юк анысы. Бер көнне урамда берәүгә хәер бирдем, тик мин машинага утырып киткәнче аны бер егет килеп тә алды. Узып барышлый гына сәдака ташлап киткәнче, андыйларның әти-әниләрен, көчләп булса да, эшкә урнаштыру – балаларына да ярдәм итү булыр иде.

Беләсезме, һавадан гына төшсә, акчаның беркайчан да бәрәкәте булмый. Хәләл көчне түгеп, эшләп алырга язсын аны. Табу гына түгел, тота да белергә кирәк акчаны. Августта безгә шушы хакта лекция укыдылар әле. Патша заманында аз гына акчасы булганнар эконом (йорт тотучы) тоткан: алар шул акчаны бәрәкәтле итеп файдаланып, аны ишәйтергә тырышкан. Кайбер байларның ялгыш юлга баскан балалары, акчаны туздырып, эчеп бетереп, нәселне фәкыйрьлеккә төшергән... Ничек бюджет төзергә? Һәр сумны, һәр тиенне ничек исәптә тотарга? Хәзер бит кибеткә керсәк, ташламаларга алданып, кирәкмәгән бик күп әйбер алабыз. Аннан: «Бу миңа нигә кирәк булды соң?» – дип аптырыйбыз. Мондый ялгышларны урап узарга өйрәттеләр лекциядә.



БАЛАЛАР Кызымнан да, улымнан да бик канәгатьмен. Эльмира – бухгалтер, башта техникум тәмамлады, аннан институт. Ә Эдуардым – Мәскәүдә, Нефть химиясе институтында укыды, соңрак финанс-икътисад институтын тәмамлады. Ул «Ямашнефть»тә эшли, җир астындагы катлам басымын саклау бүлеге җитәкчесе. Бергә яшибез, шөкер, киленнән дә уңдык – оныклар үстерәбез. Эльмираның улы Мәскәүдә, икътисад академиясендә укый. Татар-төрек лицеен тәмамлады, дүрт тел белә: татар, рус, инглиз, төрек. Ничек сөенмисең?! Оныклар бик якын! Дөнья шулай әкренләп түгәрәкләнеп бара, аннан китәр вакыт җитә... Тик китүдән куркырга кирәкми, минемчә. Бу – табигый, аңа әзерләнергә кирәк.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Дөньяның төрле чагы була – кайбер мәлләрдә кызып киткәлим... Әмма иң мөһиме – ярсуың басылгач, суынгач, хаталарыңны төзәтергә тырышырга кирәк. Безгә кайчак ясаган хатаңны тану, аңардан ояла белү җитми. Кешеләрдән оялып, Аллаһы Тәгаләдән куркып яшәү дөрестер... Тырышлыгым бардыр дип уйлыйм, дөньяны алып бару өчен кирәкле сыйфат ул.



ИБӘТУЛЛИНА Резеда

Казан дәүләт медицина институты (1994).

Гаиләле, ике улы бар.

Карьера:
табиб-кардиолог

Тормыш шигаре: «Кичәге көн үткәндә калган, киләсе көн әле тумаган: тормыш ул бүгенге көннең һәр мизгеленнән тәм табып, рәхмәтле булып яшәү».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Улларым – куанычым

Улларымның бер-бер артлы туган көннәре булды. Дуслары икесенә дә шундый матур бәйрәм ясадылар: асфальтка котлау сүзләре язганнар, шарлар очырдылар... Сөенеп карап тордым. Ә бер улыма дус кызы искиткеч тәмле зур торт пешереп килгән. Яшьләр бүген барысын да булдыра! Буй җиткән егетләрнең әнисе булу шундый күңелле икән. Юк, картаймыйм, мин алар белән яшәрә генә барам. Иң зур теләгем – тормышта үз урыннарын тапсыннар, чын кеше булсыннар.

Хәрәкәттә – бәрәкәт

Яңа гына бөтен дөньяда «Автомобильдән баш тарту» көне булып узды. 1997 елда Англия башлаган иде бу хәрәкәтне. Соңгы елларда аңа Казан да кушылды. Юлларда машиналарның күплеге – зур калалар проблемасы гына түгел ул хәзер. Дөрес, бүгенге тормыш темплары машинадан бөтенләй баш тарту мөмкинлеге бирми. Әмма, кардиолог буларак, мине бу вакыйгага шатландыра – кеше күбрәк хәрәкәтләнгән саен, аның гомере озыная. Велосипед белән эшкә йөрергә үзем дә риза – юлы да булса...

Гамьлеләр арта!


Кешеләр хәзер үзләренең бу җирдәге бурычы, тормышның мәгънәсе турында күбрәк уйлый кебек. Нәрсә хакына яшибез? Ничек итеп яшибез? Гомер азагы нинди булачак? Бәлки, бүген мин үзем аралашкан кешеләр генә шундыйдыр, белмим. Һәрхәлдә, безнең сөйләшүләр нинди яңа күлмәк алу белән генә чикләнми. Аларның берсе дә «эшкә барам, кайтам, балалар үсә» дип кенә яшәми. Һәрберсе рухи яктан күбрәк ачыла, рухи дөньясы турында күбрәк кайгырта.

сөендерде






көендерде




сөендерде






көендерде



сөендерде



көендерде

Иң зур хәсрәт – бала хәсрәте

Шушы көннәрдә олы улымның классташы фаҗигале төстә һәлак булды. 19 яше тулган көнне. Кайгырдык, дип кенә әйтсәм аз булыр... Әмма хәсрәтнең иң олысы аның әти-әнисенә килде – бердәнбер бала иде ул кыз. Бер мизгелдә тормышлары икегә бүленде... Иртәгә нәрсә көткәнен беребез дә белми. Якыннарыбызның сау-сәламәт, яныбызда булганына сөенеп, алар белән аңлашып яшисе иде. Җылы, матур сүзләрне бер-беребезгә бүген әйтәсе иде. Без бу хакта нигәдер югалту килгәч кенә уйланабыз.

Барысы да үз кулыбызда югыйсә!

Йөрәк-кан тамырлары чирләре белән авыручылар саны һаман беренче урында. Үзебезне бик яратабыз шул: тәмле ашыйбыз, телевизор каршыннан китмибез, машинадан төшмибез. Аннан, проблема тугач, табибтан могҗизалы берәр дару көтәбез: артык авырлык та, холестерин да, кан басымы да бетәр дип өметләнәбез... Тик андый дару юк! Йөрәк белән бәйле авырулар кешенең үз-үзенә булган мөнәсәбәтенә бигрәк тә бәйле. Сәламәт яшәү рәвеше дип юкка сөйләмибез.


Әйләнеп кайтмадылар...

Без Корбан гаетен бәйрәм иткән көннәрдә Мәккә шәһәрендә зур фаҗига булды: хаҗ кылучылар берсен-берсе таптап үтерде: 769 кешенең гомере өзелде, тагын 934 кеше төрле җәрәхәтләр алды. Соңгы 25 ел эчендә булган иң зур тапталыш, диделәр. Бу сәфәргә җыенганда: «Шунда вафат булып калсам иде», – дип теләүчеләр дә бар барын – изге җирдә ахирәткә күчкәннәр дөньядан бер гөнаһсыз китә, диләр. Тик үзеңне аларның туганнары, якыннары урынына куеп карасаң, барыбер үзегең өзелерлек...

PRESSA.RU

16+

«МИН ЯРАТТЫМ СЕЗНЕ...»



Рамис САФИН, «Татарстан—Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең Ульяновски өлкәсендәге хәбәрчеләр пункты җитәкчесе. Өйләнгән; гаилә стажы — 25 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Минем өчен хатын-кызның бөтен матурлыгы аның күзләрендә һәм чәчендә. Иңнәренә таралып төшеп торган йомшак чәчләренә карап, хатын-кызның бик күп сыйфатларына бәя бирә алам бугай. Дөресен әйтәм, әгәр ул чәчен бер уч кына калдырып артка резинка белән җыеп куйса, бу чәч иясе турында минем фикерем бик үк уңай була алмый... Нишләтәсең, хатын-кызның үз-үзен карап, тәрбияләп, матур булып йөргәнен яратам! Мин моңа эш вакытында әңгәмәләр корганда, теләсәм дә, теләмәсәм дә һәрвакыт игътибар итәм. Яраткан язучым Туфан ага Миңнуллин да юкка гына: «Чәч – хатын-кызның көзгесе», – димәгәндер инде.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Яраткан хатын-кызның бөтен фигыль-сыйфатларын гафу итәргә була – иренә хыянәттән башкасын. Соңгы вакытта дөньялар үзгәрде, ирләр, тормыш алып бару өчен, гаиләсен калдырып бер генә айга түгел, берничә айга вахта белән эшләргә өйдән чыгып китә. Яшь хатын ялгыз кала... Ул да тере кеше бит: ашыйсы-эчәсе килгән кебек, нәфесе, күңеле башка нәрсәләр дә тели.

Ә менә ун хатын-кызга җиде ир-егет туры килгән бу чорда ир кешенең ялгызы гына яшәүче хатын-кыз янында булып килүен кичерергә дә буладыр. Ялгызларга да бит гомер ике түгел, бер генә бирелә. Аларның да башкалар сыман ир назы, ир рәхәте күрергә хокукы бар.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...

– Миңа калса, икенчесе мөһимрәк. «Акча бетте! Кунакка киеп барырга кешенеке төсле киемем дә юк бит минем!» – дип гел шелтәләп, гаепләп торсалар, бу хатын яныннан гына түгел, өйдән үк чыгып китәсе киләдер... Ә илһамландыруга килгәндә, анысы хатын-кыздан гына тормый. Яраткан эш, хәтта урамдагы һава торышы, табигать матурлыгы да эчке халәтеңә тәэсир иткән чаклар еш була.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Кемдә ничектер, ә безнең гаиләдә минем хатыным дустым да. Без әле балалар бакчасыннан, төгәлрәге – дүрт яшьтән бирле бер-беребезне белеп, дус булып яшибез. Мәктәптә, аннан соң университетта укыганда да ул миңа дус итеп үзенең дуслары, йөргән егетләре турында сөйли иде, дөресрәге, җаен табып аны мин үзем сөйләтә идем. Гомумән, миндә кешенең эчке серләрен һәм күңеленең иң ерак почмагында ята торган уй-фикерләрне сөйләтә ала торган сәләт бар бугай. Бу миңа хәзерге эшемдә дә бик ярдәм итә. Гаилә, ир белән хатын, килен белән кайнана мөнәсәбәте турындагы сюжетларны әзерләгәндә – аеруча.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Рамилә бик озак ялындырып йөрде. Мин, инде 24 яшьлек егет, Ульяновскига китеп, телевидениедә эшли башладым, авылга да сирәк кайтам. Шулай берчакны бөтен булган көчемне җыйдым да, ул чакта бик дефицит саналган, хәтерем ялгышмаса, «LANCOME» фирмасында эшләнгән косметик наборны дусларым аша табып, аның капкачына А. Пушкинның шушы шигырен гравердан яздырдым һәм Рамиләгә бүләк иттем. (Бу бүләк әле дә Рамиләдә саклана.)

«Я вас любил: любовь еще быть может, / В моей душе угасла не совсем; / Но пусть она вас больше не тревожит, / Я не хочу печалить вас ничем. / Я вас любил безмолвно, безнадежно, / То робостью, то ревностью томим; / Я вас любил, так искренне, так нежно, / Как, дай вам бог, любимой быть другим... Р. 1989 г.»

Акыллы булса – аңлар, аңламаса – үзенә үпкәләсен янәсе. Аңлады... Дөрес, ул да бүләк косметикага кызыгып кына кияүгә чыкмагандыр анысы. Әгәр дә бер-береңне

якын итмәсәң, әйтеп тә, аңлатып та булмый торган нинди-дер хисләр, физиологик тартылу булмаса, 25 ел яшәп булмас иде...

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Әйе, иренә караганда акчаны күбрәк эшләп, өйдә соңгы сүз дә хатыннныкы булган гаиләләрне очратканым бар. Мәҗлесләрдә котлау сүзен беренче булып ир кеше әйтмәсә дә, мин, ни өчендер, бу гаиләдә хатын – баш, ир – муен икән, дип уйлап куям. Хәер, бүген заманасы да икенче бит аның. Безнең әби-бабайлар биргән классик татар тәрбиясе хәзерге кысаларга ярашмый да кебек.

7 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

– Миңа калса, ир-егетләрнең үз-үзен тотышы җәлеп итәдер. Аннан соң, хатын-кыз урынында булсам, кияүгә чыкканчы, башта җаен туры китереп, берәр мәҗлестә егеткә аракы эчертеп карар идем. Тормышта әүлия кебек йөргән егетләрнең байтак тискәре яклары исергәч күренә. Гомер иткәндә көнчеллек яки вакчыллык кебек сыйфатларның авырлыклар тудырачагы көн кебек ачык.

8 Хатын-кызның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Ир-ат, беренче чиратта, йортны, хуҗалыкны алып бара белсен. Минем кебек! Гаиләне ашату-эчертү, балаларны киендерү кебек проблемаларны хатын җилкәсенә салмасын ул.

9 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Кемне ничектер, мине куркытмый... Бер һөнәри чирем бар: микрофон тотып берәр чибәр хатын-кыз белән әңгәмә корганда, мин аңа күзем белән тутырып карыйм да, күңелемнән генә булса да, чишендерә башлыйм... Ул хисләр һәрвакыт тумый, әмма булгалый.

Утыз елга якын телевидениедә эшләү дәверендә мине иң куркыткан нәрсә – ул гашыйк булу иде. Йөрәк белән идарә итеп булмый бит. «Мәхәббәтең бакага төшсә, күл буеннан кайтмассың», дип юкка гына әйтмәгәннәр.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ходай Тәгалә безне кайсы гына галәмнән иңдерсә дә, бер җирдә яшәргә насыйп иткән. Мин, чыннан да, ир белән хатынның икесе ике галәмнән икәненә яши-яши ышана барам. (Мин генә түгел, бу хакта күпсанлы дус егетләр дә әйтә.) Интим тормышта бу аеруча нык сизелә: табиблар фикеренчә, ир кешенең җенси теләге ике-өч сәгать саен уяныргa мөмкин, ә хатын-кызларда алай түгел бугай. Баш авырта, йокы килә, кан басымым югары, ди ул. Теләмим, диярргә генә дә буладыр бит... Миңа калса, яшь гаиләләрдәге үзара суыну да шуннан башлана.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?

– Билгеле инде, баштагы елларда бездә дә шулай иде. Нидер исбатларга, дәлилләргә тырышып карадым бугай. Тора-бара хатын-кыз белән сүз көрәштерүнең мәгънәсе, файдасы юк икәнен аңладым. Тәмле сүземне әрәм иткәнче соң... Хәзер шундый хәл килеп туса, эчтән генә бер каты сүз әйтеп куям да, чыгып китәм.

12 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Беренчедән, мактанып әйтүем түгел, 25 ел хатын белән гомер итеп, мин эштән кайтканда Рамиләнең ашарга әзерләмичә диванда кырын ятканын хәтерләмим. Икенчедән, безнең беркайчан өйгә заказ белән ризык китергәнебез юк. Өченчедән, әгәр Рамилә иртән пешереп калдырырга өлгермәгән булса, бездә кичке ашны кем алдан кайта шул әзерли. Әгәр бергә кайтып керсәк, эштәге хәлләр турында сөйләшә-сөйләшә тиз генә икәү пешереп ашыйбыз. (Хәзер инде кызыбыз Алсу без кайтканчы нәрсә дә булса әзерли тора.) Ә шимбә көннәрендә иртәнге ашны әзерләү минем өстә. Ничек килеп чыгадыр, әйтә алмыйм, әмма тәмле диеп ашыйлар. (Күп вакыт ул кыздырылган ит, балык, бәрәңге яисә кичкенә чуеннарда пешерелгән аш була инде.)

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Менә монысы минем канны иң нык кыздырган нәрсә инде! Гадәттә, һәр җомга-шимбә диярлек без кунакка чакырылу. Алдан ничәдә кузгаласыбызны әйтеп куйсам да, китәргә 1-2 сәгать кала, Рамилә тузан суырткычны тартып чыгарып, өй җыештырырга яки кер юарга тотына... «Өлгерәбез әле, барыбер өстәл артына бер сәгатькә соңлап утыралар», – ди ул. Ә мин әйткән вакытым җиткәч, машинага чыгып утырам да, сигнал бирәм, алай да җиңә алмасам, телефоннан шалтыратып: «Мин китәм, такси яллап килерсең», – дим. Телевидениедә эшләү мине нык төгәллеккә өйрәтте, анда бит һәр минут, һәр секунд исәптә.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Миңа нинди генә бүләк бирсәләр дә ошый. «Бүләк ителгән атның тешенә карамыйлар», диләр бит. Иң мөһиме – сиңа карата булган игътибар һәм хөрмәт. Миңа калса, Рамилә миңа дигән бүләкне улыбыз Алмаз белән киңәшләшеп ала, һәм шунлыктан, һәрчак үземә кирәк әйбергә ия булам. Электрлы кырынгыч, свитер, портфель... Аның бүләк итү мизгеле бик кызык – мине беренче катка кухняга чакыралар. Башта әниләре, аннары Алмаз белән Алсу котлый, теләкләрен телиләр. Миңа карата тәнкыйть сүзләрен дә кыстырып җибәрергә күп сорамыйлар. Монысы да үзенә күрә бер гаилә сәясәте бит.

PRESSA.RU

Яшь чагында бер дә башка киясе килми бит ул. Башлыкны килешми дип табасың, яулыкны өлкәннәр генә бәйли дисең. Әниләрнең үзәге өзелеп калганын да уйламыйсың, салкыннан колаклар чымырдаса да сер бирмисең. Яшьләрнең модалы күренәсе килә. Бүген без тәкъдим иткән муенлы капюшон күпчелек кызларның күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. Аны бәйләү артык катлаулы түгел. Пальто төсенә туры килгән җеп тапсаң, калганы — ике-өч көнлек эш.





Мастер-классны «Сөембикә» укучыларына күптәннән таныш Ания ГАТАУЛЛИНА үткәрә.

ЯШЬЛӘРЧӘ һӘМ ҖЫЛЫ

Кирәк:

• 133м/100 г 3 йомгак бәйләү җебе (50% йон, 50% акрил);
• 5 нче номерлы бәйләү энәләре;
• 1 м тар атлас тасма (киңлеге 1 см);
• зур күзле тегү энәсе.



Үрнәк схемасы

■ – уң күз

● – чалып алу

◣ – ике күзне бер итеп, сулга авыштырып бәйләү (энә күзнең өстеннән кертелә)

◢ – ике күзне бер итеп, уңга авыштырып бәйләү (энә күзнең астыннан кертелә)

Эш барышы:

■ Энәгә 80 күз җыябыз. Бу 56–58 нче баш үлчәменә туры килә.

■ 10 рәт 2 уң, 2 сул күздән торган резинка бәйлибез (бәйләм әйләнә буенча бәйләнә).

■ 11 нче рәттә тасма уздыру өчен тишекләр ясала. Моның өчен: энәгә җеп чалып, 2 күзне бергә уң белән бәйлибез. Шул рәвешле рәтне бәйләп чыгабыз.

■ 12 нче рәттән 2 уң, 2 сул күз белән резинка бәйләүне дәвам итәбез. Резинка белән тагын 28 рәт бәйлибез. Барлыгы 20 см бәйләргә кирәк.

■ 39 нчы рәттән бәйләмне һәр ике күздән соң бергә арттыра барып (40 күз өстәлә), күзләр санын 120 гә җиткерәбез.

■ 40 нчы рәттән (уң як) бизәк белән бәйли башлыйбыз: 1 нче күз бәйләнми генә алына, 9 күз «энҗе бизәк» белән бәйләнә, 2 уң, 1 сул, 9 күзне рәсем-



дәге үрнәк буенча бәйлибез, 1 сул, 74 күз уң, 1 сул, 9 күз үрнәк буенча, 1 сул, 2 уң, 9 күз «энҗе бизәк»,

1 (соңгы күз) уң. «Энҗе бизәк»не бәйләү тәртибе түбәндәгечә: 1 уң, 1 сул, 1 уң, 1 сул... Икенче рәтне бәйләгәндә уң урынына – сул, сул урынына уң күз бәйлибез.

■ 41 нче рәт (сул як): 1 нче күз бәйләнми генә алына, 9 күз «энҗе бизәк», 2 сул, 1 уң, 9 сул, 1 уң, 74 күз сул, 1 уң, 9 сул, 1 уң, 2 сул, 9 күз «энҗе бизәк», 1 сул.

■ Капюшонның биеклеге 30 см булгач (муен өлешен санамыйбыз), кыл уртадан күзләр санын киметә башлыйбыз: 59–60 һәм 61–62 нче күзләрне бәйләгәндә ике күзне бергә бәйлибез. Игътибар: 61–62 нче күзләрне бәйләгәндә энәне өстән тыгабыз. Киметү бары тик уң якны бәйләгәндә генә башкарыла.

■ Бәйләм 40 см булганчы, гел шулай киметә барабыз. 40 см бәйләгәч, күзләрне япмый гына, капюшонның төбәсен трикотаж җөе белән тегәбез. Җепнең очын яшерәбез.

■ Капюшонны үтүкләү тактасына салып, үтүкнең табанын бәйләмгә тидерми генә пар белән үтүклибез. Тишекләр аша тасма уздыргач, үзе заманча, үзе җылы баш киемебез әзер.

Менә хәзер көзге салкын җилләр безгә куркыныч түгел!

СНУД

Бу шарфны бәйләр өчен берниндиэнәләр дә, ыргак та кирәкми. Куллар белән генә бәйләнә ул! Бәйләү тәртибе — энәләр белән оек бәйләме бәйләгәнчә. Бар аермасы: энә урынына — куллар!



Кирәк:

бик калын бәйләү җебе. Без, кирәкле җеп тапмагач, нечкәрәк җепне ике катладык. 4 йомгакка якын җеп китте.







Эш барышы:

■ йомгактан өч терсәк җеп үлчәп алып, уң кулның беләзегенә 12 күзәнәк җыябыз.

■ Беренче рәтнең беренче күзәнәген бәйләми генә алабыз – бер кулдан икенчесенә генә күчерәбез. Калган күзәнәкләрне уң белән бәйлибез. Кулларны энәләр дип хис итегез дә, энә белән ничек бәйләгән булсагыз, шулай бәйләгез. Икенче рәт сул белән бәйләнә. Шул рәвешле, шарфны үзегезгә кирәк озынлыкка җиткәнче бәйләгез.

■ **Күзләрне ябу тәртибе:** баштагы ике күзне бәйлибез. Аннары беренче бәйләгән күзне икенчесе аша беләзектән салдырабыз. Тагын бер күзне бәйлибез. Бая бәйләп алган күзне беләзектән салдырабыз. Күзләрне шулай берәм-берәм бәйләп ябабыз. Артык кысып бәйләмәгез!

■ Снудның ике очын бөҗрага тоташтырырга кирәк. Уң ягын эчтә калдырып, снудны урталай бөклибез, очларын тигезлибез.

■ Бәйләм җебен күзәнәкләр аша йөртеп, ике читне бергә ялгап тоташтырабыз. Артык җепне кисеп алабыз.

■ Шуның белән снуд әзер. Аны шарф итеп муенга чорнарга да, башка бөркәнергә дә була.

Сөмбел ГАФФАРОВА уздырган бу мастер-классны тулысы белән сайтыбыздан карый аласыз.

PRESSA.RU

ИТАЛИЯ КУХНЯСЫ: ЛАЗАНЬЯ

Бүгенге мастер-классыбызның хуҗабикәсе — Татарстанның атказанган артисты Резеда ШӘРӘФИЕВА. Җиңел кулдан гына лазанья пешерергә өйрәтәчәк ул безне. Татар эстрадасына куе бәрхет тавышы, искиткеч күлмәкләре, эшләпәләре белән килеп керде ул. Иң матур киенүче җырчы диделәр аның турында. Шулай булмыйча соң, үзе теккән күлмәкләр иде бит алар. Рәссам-бизәүче белгечлеге менә кайчан кирәк ул! Тегәргә әнисеннән өйрәнсә, җырга хирыслыгы — әтисеннән. Аның гармунда уйнап җырлаганын авылдашлары хәтерли әле. Әтисенең хыялларын кызы чынга ашыра менә. Гастрольдән кайтып кергәнен чак туры китердек. Аш-суга да оста икән җырчыбыз. Ул тәкъдим иткән ризыкны бергәләп әзерлик әле!





Кирәк:
- 400 г фарш;
- 2 баш суган;
- 1 кишер;
- 2 аш кашыгы томат пастасы;
- 400 мл кайнаган су;
- 4 аш кашыгы үсемлек мае;
- тоз-борыч, дәфнә яфрагы;
- 200 г каты сыр;
- 0,5 кг лазанья өчен махсус токмач

Соус өчен:
- 50 г акмай;
- 50 г он;
- 900 мл сөт.

Эш барышы:













■ Суганны турап, үсемлек маенда кыздырабыз. Ул алтынсу төскә кергәч, кишер уып салабыз. Икесен бергә болгата-болгата кыздырабыз. Кишер йомшаргач, фаршны кушабыз. Бераздан томат пастасы салабыз, тоз-борыч сибәбез. Кайнаган су салып, сүрән генә утта пешерүне дәвам итәбез.

■ Ул пешкән арада соус ясыйк. Калын төпле кәстрүлдә акмай эретәбез, шуңа аз-азлап кына он кушабыз. Төерләре калмаслык итеп туглагач, сөт өстибез, тоз сибәбез. Сөт кайнап чыккач, тагын бер кат яхшылап туглыйбыз һәм уттан алабыз.

■ Турыпочмаклы табаның төбен майлап, юка гына итеп соус ягабыз. Аның өстенә фаршны салабыз, кашык белән тигезлибез. Фаршны күп салырга кирәкми, юка гына булсын. Фарш өстенә уылган сыр сибәбез. Сыр өстенә бер кат токмач тезеп чыгабыз.

■ Токмач өстенә мул итеп кабат соус ягабыз. Бу юлы инде соус күп булырга, токмачны тулысынча капларга тиеш. Югыйсә токмачның пешмәве ихтимал. Соустан соң тагын ит һәм сыр катламнары салына. Аннан соң тагын токмач тезелә. Шул рәвешле берничә кат хасил була. Без, мәсәлән, токмачны дүрт кат тездек. Иң өскә – соус, аның өстенә – ит, ит өстенә сыр уып, лазаньяны 180–200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.
Ул 30-40 минуттан әзер була.

«Ә дигәнче».

ҖИТЕЗ БӘРӘҢГЕ



Мин Хәбибуллина Гөлзия. Тумышым белән Апас районының Сатмыш авылыннан булсам да, хәзерге көндә гаиләбез белән Казанда яшибез. Гаиләбездә дүрт кеше: әтиебез, үзем, кызым һәм улым. Кызым Зилә белән «Сөембикә» журналын укырга һәм төрле ризыклар пешерергә яратабыз. Сезнең конкурска тәкъдим итәсе ризыгыбыз «Ә дигәнче — бәрәңге» дип атала. Тиз генә пешереп өлгертер өчен бик уңайлы. Кирәкле нәрсәләре дә өйдә һәрвакыт табыла торган: бәрәңге, суган, помидор, сыр, майонез, тоз, борыч.


Эш барышы:

■ Бәрәңге белән суганны тәгәрмәчләп турыйбыз да, тозлап-борычлап, майонез белән бутыйбыз.
■ Майланган табага бушатып, өстенә түгәрәкләп киселгән помидор тезәбез.
■ Әз генә су салып, өстен фольга белән каплыйбыз һәм уртача кызулыктагы духовкага тыгабыз.
■ 20 минуттан фольгасын алып, өстенә уылган сыр сибәбез.
10-15 минутка гына яңадан духовкага куеп алабыз (көчлерәк утка).
■ Ризыгыбыз әзер, аны әзерләр өчен 30 минут вакыт җитә.
Ашларыгыз тәмле булсын!

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

Хәзер кайсы гына табибка мөрәҗәгать итсәң дә, сүз иммунитетка барып төртелә. Сәламәтлекнең бик мөһим чагылышы булган ул иммунитет дигән күзгә күренмәс нәрсә ни соң ул? Табиб-иммунологларны тыңлап карыйк. Алар: «Иммунитет системасы төрле әгъзаларның, күзәнәкләрнең бердәм һәм килешеп эшләве нәтиҗәсендә барлыкка килә торган саклану чарасы ул», — диләр.



ЯМАВЫ ҮЗЕНДӘ

Иммунитетны какшатучылар үз арабызда гына икән. Әйтик, су яки ризык белән керә торган микроорганизмнар, картая-картая үзлеген үзгәрткән күзәнәкләр дә дошман була ала. Онкология чиренә яки бүтән берәр әшәке чир чыганагына әверелергә өлгергәнче аларны организмнан себереп түгәргә кирәк. Моның өчен аларны таный белергә дә кирәк бит әле. «Иммунитет хәтере» дигән нәрсә бу эшне булдыра инде. (Төрле вакциналар эшләү нигезендә шушы – «иммунитет хәтере» дигән нәрсә ята.) Иммунитет күзәнәкләренең зур өлеше кан ясаучы тукымалардан хасил була. Иммунитет күзәнәкләре кешенең эчәклегендә яши, шуңа күрә сәламәт ашказаны, эчәк юллары организмны бактерияләрдән саклау өчен бик мөһим. Саклаучы ферментлар төкеректә, күз яшьләрендә, күкрәк сөтендә дә бар.

Төрле кешенең иммунитеты төрлечә. Көчле авырулары хроник формага күчкән кешеләрнең, каршы тору сәләте (һөҗүм итүче микроорганизмнарыкыннан көчсезрәк булган чагында), иммунитеты какшый. Аннары иң баштан ук иммунитетлары җитешсез булган кешеләр дә бар. Әгәр дә иммунитет каршылыгы кирәгеннән артып китә калса, бүтән проблема килеп чыга: иммунитет читтән килгән дошманнарны түгел, бәлки үз-үзен ашый башлый.

Ул чагында инде организмның сәламәт тукымалары зарарлана, аллергия касәфәте борын төртә.

Иммунитет җитешсезлеге нидән килеп чыга икән дигән сорау күпләрне борчый торгандыр. Бу сорау табибларны да уйландыра. Сирәк кенә моның сәбәпчесе – генетик тайпылышлар. Күпчелек очракта әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, төрле йогышлы авырулар кешенең саклану көчен какшата. Кагыйдә буларак, икенче очракта моны дәвалап була. Сез бик тиз арыйсыз, ниндидер хроник чирләр бимазалый икән, елга бишәр мәртәбә салкын тиеп авырып аласыз икән, аллергия яки герпес йөдәтә икән, чынлап торып иммунитетны ныгыту турында уйланырга һәм табибка йөгерергә вакыт.

Иммунитетны ныгытучы дарулар күп, әлбәттә. Әмма кай төшне ямарга кирәк икәнлеген, махсус методика белән тикшерелгән кан анализларын караганнан соң, табиб кына әйтә ала. Иммунитет төшкәндә, суалчан булганда, бронхит йөдәткәндә, шикәр диабеты, аллергия булганда, тире авырулары күзәтелгәндә алына андый анализ. Хәер, борчылыр өчен сәбәпләр бик күп. Иммунитетны тәртипкә сала торган дарулар хакында искәртсәк тә ярыйдыр. Аларның ниндиләре генә юк. Тик иммунитетны физиологик нормадан күтәрергә ярамаганлыгын онытмаска кирәк. Гадәттә, иммунитет дарулары антибиотиклар, вируска каршы дарулар, гөмбәчекләргә каршы препаратлар белән бергә беренче көннән үк бирелә.

Кеше организмына үсемлекләрдән алынган дарулар уңай тәэсир итә. Тик аларның да тискәре йогынтысы бар. Үсемлек даруларның вирусларга каршы тору үзлеге булуын да искәртик. Даруын әйткәч, шикәрнең иммунитетны шактый нык какшатуын да искәртик. Ә менә составында глюкоза булуына карамастан, кипкән җимешләр белән бал файдага гына. Артыкка киткән кофе да иммунитетны какшата. Чәй эчәргә яратучылар отышлы хәлдә. Чәйдәге тиамин организмны ныгыта гына. Алай да иммунитетның иң зур дошманы – начар кәеф. Елмаеп-көлеп яшәгез, гомер буе сәламәт булырсыз!


КУЧКАР. Елның соңгы аенда керемнәрегезнең артуы ихтимал. Ерак сәяхәтләргә барудан тыелып торыгыз. Хәер, монда да итәк-җиңне җыеп йөрергә тырышыгыз. Үтә дә мөһим әйберләрнең хәтердән чыгып китүе ихтимал. Сәламәтлекне ныгыту өчен яхшы вакыт.


ҮГЕЗБОЗАУ. Коллегаларыгызга, эшлекле партнерларыгызга таянырга туры килер. Эше иҗат белән бәйле булганнарга бик зур уңыш елмаячак. Ялгызлар бер күрүдән гашыйк булырга мөмкиннәр.


ИГЕЗӘКЛӘР. Уңышлы ай, хәтта уңышлардан башыгыз әйләнүе дә бар. Рухи канәгатьлек тә, матди әҗер дә булыр. Үтә дә кызыклы кеше белән танышырсыз. Бүген эшлисе эшне иртәгә калдырып, күңелсез хәлгә юлыгуыгыз ихтимал.


КЫСЛА. Төрле авантюраларга бай ай. Командировка яки сәяхәт вакытында яңа танышыгыз барлыкка килергә мөмкин. Әллә кайчан онытылган дусларыгыз белән дә мөнәсәбәтләрнең яңарып китүе ихтимал. Яңа эш тәкъдим итүләре бар.


АРЫСЛАН. Ай башында тормышыгызда беренче урынга шәхси эшләрегез һәм гаиләгез чыгар. Балаларның мәшәкатьләрен хәл итү белән мәшгуль булырсыз. Ялгызларның үз тиңнәрен очрату ихтималы бик зур.


СӨМБЕЛӘ. Хәлиткеч карарлар кабул итәргә туры килер. Киләчәктәге уңышларыгыз үзегезне хәзер ничек тотуыгызга бәйле. Тулаем алганда, уңышлы ай. Күптәнге хыялыгызны тормышка ашыру мөмкинлеге туар.


БИЗМӘН. Бу айда тормышыгыз төзелешне хәтерләтер: көн туган саен, яңа бер кат әзер. Кызыклы, мавыктыргыч ай. Йорт яки фатирыгызда ремонт башлау өчен шәп вакыт. Яшәү шартларын яхшырту форсаты чыгар.


ЧАЯН. Язмыш сезгә берничә көтелмәгән вакыйга әзерли. Ул вакыйгалардан үзегезгә файда алып калырга тырышыгыз. Яңа идея белән рухланырсыз. Ай ахырында романтик мөнәсәбәтләр көтелә. Беренче мәхәббәтегездән хәбәр алуыгыз ихтимал.


УКЧЫ. Быел башкарган эшләр хакында уйланып, нәтиҗәләр чыгару өчен яхшы вакыт. Тормышыгызда көтелмәгән борылышлар булыр. Эштә киеренкелекләрне җиңәргә туры килер. Мөһим карарларны ай уртасында кабул итегез – ялгышмассыз.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Балалар мәшәкатенә чумарсыз. Алар өчен горурланырга да туры килер. Эштә исә барысы да үз җае белән барыр. Аеруча айның икенче яртысы уңышлы. Мөһим эшләрне шул вакытка калдырыгыз. Керемнәргә караганда, чыгымнарыгыз артыграк булыр.


СУКОЯР. Бу айда сезнең барысы да яхшы булачак. Мондый гармониянең сирәк булуын исәпкә алып, тынычлыгыгызның рәхәтен тоеп калырга тырышыгыз. Айның беренче ике атнасында үзегездә таулар күчерерәй көч тоярсыз. Күп өлкәләрдә сүзе үтәрдәй файдалы кеше белән танышу ихтималы бар.


БАЛЫК. Үз фикерегезне якларга туры килер. Уңыш сезнең яклы. Яңа ниятләрегезне курыкмыйча тормышка ашырырга керешегез. Булышчыларыгыз якында гына йөри. Һөнәр өлкәсендә файдалы яңа белемнәр алырсыз. Финанс ягыннан борчылырга урын юк.

Октябрьдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Рәхилә Мифтахова (7.10.1940–8.01.2000) – **опера артисты, җырчы, педагог.** Каракалпак Республикасының Хоҗәйли шәһәрендә туа. 1959 елда Казан музыка училищесына укырга керә. 1968 елда Казан консерваториясен тәмамлый. Студент вакытында ук опера һәм балет театрының өйрәнчекләр төркеменә эшкә алына. Беренче рольләрен балалар өчен куелган опералларда башкара. 1968 елдан – инде җитлеккән актрисага баш рольләрне ышанып тапшыралар. 32 ел эчендә 52 партия башкара ул. 1971–1978 елларда – музыка училищесында, 1985–1999 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать университетында укыта. 1997 елдан – ялгыз җырлау кафедрасы мөдире, профессор. 1981 елда – РСФСРның атказанган, 1993 елда Татарстанның халык артисты исемнәренә лаек була.

Россия



Галина Стаханова (12.10.1940) – **актриса.** Мәскәүдә туа. Хыялында үзен артистка итеп күрсә дә, театр вузларына барырга кыймый. Ничек тә сәхнәгә якынаю өчен, 1960–1962 елларда Маяковский исемендәге театрда гример өйрәнчеге була. Аннан ике ел ГИТИСта тәэминатчы булып эшли. Костюмер вазыйфасын да башкара ул, «Мосфильм» киностудиясендә администратор да була. «Лужники» стадионында баш контролер да булып эшли. Төп эше белән бергә 1965 елда МГУның студентлар театрына артистка булып урнаша. Кинода – 1979 елдан. Евгений Евтушенко аны «Детский сад» фильмында үзенең әбисен уйнарга чакыра. «Мосфильм» актрисаның кандидатурасын бик авырлык белән раслый. Бу аның кинодагы тәүге эше була.

Чит илләр



Кейт Уинслет (5.10.1975) – **актриса.** Бөекбританиянең Рединг шәһәрендә туа. Актерлык карьерасы 1991 елдан башлана. Кино тәнкыйтьчеләренең мактау сүзләренә ирешкән тәүге эше «Күк затлары» фильмында башкарган роле. Шулай да тамашачы аны «Титаник»тагы яшь Роза Бьюкейтерны уйнаган актриса буларак таный. Бу роле өчен ул «Оскар» премиясенә тәкъдим ителә. «Айрис», «Тылсымлы ил», «Үзгәрешләр юлы» фильмнары да актрисага зур уңыш һәм кинопремияләр китерә. Шәп җырлаучы актриса буларак та таныла. Аның «What If» синглы Европаның күп кенә илләрендә хит буларак яңгырый.

PRESSA.RU





КАЙДА ДА – ҮЗ ӨЕНДӘ...

Виктория Егорова. Бу исем минем өчен яңа. Картиналары да ачыш булды. Үзе белән танышканчы, башта картиналары килеп керде дөньяма. Виктория үзе Казанда түгел иде, Индонезиядә – арт-фестивальдә, 20 ил арасында Россияне тәкъдим итүче бердәнбер рәссам буларак катнаша. Танышырга мөмкинлек килеп чыкмый да чыкмый. Шунда уйлап куйдым: бәлки, үзен белергә кирәк тә түгелдер? Сурәтләре аша җибәргән хәбәре – шул да бик җиткән. Җан биографиясе бит барыбер – иҗатта.

Әмма сурәтләренә ныграк күмелгән саен, сораулар күбрәк туа башлады. Сөйләшү зарурлыгы – арта...

«Күпчелек эшләрем эмоция-тәэсирләргә нигезләнгән. Башка илләргә сәяхәт иткәндә җыеп кайткан тәэсирләрме ул, шәһәр читенә чыгып кергән кечкенә генә сәфәрнекеме – кайда нәрсә көтеп торганын белмисең бит. Фәрештәләр яисә Галәмдәге бүтән көчләр белән бәйләнешне тоюдан туган сурәтләр дә бар, болары инде интуиция өлкәсенә карый, монда сүзләр артык...»

«Фәрештә пышылдавы» мине бер күрүдә үк җәлеп итте. Рәссамның дөньясында ялгызлык бөтенләй диярлек юк, булганда да ул – фәрештәле, гармонияле. Икенче бер картинасы – «Тынлык» – икәүнең бөтенлек тойгысында изрәве, гавамнан аерылып, үз аңлашу утрауларына йомылуы. Бу ике сурәт башка картиналарыннан аерылып тора. Мин аларны үзенә күрә бер диптих буларак кабул иттем. Бар да очып китәрдәй җиңел һәм йомшак-садә монда – кызның ап-ак челтәр күлмәге, чәчендәге такыясы да, туташны коендырган алтынсу нур, чәчләренә орынырорынмас тибрәнүче таҗын очырган тузганаклар да...

«Төркия циклы» кешеләр бердәмлеген, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең табигый җылылыгын бөркеп тора. «Бу серия Төркиядәге халыкара күргәзмәдә булып кайтканнан соң язылды. Анда мин таулардагы борынгы авылларда йөрдем. Гаҗәеп колоритлы урыннар. Ә өлкән кешеләрнең гадәти тормыш-көнкүреше – үзе бер фәлсәфә».

Чыннан да, шәркый рухны, бер-берсе белән тыгыз үрелгән эшлекле, туганнарча, дусларча мөнәсәбәтләрне нечкә итеп «тотып» ала алган Виктория. Базарда сату итүче агайлармы ул, кафеда утыручы яшьләрме, алма җыючы яки палас сатучы хатыннармы – борынгы традицияләр, милли-җирле рух бөркелеп тора һәммәсеннән.


«Институтны тәмамлаган гына елларда натюрмортлар, пейзажлар яза идем, ул үзенә күрә бер шундый чор булды, ахрысы. Хәзер инде миңа күп фигуралы киндерләр ошый, мин алар аша нәрсә җиткерергә теләгәнемне тоемлый башладым. 2014–2015 еллардагы эшләрем сериясендә мин үзебезнең халыкның көнкүрешен, җирле колоритны чагылдырырга тырыштым».

Ретроспектива ясап, Викториянең натюрмортлар һәм пейзажлар чорына «сикерәм». Һәм... ялгызаграк дөньяга юлыгам. Анда кешеләр юк диярлек, булса да, күләгәләр генә. Мәңге еламсырак Питерның яңгырларына, тымызык томаннарына сеңеп беткән тап-буяулар алар...

«Үз-үземә китеп, бикләнеп тору бик мөһим минем өчен», – ди Виктория. Монысы аңлашыла. Барыбыз да шундый. Миңа аның башка фразасы ошады. Бик символик тоелды: «Мин үз шәһәремне, туган илемне, Россияне бик яратам, әмма иҗат кешесе үзен билгеле бер җирлек, милләт, ил кысаларына гына кертеп «бикләргә» тиеш дип санамыйм. Кайда барсам да, үземне өйдәгедәй хис итәм...»


Бәлки, шуңа туганлык тоямдыр аның образларына карап – төрек агайларымы ул, утраклыкка күчкән чегәннәрме... кызның колагына нидер пышылдаучы фәрештәме. Ул да бит – Туган Йорт символы...

Луиза ЯНСУАР









Төркия циклыннан: авылда ял.

Болгардагы рәшә.
Тынлык.
Шәрык натюрморты.
Алма бакчасында.

ВИКТОРИЯ ЕГОРОВА



ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА АРЗАН БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП КАЛЫРГА АШЫГЫГЫЗ!

15 октябрьдән 25 октябрьгә кадәр «Россия почтасы» газета-журналларга язылу ункөнлеге үткәрә. Бу вакыт эчендә «Сөембикә» журналына да 10 процент ташлама белән, ягъни 445 сум 50 тиенгә язылырга була. Мөмкинлектән файдаланып калыгыз.

Бергә булыйк!

- Исегезгә төшерәбез: хәзер «Сөембикә» журналының электрон версиясенә дә язылырга мөмкин. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен бу «Сөембикә»гә язылу өчен бердәнбер мөмкинлек! Россиянең ерак регионнарында һәм БДБ илләрендә яшәүче укучыларыбызга журналны PDF-форматта алдыру арзангарак төшәчәк, чөнки моңа почта чыгымнары өстәлмәгән.
- Электрон версиягә язылганда, почта бүлегенә барып, чиратлар тору мәшәкате дә читләп үтә: үзегезгә кайчан җайлы, шул вакытта интернет-сайтка керәсез, банк картасы яки «электрон акча» белән тиешле сумманы күчерәсез. Компьютерның нибары берничә төймәсенә басу җитә! Һәм яңа саннар укучыга күпкә тизрәк барып җитә – чөнки язылучының компьютерына алар, урау юллар үтмичә, журналның басма варианты типография-дән чыгып өлгергәнче үк килеп ирешә. Чит төбәкләрдә яшәүче укучылар өчен монысы бигрәк тә мөһим булыр.
- Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала. Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табарга мөмкин (www.syuyumbike.ru).
- Сайтыбызда журналның басма вариантына да язылып була. Ашыгыгыз!



www.syuyumbike.ru





16+